*Казан шәһәре Яңа Савин районының*
*"Катнаш төрдәге 203нче балалар бакчасы"*
*муниципаль автономияле мәктәпкәчә*
*белем учреждениесе*
**РАСЛЫЙМ:**
*Мөдир*
*Г.К.Шагимуллина*
*Приказ № 4-м*
*Раслау көне 31.08.2022*
*ПУ*

# Балалар бакчасында татар теле тәрбиячесенең мәктәпкәчә яшьтәге төркемнәрдә рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә һәм татар балаларын ана телендә сөйләшергә өйрәтүнең эш программасы 2022-2023 нче уку елы

*Татар һәм ана теленә өйрәтүче тәрбияче:*
*Г.Р. Мадьярова*
**КАБУЛ ИТЕЛГӘН:**
*Педагоглар советының протоколы*
*№4-м көне 31.08.2022*
**КИЛЕШЕНГӘН:**
*Өлкән тәрбияче:*
*Э.Р. Орлова*

*Казан*

## Эчтәлек:


| № | Бүлекнең атамасы | Бите |
|---|---|---|
| 1. | **Максатчан бүлек** | |
| 1.1 | Аңлатма язуы | 4 |
| 1.1.1 | Программаның максаты һәм бурычлары | 5 |
| 1.1.2 | Принциплар | 8 |
| 1.1.3 | Программаны тормышка ашыруда мөһим билгеләр | 10 |
| 1.2.4 | Көтелгән нәтиҗәләр (кушымта) | |
| 1.2.4 | “Минем өем” проекты. (4-5яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 18 |
| 1.2.5. | “Уйный – уйный үсәбез” проекты. (5-6 яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 23 |
| 1.2.6. | “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты. (6-7 яшьлек балалар өчен ) | 28 |
| 1.2.7. | Тикшерү үткәрү буенча киңәшләр (татар теле) (кушымта) | 33 |
| 1.2.8. | Тикшерү өчен биремнәр. “Минем өем” проекты. (4-5яшь) (кушымта) | 34 |
| 1.2.9. | Тикшерү өчен биремнәр. “Уйный – уйный үсәбез” проекты. (5-6 яшь) (кушымта) | 39 |
| 1.2.10. | Тикшерү өчен биремнәр.“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты.(6-7 яшь) | 43 |
| 1.2.11 | Туган телгә өйрәтү буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру төрләре (кушымта) | 47 |
| 1.2.11 | “Туган телдә сөйләшәбез” . Эшчәнлек оештыру конспектлары.( 2-3 яшьлек балалар өчен) | 48 |
| 1.2.12 | “Туган телдә сөйләшәбез” . Эшчәнлек оештыру конспектлары.( 3-4 яшьлек балалар өчен) | 66 |
| 1.2.13 | “Туган телдә сөйләшәбез” . Эшчәнлек оештыру конспектлары.( 5-6 яшьлек балалар өчен) | 78 |
| 1.2.14 | “Туган телдә сөйләшәбез” . Эшчәнлек оештыру конспектлары.( 6-7 яшьлек балалар өчен) | 89 |
| 1.2.15 | Тикшерү үткәрү буенча киңәшләр (ана теле) (кушымта) | |
| 1.2.16 | Тикшерү өчен биремнәр. “Туган телдә сөйләшәбез” . ( 2-3 яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 103 |
| 1.2.17 | Тикшерү өчен биремнәр. “Туган телдә сөйләшәбез” .( 3-4 яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 108 |
| 1.2.18 | Тикшерү өчен биремнәр. “Туган телдә сөйләшәбез” .( 5-6 яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 115 |
| 1.2.19 | Тикшерү өчен биремнәр. “Туган телдә сөйләшәбез” . ( 6-7 яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 118 |
| 2. | **Эчтәлекле бүлек** | |
| 2.1.1. | Балага үсеш юнәлешләре буенча белем бирү (биш белем өлкәсендә) | 121 |
| 2.1.2. | Программаны тормышка ашыруда төрле технологияләр, формалар, алымнар, методлар һәм чаралар | 124 |

| | | |
|---|---|---|
| 2.2.1. | Тематик план. “Минем өем” проекты буенча (4-5 яшь) (кушымта) | 128 |
| 2.3.1. | Календарь планы. “Минем өем” проекты буенча (4-5 яшь) (кушымта) | 130 |
| 2.2.2. | Тематик план.“Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча (5-6 яшь) (кушымта) | 181 |
| 2.3.2. | Календарь планы. “Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча (5-6 яшь) (кушымта) | 183 |
| 2.2.3. | Тематик план. “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча (6-7 яшь) | 215 |
| 2.3.3. | Календарь планы.“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча (6-7 яшь) | 217 |
| 2.2.4 | Тематик план “Туган телдә сөйләшәбез” **.** ( 2-3 яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 298 |
| 2.3.4 | Календарь планы. “Туган телдә сөйләшәбез” **.**( 2-3 яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 300 |
| 2.2.5 | Тематик план “Туган телдә сөйләшәбез” **.**( 3-4 яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 313 |
| 2.3.5 | Календарь планы. “Туган телдә сөйләшәбез” **.** ( 3-4 яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 316 |
| 2.2.6 | Тематик план “Туган телдә сөйләшәбез” **.** ( 5-6 яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 330 |
| 2.3.6 | Календарь планы. “Туган телдә сөйләшәбез” **.**( 5-6 яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 332 |
| 2.2.7 | Тематик план “Туган телдә сөйләшәбез” **.**( 6-7 яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 356 |
| 2.3.7 | Календарь планы.. “Туган телдә сөйләшәбез” **.** ( 6-7 яшьлек балалар өчен) (кушымта) | 359 |
| 2.4. | Балалар белән үзара тәэсир итешү | 398 |
| 2.5. | Педагоглар белән үзара тәэсир итешү | 401 |
| 2.6. | Балалар бакчасында тәрбияләнүче балаларның гаиләләре белән үзара бәйләнешле йогынты, тәэсир итешү, ярдәм итү | 404 |
| 3. | **Оештыру бүлеге** | |
| 3.1. | Материаль-техник тәэмин итү | 407 |
| 3.2. | Методик материаллар һәм белем бирү чаралары | 407 |
| 3.2.1. | «Минем өем» укыту методик комплекты буенча күрсәтмә, таратма материаллар | 407 |
| 3.2.2. | «Уйный-уйный үсәбез» укыту методик комплекты буенча күрсәтмә, таратма материаллар | 408 |
| 3.2.3. | «Без инде хәзер зурлар-мәктәпкә илтә юллар” укыту методик комплекты буенча күрсәтмә, таратма материаллар | 410 |
| 3.2.4. | Методик әсбаплар | 411 |
| 3.3 | Татар теле кабинетында предметлы-үстерүче тирәлекне оештыру үзенчәлекләре | 419 |
| 3.4. | Белем бирү эшчәнлекләре челтәре һәм тәрбияченең эш көне бүленеше | 421 |
| 3.5. | Бәйрәмнәр һәм күңел ачу чаралары | 426 |
| | | |

## 1. Максатчан бүлек

### АҢЛАТМА ЯЗУЫ

“Татарстан Республикасы халыклары телләре турында” Татарстан Республикасы Законында һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасында мәктәпкәчә милли белем бирү өчен кирәкле шартлар булдыру каралган. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән кабул ителгән 2010 – 2015 елларда мәгарифне үстерү стратегиясендә (30.12.2010, №1174) – мәктәпкәчә тәрбия һәм белем бирү учреждениеләре өчен рус телле балаларны татарчага өйрәтү программасы, укыту-методик комплектлары (УМК) төзү бурычы куелды.

Балалар бакчасында татар теленә өйрәтү программасы (алга таба программа) “Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасы структурасына Федераль дәүләт таләпләре”нә (РФ Мәгариф һәм фән министрлыгының 23.11.2009 елда 655 нче карары нигезендә расланган) нигезләнеп төзелде.

Программа 4 яшьтән 7 яшькә кадәр булган рус телле балаларның татарча аралашырга өйрәтү эшчәнлекләренең эчтәлеген чагылдыра. Программа мәктәпкәчә яшьтәге баланың үсеш закончалыкларына, шәхси һәм эшлекле якын килү турындагы фундаменталь тикшеренүләргә, тел өйрәтү процессында методик стандарт итеп кабул ителгән коммуникатив технология принципларына (Л. С. Выготский, П. Я. Гальперин, В. В. Давыдов, Е. А. Пассов, В.Н. Мещерякова)  чагылыш тапкан фәнни тикшеренүләргә, гамәли эшкәртмәләр һәм методик киңәшләргә, мәктәпкәчә мәгариф системасы эшчәнлеген ачыклаучы норматив хокукый актлар, нигезләмәләренә көйләнгән.

Балалар бакчасында татар балаларына ана телен өйрәтәбез. “Туган телдә сөйләшәбез” дигән укыту-методик комплекты нигезендә эшлибез. “Туган телдә сөйләшәбез” укыту-методик комплекты Россия Федераѳиясе Мәгариф һәм фән министрлыгының “ Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына карата федераль дәүләт таләпләрен раслау һәм аларны гамәлгә кертү турында” 2009 ел, 23 ноябрь, 655нче боерыгы белән расланган Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына карата федераль дәүләт таләпләре нигезендә балалар бакчаларында, 2яшьтән 7 яшькә кадәр булган татар балаларына (Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева “Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы”) туган телне өйрәтү, сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру юнәлешен тормышка ашыру максатын күздә тотып төзелгән.

## ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

(рус һәм башка милләт балаларын татарча сөйләшергә өйрәтү)

**Уртанчылар** төркеме балаларын **(4-5яшь)** татарча өйрәтү **“Минем өем**” проектына нигезләнеп алып барыла. Педагогик эшчәнлекнең **максаты:** Татар теленә кызыксыну уяту. Информацион- коммуникатив технологияләр, уен- ситуацияләр, күргәзмәлелек кулланып тел өйрәтү, аралашу теләге тудыру.

**Бурычлар:** 1. Сүз байлыгы булдыру.

2. Гади диалогта катнаша белү, сүзләрне отып алу аша хәтер, зиһен үстерү.

3. Бер – береңне тыңлау, ишетү сыйфатлары тәрбияләү.

**“Минем өем**”проекты темалары ( “**Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар**”) буенча бирелгән лексиканы төрле ситуацияләрдә ишетеп, аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләре булдыру.

Балаларның тирә- юнь күзаллавын киңәйтә бару, югарыда күрсәтелгән темага караган сүзләр хисабына сүз байлыгын арттыру өстендә эшләү, татар телендә сөйләшә башлау теләге уяту.

Сүзләрне актив үзләштерүләренә ирешү өчен, әйбер исемнәренең мәгънәсен аңлату һәм аларны дөрес әйтү күнегүләре эшләү. Иң якын кешеләр ( **әти,әни,бабай, әби, малай, кыз**), яраткан уенчыклар(**туп, машина, курчак, эт,** песи, куян, аю), ашамлыклар ( **алма, ипи, сөт, чәй**) һәм саннар**( бер, ике, өч, дүрт, биш) хисабына** сүзлекне баету һәм активлаштыру. Өйрәнгән сүзләрне аерым, күмәк, тәрбияче ярдәмендә кабатлый белү күнекмәләре булдыру.

***Бу кем? Бу нәрсә?*** сорауларына аңлап җавап бирергә өйрәтү. ***Нинди?*** соравын аңларга, дөрес җавап бирергә өйрәтү. Әйберләрнең билгесен ачыклау маскаты белән куела торган сорауларны аңларга һәм сөйләмдә җавап кайтарырга өйрәтү (**зур, матур, йомшак, кечкенә, чиста, әйбәт, пычрак, тәмле**).Тәрбияче әйткән сүзләрне, кыска фразаларны балаларның кабатлап әйтә белүләренә ирешү өстендә эшләү. Аларның өлкәннәр кушкан катлаулы булмаган боерыкларны аңлап үти белүләренә ирешү ( **мә, бир, утыр, аша, эч, уйна, ю,ал).**

Тәрбияче әйткән билге буенча предметны табу, күрсәтә белергә өйрәтү. ***Зур машина ал. Тәмле алма бир.***

Үз исемен дөрес әйтә, исәнләшә,саубуллаша белергә өйрәтү, сүзләрне дөрес, урынлы куллану. ***Исәнме! – Исәнмесез! Сау бул! – Сау булыгыз! Мин- кыз...***

Таныш предметларның исемнәрен ныгыту, куелган сорауга раслау, инкарь итү сүзләрен ( **әйе, юк**) дөрес кулланырга өйрәтү. – ***Син Коля(мы) ? - Әйе. – Син кыз(мы)? – Юк, мин- малай.***

***Мин, син*** алмашлыкларын аңларга һәм урынлы кулланырга өйрәтү.

Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

**Зурлар** төркеме балаларын **(5-6яшь)** татарча өйрәтү **“Уйный- уйный үсәбез**” проектына нигезләнеп алып барыла. Педагогик эшчәнлекнең **максаты:** Үзара һәм зурлар белән көндәлек тормышта татарча аралашуга чыгу.

**Бурычлар**: 1. Сүз байлыгын арттыру, сөйләм күнекмәләре формалаштыру.
2. Гади сорауларны аңлап җавап бирү, мөрәҗәгать итә белү, көндәлек яшәештә аралашу.
3. Әдәпле итеп кара-каршы сөйләшә белү күнекмәләрен тәрбияләү.

**“Уйный-уйный үсәбез”**проекты темалары (“**Гаилә”**, **“Ашамлыклар”**, **“Уенчыклар”**, **“Саннар”**, **“Яшелчәләр”**, **“Савыт-саба”**, **“Киемнәр”**, **“Шәхси гигиена”**, **“Өй җиһазлары”**, **“Бәйрәмнәр”)** буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә **( уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт**) ишетеп, аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләре булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету,тулыландыру (**кишер,суган, бәрәңге, шалкан, кыяр, кәбестә, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, күлмәк, чалбар, бит, кул, баш, бармак, аяк, өстәл, урындык, караватъ, баллы, ничә, куп, нинди, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, сары, зәңгәр, нәрсә кирәк, юа, ки, киенә, сала, сал, йокла, хәерле көн, яратам, бар).**

Санау күнекмәләрен ныгыту, сөйләмдә камилләштерү.- ***Ничә туп? – Ике туп.***
***Нәрсә кирәк? Нинди?Ничә?*** сорауларын аңлап, мөстәкыйль рәвештә куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.
Раслау һәм инкарь итү сүзләрен ( **әйе, юк)** ныгыту, урынлы куллану. ***–Бу матур туп? - Әйе, матур туп.***
**Исем + сыйфат** конструкциясен сөйләмдә активлаштыру.

“Минем өем” проекты буенча өйрәнелгән боерык фигыльләрне ныгыту (**аша, эч, утыр, уйна, йокла)**, яңа боерык фигыльләрне (**ки, сал)** сөйләмдә аңлап, дөрес куллана белергә өйрәтү, активлаштыру.

Алган белемнәрен, сөйләм күнекмәләрен үстерешле диалогларда, уеннарда, ситуатив күнегүләрдә камилләштерү.

Кечкенә күләмле шигырьләр, җырлар өйрәтү.

**Мәктәпкә әзерлек** төркеме балаларын **(6-7 яшь)** татарчага өйрәтү **“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар”** проектына нигезләнеп алып барыла. Педагогик эшчәнлекнең **максаты**: Балаларның көнкүрешкә, табигатькә, җәмгыятькә кагылышлы сүзләр исәбенә сөйләмнәрен баету, балаларга әйләнә-тирәдәге предметлар турында тулырак мәгълүмат бирү, сүз һәм сүзтезмәләрне төрле ситуацияләрдә кулланышка кертү, аларны мөстәкыйль аралашуга әзерләү.

**Бурычлар**:
1. Сөйләмне аралашу чарасы буларак камилләштерү, файдалана белү күнекмәләренә өйрәтү.
2. Мөстәкыйль фикер йөртергә, җавап бирергә күнектерү, балада үзенең сөйләме белән кызыксыну һәм сизгерлек уяту.
3. Сөйләм әдәбе (сорау, гозер, мөрәҗәгать итү, рәхмәт белдерү, исәнләшү, саубуллашу) кагыйдәләрен камилләштерү.

**“Без инде хәзер зурлар- мәктәпкә илтә юллар”** проекты буенча темалары (**“Гаилә”, “Ашамлыклар”, “Уенчыклар”, “Саннар”, “Яшелчәләр”, “Савыт-саба”, “Киемнәр”, “Шәхси гигиена”, “Өй җиһазлары”, “Бәйрәмнәр”, “Танышу”, “Тату гаилә”, “Дусларны сыйлыйбыз”, “Кунак килде”, “Кафега барабыз”, “Күңелле уеннар”, “Без циркта”, “Безнең дуслар”, “Чана шуабыз”, “Без биибез”, “Күңелле сәяхәт”, “Мәктәп”, “Без әкият яратабыз”)** буенча бирелгән лексиканы төрле эшчәнлектә (**танып белү, уен, аралашу, музыка, хезмәт, хәрәкәт)** ишетеп, аңлап куллана белергә өйрәтү, сөйләм күнекмәләрен булдыру.

Яңа сүзләр хисабына баланың сөйләмен баету, тулыландыру (***тычкан, нишли, өйклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, барам, кая барасың, син нишлисең, сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәкчәк, өчпочмак,яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, ат, кәҗә, сыер, үрдәк, чеби,чана, шуа, шу, шуам, бие, бии, биим, кара, соры, җылы, салкын, җырла, җырлыйм, китап укый, китап укыйм, китап укы, рәсем ясый, рәсем яса, рәсем ясыйм, дәфтәр, бүләк, бәйрәм, мәктәп).***

***Бу кем? Бу нәрсә? Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Нишли? Син нишлисең? Кая барасың?*** Сорауларын аңлап, мөстәкыйль рәвештә куя һәм дөрес җавап бирә белергә өйрәтү.

Фигыльләр белән лексиканы баету (***ашый- ашыйм, эчә-эчәм,утыра-утырам, уйный- уйныйм, йоклый-йоклыйм, бии-биим, җырлый- җырлыйм, рәсем ясый- рәсем ясыйм, укый- укыйм, йөгерә- йөгерәм, чана шау-чана шаум, сикерә- сикерәм, бара- барам, ярата- яратам).***

Җырлар, шигырьләр өйрәнү.

# ПРОГРАММА ПРИНЦИПЛАРЫ

***Коммуникативлылык принцибы*** – балаларны татар телен аралашу чарасы буларак куллануга әзерләүгә корылган. Телне фән буларак түгел, ә аралашу чарасы буларак өйрәтү.

***Интеграция һәм дифференциация принцибы*** – һәр сөйләм төренең үз үзәнчәлеген исәпкә алу, тәрбияче сөйләмен техник чаралар ярдәмендә (аудио-, видеоязмада) тыңлау (аудирование), тел үзәнчәлекләрен төрле күнегүләрдә бирү, балаларның диалогик сөйләмен үстерү;

***Күрсәтмәлелек принцибы*** – тел өйрәтүне көндәлек тормыштагы һәр төрле эшчәнлеккә бәйле рәвештә, аларның тирә-юньне танып белүенең төп чарасы булып торган уен аша үткәрү;

***Тел өйрәтү, тәрбия һәм үстерү бурычларының бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә тормышка ашыру принцибы;***

***Барлык белем бирү өлкәләрен берләштерү (интегральләштерү) принцибы:*** аралашу, танып-белү, социальләштерү, физик культура, сәламәтлек, хезмәт, иминлек, матур әдәбият, иҗади сәнгать, музыка.

***Дәвамчанлык принцибы*** – балалар бакчасы һәм башлангыч мәктәптә эзлеклелекне күздә тоту;

***Белем бирүне комплекслы-тематик принципка корып оештыру;***

***Белем бирү эшчәнлегенең мотивлашкан булу принцибы*** - бала материалны үзе өчен кызык булганда, үзенең шәхси ихтыяҗларына туры килгәндә генә кабул итә һәм фикерли башлый. Телне өйрәтү процессында әкияти сюжетлар карау, кызыклы таныш геройлар (Акбай, Мияу) белән очрашу, уен элементларын куллану – тел материалын өйрәнүнең мотивлашкан булуын тәэмин итә. Телне аралашу, уен ситуацияләренә бәйләп өйрәнгәндә, балалар тел өйрәнүнең практик әһәмиятен тоялар, эмоциональ күтәренкелек туа һәм алар тел материалын бик теләп үзләштерәләр.

***Белем бирү эшчәнлегенең дидактик принцибы*** - гадидән катлаулыга таба бару.

***Индивидуальләштерү принцибы*** - тел өйрәткәндә социаль шәхес сыйфатларын үстерүне күздә тоту. Балаларның яшь үзәнчәлекләрен исәпкә алу.

Уртанчылар төркемендә атнага 2 тапкыр режим вакытында (уен формасында) эшчәнлек оештырыла, 20шәр минутлык дәвамында. Зурлар төркемендә атнага 1 тапкыр режим вакытында (уен формасында), 1 тапкыр кабинетта эшчәнлек оештырыла, 25әр минутлык дәвамында. Мәктәпкә әзерлек төркемендә атнага 2 тапкыр кабинетта, 1 тапкыр режим вакытында (уен формасында) эшчәнлек оештырыла, 30 ар минутлык дәвамында. Темалар бер-берсенә бәйләнешле итеп, балаларның яшь үзенчәлекләрен искә алып сайланган. Белем бирү эшчәнлекләренең темасы катлауландырылып, кабатлана бара, алар баланың сөйләм телен камилләштерү максатын күздә тотып төзелгән. Һәр теманы йомгаклау өчен, гомумиләштерү эшчәнлеге буларак, анимацион күренешләр дә эшләнгән. Телгә өйрәтүнең төп формасы һәм чарасы булып белем бирү эшчәнлеге алына. Ул системалы рәвештә план буенча үткәрелә. Планга индивидуаль эш тә кертелә. Өйрәнелгән сүзләр, сүзтезмәләр, диалоглар эшчәнлектән тыш уен вакытларында активлаштырыла һәм ныгытыла, көндәлек аралашуда кулланыла. Яңа сүзләрне, сүзтезмәләрне, ситуацияләрне балалар аңламаган очракта, тәрбияче рус телендә сөйли. Пиктограммалар мәктәпкә әзерлек төркемендә, яңа сүзләр (фигыльләр) белән беренче тапкыр таныштырганда гына кулланыла. Балаларга темадан тыш артык сүзләр, уеннар, җырлар, шигырьләр төп программаны үзләштергән очракта бирелә. Бала татар телендә сүзне дөрес әйтмәгән очракта, тәрбияче баланы тыңлап сүзнең дөрес үрнәген бирә. Балалардан авазларның дөрес әйтелешен катгый таләп итмәскә кирәк. Тәрбияче сөйләмендә акцент, җирле диалект, аваз кимчелекләре булмаска тиеш. Тәрбияче сүзлек белән эшләгәндә татар һәм рус телләре өчен уртак сүзләргә таяна ала. Тәрбияче үзенең эшенә иҗади якын килергә, төрле алымнар, чаралар эзләп, аларны кулланырга тиеш. Укыту-методик комплекты кысаларында, лексик минимумны үзләштергән очракта, эшчәнлектә планлаштырылган уеннарның эчтәлеген үзгәртү, яңа алымнар кертү, баету хуплана. Төркемнәрдә балаларның һәм тәрбиячеләрнең татар телендә аралашулары һәрдаим булырга тиеш. Эшчәнлектә өйрәнелгән тел материалы, режим моментларында, уен эшчәнлеге аша (ситуатив күнегүләр,сюжетлы-рольле уеннар, үстерелешле диалоглар, сәхнәләштерү һ. б.) ныгытыла. Рус телле балаларны татарча сөйләшергә өйрәткәндә балалар бакчасы коллективы һәм әти-әниләрнең бердәм позициядә булуы уңай нәтиҗә бирә.

## ПРОГРАММАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУДА МӨҺИМ БИЛГЕЛӘР

Балалар бакчасында ике **уртанчылар** төркеме бар. Алардагы үзенчәлекләр түбәндәге таблицаларда күренә.

Төркемдә тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре турында мәгълүмат:

| Билгеләр: | 7нче төркем бала саны | 4нче төркем бала саны | 7нче төркем % | 4нче төркем % |
|---|---|---|---|---|
| Балаларның гомуми саны | 24 | 24 | 100% | 100% |
| Тулы гаиләдә яшәүчеләр: | 24 | 24 | 100% | 100% |
| Тулы булмаган гаиләдә яшәүчеләр: | 0 | 0 | 0% | 0% |
| Күп балалы гаиләдә яшәүчеләр: | 4 | 3 | 16,7% | 12,5% |
| Проблемалы гаиләдә яшәүчеләр: | 0 | 0 | 0% | 0% |
| Опекун гаиләсендә яшәүчеләр: | 0 | 0 | 0% | 0% |
| Катнаш гаиләләрдә яшәүчеләр: | 10 | 4 | 41,7% | 16,7% |
| Рус гаиләләрендә яшәүчеләр: | 4 | 12 | 16,7% | 50,0% |
| Татар гаиләләрендә яшәүчеләр: | 8 | 7 | 33,3% | 29,2% |
| Башка милләт гаиләләрендә яшәүчеләр | 2 | 1 | 8,3% | 4,1% |

### 7нче номерлы уртанчылар төркеме балаларның индивидуаль үзенчәлекләре, %

| Төркем, яше | Җенесе | | Темперамент тибы | Социаль-эмоциональ сфера | Танып-белү сферасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | Х-к | И-а | | | |
| № 7 уртанчылар, 4-5яшь | 14 | 10 | Сангвиниклар– | Агрессияле – | Үсеш нормасына туры килә |
| | | | Холериклар – | Борчулы – | |
| | | | Флегматиклар – | Оялчан – | |
| | | | Меланхоликлар – | Гиперактив – | |

**4нче номерлы уртанчылар төркеме балаларның индивидуаль үзенчәлекләре, %**

<table>
<tr><td rowspan="2">Төркем, яше</td><td colspan="2">Җенесе</td><td rowspan="2">Темперамент тибы</td><td rowspan="2">Социаль-эмоциональ сфера</td><td rowspan="2">Танып-белү сферасы</td></tr>
<tr><td>Х-к</td><td>И-а</td></tr>
<tr><td rowspan="4">№ 4 уртанчылар, 4-5яшь</td><td rowspan="4">9</td><td rowspan="4">15</td><td>Сангвиниклар–</td><td>Агрессияле –</td><td rowspan="4">Үсеш нормасына туры килә</td></tr>
<tr><td>Холериклар –</td><td>Борчулы –</td></tr>
<tr><td>Флегматиклар –</td><td>Оялчан –</td></tr>
<tr><td>Меланхоликлар –</td><td>Гиперактив –</td></tr>
</table>

Балалар бакчасында ике **зурлар** төркеме бар. Алардагы үзенчәлекләр түбәндәге таблицаларда күренә.
Төркемдә тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре турында мәгълүмат:

| Билгеләр | 5нче төркем бала саны | 11нче төркем бала саны | 5нче төркем % | 11нче төркем % |
|---|---|---|---|---|
| Балаларның гомуми саны | 24 | 25 | 100% | 100% |
| Тулы гаиләдә яшәүчеләр: | 24 | 25 | 100% | 100% |
| Тулы булмаган гаиләдә яшәүчеләр: | 0 | 0 | 0% | 0% |
| Күп балалы гаиләдә яшәүчеләр: | 2 | 2 | 8,3% | 8,0% |
| Проблемалы гаиләдә яшәүчеләр: | 0 | 0 | 0% | 0% |
| Опекун гаиләсендә яшәүчеләр: | 0 | 0 | 0% | 0% |
| Катнаш гаиләләрдә яшәүчеләр: | 3 | 6 | 12,5% | 24,0% |
| Рус гаиләләрендә яшәүчеләр: | 15 | 10 | 62,5% | 40,0% |
| Татар гаиләләрендә яшәүчеләр: | 6 | 8 | 25,0% | 32,0% |
| Башка милләт гаиләләрендә яшәүчеләр | 0 | 1 | 0% | 4,0% |

**5нче номерлы зурлар төркеме балаларның индивидуаль үзенчәлекләре, %**

| Төркем, яше | Җенесе | | Темперамент тибы | Социаль-эмоциональ сфера | Танып-белү сферасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | Х-к | И-а | | | |
| № 3 зурлар, 5-6 яшь | 12 | 12 | Сангвиниклар– | Агрессияле – | Үсеш нормасына туры килә |
| | | | Холериклар – | Борчулы – | |
| | | | Флегматиклар – | Оялчан – | |
| | | | Меланхоликлар – | Гиперактив – | |

**11нче номерлы зурлар төркеме балаларның индивидуаль үзенчәлекләре, %**

| Төркем, яше | Җенесе | | Темперамент тибы | Социаль-эмоциональ сфера | Танып-белү сферасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | Х-к | И-а | | | |
| № 6 зурлар, 5-6яшь | 15 | 10 | Сангвиниклар– | Агрессияле – | Үсеш нормасына туры килә |
| | | | Холериклар – | Борчулы – | |
| | | | Флегматиклар – | Оялчан – | |
| | | | Меланхоликлар – | Гиперактив – | |

Балалар бакчасында өч **мәктәпкә әзерлек** төркеме бар. Алардагы үзенчәлекләр түбәндәге таблицаларда күренә. Төркемдә тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре турында мәгълүмат:

| Билгеләр | 3нче төркем бала саны | 6нчы төркем бала саны | 10нчы төркем бала саны | 9нчы төркем % | 9нчы төркем % | 9нчы төркем % |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Балаларның гомуми саны | 25 | 25 | 25 | 100% | 100% | 100% |
| Тулы гаиләдә яшәүчеләр: | 25 | 25 | 25 | 100% | 100% | 100% |
| Тулы булмаган гаиләдә яшәүчеләр: | 0 | 0 | 0 | 0% | 0% | 0% |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Күп балалы гаиләдә яшәүчеләр: | 1 | 1 | 1 | 4,0% | 4,0% | 4,0% |
| Проблемалы гаиләдә яшәүчеләр: | 0 | 0 | 0 | 0% | 0% | 0% |
| Опекун гаиләсендә яшәүчеләр: | 0 | 0 | 0 | 0% | 0% | 0% |
| Катнаш гаиләләрдә яшәүчеләр: | 6 | 6 | 7 | 24,0% | 24,0% | 24,0% |
| Рус гаиләләрендә яшәүчеләр: | 12 | 14 | 10 | 48,0% | 56,0% | 40,0% |
| Татар гаиләләрендә яшәүчеләр: | 7 | 3 | 8 | 28,0% | 12,0% | 32,0% |
| Башка милләт гаиләләрендә яшәүчеләр | 0 | 2 | 0 | 0% | 8,0% | 0% |

**3нче номерлы мәктәпкә әзерлек төркеме балаларның индивидуаль үзенчәлекләре, %**

| Төркем, яше | Җенесе | | Темперамент тибы | Социаль-эмоциональ сфера | Танып-белү сферасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | Х-к | И-а | | | |
| № 3 мәктәпкә хәзерлек, 6-7яшь | 11 | 14 | Сангвиниклар– | Агрессияле – | Үсеш нормасына туры килә |
| | | | Холериклар – | Борчулы – | |
| | | | Флегматиклар – | Оялчан – | |
| | | | Меланхоликлар – | Гиперактив – | |

**6нчы номерлы мәктәпкә әзерлек төркеме балаларның индивидуаль үзенчәлекләре, %**

| Төркем, яше | Җенесе | | Темперамент тибы | Социаль-эмоциональ сфера | Танып-белү сферасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | Х-к | И-а | | | |
| № 6 мәктәпкә хәзерлек, 6-7яшь | 11 | 14 | Сангвиниклар– | Агрессияле – | Үсеш нормасына туры килә |
| | | | Холериклар – | Борчулы – | |
| | | | Флегматиклар – | Оялчан – | |
| | | | Меланхоликлар – | Гиперактив – | |

**10нчы номерлы мәктәпкә әзерлек төркеме балаларның индивидуаль үзенчәлекләре, %**

| Төркем, яше | Җенесе | | Темперамент тибы | Социаль-эмоциональ сфера | Танып-белү сферасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | Х-к | И-а | | | |
| № 10 мәктәпкә хәзерлек, 6-7яшь | 13 | 12 | Сангвиниклар– | Агрессияле – | Үсеш нормасына туры килә |
| | | | Холериклар – | Борчулы – | |
| | | | Флегматиклар – | Оялчан – | |
| | | | Меланхоликлар – | Гиперактив – | |

Балалар бакчасында бер катнаш (икенче кечкенәләр һәм уртанчылар) **коррекцион (сукыр балалар)** төркеме бар. Алардагы үзенчәлекләр түбәндәге таблицаларда күренә. Төркемдә тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре турында мәгълүмат:

| Билгеләр | 8нче төркем бала саны | 8нче төркем % |
|---|---|---|
| Балаларның гомуми саны | 10 | 100% |
| Тулы гаиләдә яшәүчеләр: | 9 | 83,3% |
| Тулы булмаган гаиләдә яшәүчеләр: | 0 | 0% |
| Күп балалы гаиләдә яшәүчеләр: | 1 | 10,0% |
| Проблемалы гаиләдә яшәүчеләр: | 0 | 0% |
| Опекун гаиләсендә яшәүчеләр: | 1 | 10,0% |
| Катнаш гаиләләрдә яшәүчеләр: | 4 | 40,0% |
| Рус гаиләләрендә яшәүчеләр: | 2 | 20,0% |
| Татар гаиләләрендә яшәүчеләр: | 4 | 40,0% |
| Башка милләт гаиләләрендә яшәүчеләр | 0 | 0 |

**8нче номерлы коррекцион ( сукыр балалар) төркеме балаларның индивидуаль үзенчәлекләре, %**

<table>
<tr><td rowspan="2">Төркем, яше</td><td colspan="2">Җенесе</td><td rowspan="2">Темперамент тибы</td><td rowspan="2">Социаль-эмоциональ сфера</td><td rowspan="2">Танып-белү сферасы</td></tr>
<tr><td>Х-к</td><td>И-а</td></tr>
<tr><td rowspan="4">№ 8 катнаш төркем, 3-5яшь</td><td rowspan="4">4</td><td rowspan="4">6</td><td>Сангвиниклар–</td><td>Агрессияле –</td><td rowspan="4">Үсеш нормасына туры килә</td></tr>
<tr><td>Холериклар –</td><td>Борчулы –</td></tr>
<tr><td>Флегматиклар –</td><td>Оялчан –</td></tr>
<tr><td>Меланхоликлар –</td><td>Гиперактив –</td></tr>
</table>

Балалар бакчасында бер **икенче кечкенәләр** төркеме бар. Алардагы үзенчәлекләр түбәндәге таблицаларда күренә. Төркемдә тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре турында мәгълүмат:

| Билгеләр | 9нчы төркем бала саны | 9нчы төркем % |
|---|---|---|
| Балаларның гомуми саны | 26 | 100% |
| Тулы гаиләдә яшәүчеләр: | 26 | 100% |
| Тулы булмаган гаиләдә яшәүчеләр: | 0 | 0% |
| Күп балалы гаиләдә яшәүчеләр: | 3 | 11,5% |
| Проблемалы гаиләдә яшәүчеләр: | 0 | 0% |
| Опекун гаиләсендә яшәүчеләр: | 0 | 0% |
| Катнаш гаиләләрдә яшәүчеләр: | 6 | 23,0% |
| Рус гаиләләрендә яшәүчеләр: | 10 | 38,5% |
| Татар гаиләләрендә яшәүчеләр: | 10 | 38,5% |
| Башка милләт гаиләләрендә яшәүчеләр | 0 | 0% |

**9нчы номерлы икенче кечкенәләр төркеме балаларның индивидуаль үзенчәлекләре, %**

| Төркем, яше | Җенесе | | Темперамент тибы | Социаль-эмоциональ сфера | Танып-белү сферасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | Х-к | И-а | | | |
| № 9 икенче кечкенәләр, 3-4яшь | 11 | 15 | Сангвиниклар– | Агрессияле – | Үсеш нормасына туры килә |
| | | | Холериклар – | Борчулы – | |
| | | | Флегматиклар – | Оялчан – | |
| | | | Меланхоликлар – | Гиперактив – | |

Балалар бакчасында ике **беренче кечкенәләр** төркеме бар. Алардагы үзенчәлекләр түбәндәге таблицаларда күренә. Төркемдә тәрбияләнүчеләрнең гаиләләре турында мәгълүмат:

| **Билгеләр** | 1нче төркем бала саны | 2нче төркем бала саны | 1нче төркем % | 2нче төркем % |
|---|---|---|---|---|
| Балаларның гомуми саны | 17 | 17 | 100,0% | 100,0% |
| Тулы гаиләдә яшәүчеләр: | 17 | 17 | 100,0% | 100,0% |
| Тулы булмаган гаиләдә яшәүчеләр: | 0 | 0 | 0% | 0% |
| Күп балалы гаиләдә яшәүчеләр: | 4 | 6 | 23,5% | 35,3% |
| Проблемалы гаиләдә яшәүчеләр: | 0 | 0 | 0% | 0% |
| Опекун гаиләсендә яшәүчеләр: | 0 | 0 | 0% | 0% |
| Катнаш гаиләләрдә яшәүчеләр: | 5 | 2 | 29,4% | 11,8% |
| Рус гаиләләрендә яшәүчеләр: | 6 | 4 | 35,3% | 23,5 |
| Татар гаиләләрендә яшәүчеләр: | 6 | 10 | 35,3% | 58,8% |
| Башка милләт гаиләләрендә яшәүчеләр | 0 | 1 | 0% | 5,9% |

## 1нче номерлы беренче кечкенәләр төркеме балаларның индивидуаль үзенчәлекләре, %

| Төркем, яше | Җенесе | | Темперамент тибы | Социаль-эмоциональ сфера | Танып-белү сферасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | Х-к | И-а | | | |
| № 1 беренче кечкенәләр, 2-3яшь | 9 | 8 | Сангвиниклар– | Агрессияле – | Үсеш нормасына туры килә |
| | | | Холериклар – | Борчулы – | |
| | | | Флегматиклар – | Оялчан – | |
| | | | Меланхоликлар – | Гиперактив – | |

## 2нче номерлы беренче кечкенәләр төркеме балаларның индивидуаль үзенчәлекләре, %

| Төркем, яше | Җенесе | | Темперамент тибы | Социаль-эмоциональ сфера | Танып-белү сферасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | Х-к | И-а | | | |
| № 2 беренче кечкенәләр, 2-3яшь | 9 | 8 | Сангвиниклар– | Агрессияле – | Үсеш нормасына туры килә |
| | | | Холериклар – | Борчулы – | |
| | | | Флегматиклар – | Оялчан – | |
| | | | Меланхоликлар – | Гиперактив – | |

# КӨТЕЛГӘН НӘТИҖӘЛӘР

**“Минем өем” проекты. (**4-5яшьлек балалар өчен)

**Лексик минимум** – якынча 62 сүз һәм сөйләм үрнәкләре.

**Актив сүзләр:** әти, әни, кыз, малай, мин, исәнмесез, сау булыгыз, исәнме, эт, песи, әйе, юк, сау бул, әби, бабай, әйбәт, ипи, алма, сөт, чәй, рәхмәт, мә, тәмле, кил монда, утыр, бир, аша, эч, туп, зур, кечкенә, матур, курчак, куян, аю, хәлләр ничек, уйна, пычрак, чиста, ю, бер, ике, өч, дүрт, биш (49 сүз)

**Сөйләм үрнәкләре:** утырыгыз, бу кем?, кем юк?, син кем?, кем анда?, басыгыз, ал, ничә? нинди? (13 сүз)

**Проектның эчтәлеге түбәндәге темалардан тора:**

- гаилә
- ашамлыклар
- уенчыклар
- саннар

Атна дәвамында 20 шәр минутлык 2 эшчәнлек режим вакытында оештырыла.

| **Актив сузләр** | **Сөйләм урнәге** | **Аудиоязма,Эш дәфтәре, Мультфильм** |
|---|---|---|
| | **Гаилә – 12 сәгать (1-12)** | |
| әти<br>әни<br><br>малай<br>кыз<br><br>мин<br>исәнмесез<br>сау булыгыз<br><br><br><br>исәнме | -Бу кем?<br>-Әти (әни, бабай, әби, кыз, малай).<br><br>-Кем юк?<br>-Әти (әни, бабай, әби, малай, кыз).<br><br>-Исәнмесез.<br>-Син кем?<br>-Мин Коля (Оля).<br>-Мин малай.<br>-Сау булыгыз!<br><br>-Исәнме, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай, Мияу, Акбай).<br>-Сау бул, әни (әти, бабай, әби, кыз, малай). | Аудиоязма №1-23<br><br>Дәфтәрдә эш №1-4<br><br><br><br>Мультфильмнар:<br>1. “Әйдәгез, дуслашыйк”<br>2. “Качышлы уйныйбыз”<br>3. “Шалкан” |

| | | |
|---|---|---|
| эт<br>песи | -Кем анда?<br>-Мин песи. Мин Мияу.<br>-Кил монда.<br>-Мин эт. Мин Акбай.<br>-Кил монда.<br><br>-Син Коля?<br>-Әйе, Коля.<br>-Син малай (кыз)?<br>-Әйе (юк).<br><br>-Әти? (әни, бабай, әби, кыз, малай).<br>-Әйе.<br>-Әни? (әти, бабай, әби, кыз, малай).<br>-Юк.<br>-Малай?<br>-Юк, кыз.<br>-Кыз?<br>-Әйе, кыз.<br><br>-Хәлләр ничек?<br>-Әйбәт. | |
| әйе<br>юк<br>сау бул<br><br>әби<br>бабай<br><br>әйбәт | | |
| **Ашамлыклар – 9 сәгать (13-21)** | | |
| ипи<br>мә<br>рәхмәт<br><br>алма<br>сөт<br>чәй | -Мә, ипи (алма, сөт, чәй).<br>-Рәхмәт, әби.<br><br>-Коля, мә ипи (алма, сөт, чәй).<br>-Рәхмәт.<br><br>-Мияу, кил монда. Утыр. (Акбай, Коля, Оля) | Аудиоязма №24-39<br><br><br>Дәфтәрдә эш №5-10<br>Мультфильмнар:<br>1.“Тәмле” кибетендә”<br>2. “Азат кунак чакыра” |

| | | |
|---|---|---|
| тәмле<br>кил монда<br>утыр<br><br><br><br>аша<br>эч | -Оля, кил монда. Мә ипи (алма, сөт, чәй). Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле (ме)?<br>-Ипи (алма, сөт, чәй) тәмле. Рәхмәт.<br><br>-Мә, тәмле алма (ипи).<br><br>-Мә, ипи (алма) аша.<br>-Мә, сөт (чәй) эч. | |
| **Уенчыклар – 23 сәгать (22-44)** | | |
| туп<br><br><br>бир<br><br><br>зур<br>кечкенә<br><br><br><br>матур<br>курчак<br><br>куян<br>аю | - Бу нәрсә?<br>- Туп (курчак, куян, аю).<br><br>-Курчак (туп, куян, аю) бир.<br>-Мә, курчак (туп, куян, аю).<br><br>-Бу нәрсә?<br>-Аю (курчак, куян, туп).<br>-Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>-Аю (курчак, куян, туп) зур (матур, кечкенә, әйбәт).<br><br>- Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>- Аю (курчак, куян, туп) зур (кечкенә, матур, әйбәт).<br><br>-Аю (курчак, куян, туп)? -Әйе.<br>-Курчак (аю, куян, туп)? -Юк.<br><br>-Бу нәрсә?<br>-Аю (курчак, куян, туп). | Аудиоязма №40-53<br><br><br>Дәфтәрдә эш №11-13<br><br><br>Мультфильмнар:<br>1. “Паркка сәяхәт”<br>2. “Уенчыклар үпкәләгән”<br>3. “Күңелле уеннар”<br>4. “Акбай һәм Мияу маҗаралары” |

| | | |
|---|---|---|
| уйна | -Мә, аю (курчак, куян, туп). Уйна.<br><br>-Коля, кил монда. Уйна.<br>-Оля, кил монда. Уйна.<br><br>- Аю (курчак, куян, туп) бир.<br>- Аю (курчак, куян, туп) нинди?<br>- Аю (курчак, куян, туп) зур.<br>- Аю (курчак, куян, туп) кечкенә.<br><br>- Мә, зур аю (курчак, куян, туп).<br>- Мә, кечкенә  аю (курчак, куян, туп).<br>-Аю (курчак, куян), кил монда. Аша (утыр, эч, уйна). | |
| ю | -Коля (Оля), аю (курчак, куян, туп) ю.<br>- Исәнме, Мияу!<br>- Исәнме, Акбай! | |
| хәлләр ничек? | - Хәлләр ничек?<br>- Әйбәт. | |
| <br><br><br>пычрак<br>чиста | -Туп (курчак, куян, аю) нинди?<br>-Туп (курчак, куян, аю) пычрак (чиста).<br>-Туп ю.<br>-Туп чиста?<br>- Юк, туп пычрак.<br>(Әйе, туп чиста).<br>Ю, ю, ю – туп (курчак, аю, куян) ю. | |

| Саннар - 6 сәгать (45-50) | | |
|---|---|---|
| бер<br>ике<br>өч<br>дүрт<br>биш | -Ничә?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) алма.<br>-Ничә малай?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) малай.<br>-Ничә кыз?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) кыз.<br><br>-Өч?<br>-Юк.<br>-Ике?<br>-Әйе.<br><br>-Ничә аю (туп, курчак, куян)?<br>-Бер (ике, өч, дүрт, биш) аю. | Аудиоязма №54-60<br>Дәфтәрдә эш №14<br>Мультфильм:<br>1.“Уйный-уйный саныйбыз” |
| **Кабатлау - 15 сәгать (51-65)** | | |
| | | Аудиоязма №25<br>Дәфтәрдә эш №61-64<br>Мультфильм:<br>1. “Күңелле ял итәбез” |

**“Уйный – уйный үсәбез” проекты. (**5-6 яшьлек балалар өчен)

**Актив сүзләр:** кишер, нинди, баллы, ничә, суган, бәрәңге, алты, җиде, сигез, тугыз, ун, кыяр, кәбестә, кызыл, сары, яшел, кирәк, юа, нәрсә кирәк, аш, ботка, кашык, тәлинкә, чынаяк, зәңгәр, күлмәк, чалбар, ки, сал, йокла, бит, кул, өстәл, урындык, карават, яратам, бар (38 сүз)

**Сөйләм үрнәкләре:** бу нәрсә?, хәерле көн, нәрсә бар? күп (7 сүз).

**Проектның эчтәлеге түбәндәге темалардан тора:**

- яшелчәләр
- ашамлыклар

- савыт- саба
- киемнәр
- шәхси гигиена
- өй җиһазлары
- бәйрәм “Туган көн”
- бәйрәм “Сабан туй”
- Уртанчылар төркемендәге темалар(гаилә, ашамлыклар, уенчыклар, саннар) ел дәвамында кабатлана.

  Атнага 25 шәр минутлык 2 эшчәнлек (берсе режим вакытында, икенчесе дәресләр челтәре вакытында) оештырыла.

| **Актив сузләр** | **Сөйләм урнәге** | **Аудиоязма, Эш дәфтәре,Мультфильм** |
|---|---|---|
| | **Кабатлау – 2 сәгать (1-2)** | |
| | “Минем өем” проекты буенча | Аудиоязма №1 . Дәфтәрдә эш №1<br>Мультфильм: 1. “Шалкан” |
| | **Яшелчәләр – 21 сәгать (3-23)** | |
| Кишер<br><br>баллы<br>ничә<br>суган<br>бәрәңге<br>кыяр<br>кәбестә<br>нинди<br>бер<br>ике<br>өч<br>дүрт<br>биш<br>алты<br>җиде<br>сигез | -Бу нәрсә?<br>-Кишер.<br>-Мә, кишер.<br>-Нинди кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)?<br>-Зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Мә, зур (кечкенә) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Рәхмәт.<br>-Зур кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Кечкенә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Чиста кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Пычрак кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)<br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) нинди?<br>-Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) тәмле, зур (кечкенә), матур, чиста (пычрак)<br>Кишер баллы. Алма баллы. | Аудиоязма №2-24<br>Дәфтәрдә эш №2-6<br>Мультфильмнар:<br>1.“Баллы кишер”<br>2. “Уйный-уйный эшлибез”<br>3. “Юл маҗаралары”<br>4. “Кем эшләми, шул ашамый” |

| | | |
|---|---|---|
| тугыз | -Мә кишер(алма), аша. Баллы? | |
| ун | -Әйе, баллы. Рәхмәт. | |
| | -Ничә кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр)? Сана. | |
| | -Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) | |
| | -Оля, кил монда. Мә, ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) | |
| | -Ике (1-10) кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) | |
| | -Оля, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) бир. | |
| кызыл | -Мә, кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә,кишер). | |
| сары | -Рәхмәт. | |
| яшел | -Коля, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр) бир. | |
| | -Мә, (1-10) кәбестә (суган, бәрәңге, кишер, кыяр). | |
| нәрсә | -Сау бул, Коля. | |
| кирәк? | -Ничә кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер)? | |
| ю | -Бер (1-10) кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер). | |
| юа | -Кыяр (суган, бәрәңге, кәбестә, кишер) пычрак. | |
| | -Бу туп. | |
| | -Туп (алма) нинди? | |
| | -Туп (алма) сары (кызыл, яшел) | |
| | -Нинди туп (алма) юк? | |
| | -Кызыл (сары, яшел) туп (алма) юк. | |
| | -Кишер (суган, бәрәңге, кәбестә, кыяр) кирәк? | |
| | -Кирәк. | |
| | -Коля, нәрсә кирәк? | |
| | -Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) кирәк. | |

| | | |
|---|---|---|
| | -Нинди кыяр?<br>-Яшел (тәмле, чиста) кыяр.<br>-Кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) пычрак.<br>-Мә, кыяр (суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) ю.<br>-Оля кыяр ( суган, кишер, бәрәңге, кәбестә) юа. | |
| **Ашамлыклар – 7 сәгать (24-30)** | | |
| аш<br>ботка | тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй)<br>-Нәрсә кирәк?<br>-Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) кирәк.<br>-Нинди аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге)?<br>-Тәмле аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге). -<br>Мә, аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) аша (эч).<br>-Рәхмәт. Аш (ботка, сөт, ипи, чәй, кишер, кәбестә, кыяр, бәрәңге) тәмле. | Аудиоязма №25-29<br>Дәфтәрдә эш №7, 8<br>Мультфильм: 1.“Аш бүлмәсе” |
| **Савыт-саба - 6 сәгать (31-36)** | | |
| Кашык<br>тәлинкә<br>чынаяк<br>зәңгәр | -Кашык (тәлинкә, чынаяк) бир.<br>-Нинди кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-Зур (кечкенә, сары, яшел, кызыл, зәңгәр).<br>-Ничә кашык (тәлинкә, чынаяк)?<br>-(1-10 га) кашык (тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, (1-10) кашык(тәлинкә, чынаяк).<br>-Мә, кызыл (сары, яшел, зәңгәр). чынаяк (тәлинкә, чынаяк). | Аудиоязма №30-37<br>Дәфтәрдә эш №9, 10<br>Мультфильм:<br>1. “Өч аю”<br>2. “Чисталыкта - матурлык” |
| **Киемнәр - 8 сәгать (37-44)** | | |
| күлмәк<br>чалбар | Яшел (кызыл, сары, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br>Чиста күлмәк (чалбар).<br>Матур күлмәк (чалбар). | Аудиоязма №38-43<br>Дәфтәрдә эш №11, 12<br>Мультфильм: |

| | | |
|---|---|---|
| ки<br>сал<br><br>йокла | Күлмәк (чалбар) юк.<br>-Оля, күлмәк (чалбар) бир.<br>-Нинди күлмәк (чалбар)?<br>-Сары (кызыл, яшел, зәңгәр) күлмәк (чалбар).<br>-Ничә күлмәк (чалбар)?<br>-Бер (1-10) күлмәк (чалбар).<br>-Курчак, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br>-Оля, чалбар (күлмәк) бир.<br>-Мә, чалбар (күлмәк).<br>-Рәхмәт. Курчак, мә, чалбар (күлмәк) ки (сал).<br>-Курчак, йокла. | 1.“Киемнәр кибетендә”<br>2.“Шаян уенчыклар” |
| | **Шәхси гигиена – 4 сәгать (45-48)** | |
| бит<br>кул<br>хәерле көн | -Хәерле көн.<br>-Мә су, бит (кул) ю.<br>-Бит (кул) чиста.<br>-Бит (кул) чиста.<br>-Әйе, бит (кул) чиста. | Аудиоязма № 43, 44-48<br>Эш дәфтәре №13, 14<br>Мультфильм<br>1.“Ни өчен киемнәр югалган?” |
| | **Өй җиһазлары – 4 сәгать (49-52)** | |
| өстәл<br>урындык<br>карават | -Зур (кечкенә) урындык (өстәл, карават).<br>-Зур аю, мә зур карават (өстәл, урындык).<br>-Кечкенә аю, мә кечкенә карават (өстәл, урындык).<br>-Нәрсә кирәк?<br>-Карават (өстәл, урындык) кирәк.<br>-Нинди карават?<br>-Зур (кечкенә, сары, яшел, зәңгәр) карават.<br>-Мә, зур карават.<br>-Рәхмәт. | Аудиоязма № 49<br>Эш дәфтәре №15<br>Мультфильм:<br>1.“Маша һәм өч аю” |
| | **Бәйрәм “туган көн” – 8 сәгать (53-60)** | |
| яратам | -Мин алма (ипи, сөт, чәй, ботка, аш, кыяр, кәбестә, бәрәңге, кишер) яратам. | Аудиоязма №50-60<br>Эш дәфтәре №16-19 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| бар | | -Мин Коля(ны) (Оля(ны) яратам.<br>-Мин курчак(ны) (аю(ны), песи(не), эт(не), куян(ны) яратам.<br>-Нәрсә бар?<br>-Туп (курчак) бар.<br>-Нәрсә юк?<br>-Туп (курчак) юк.<br>“Бар”, “Юк” сүзләрен кулланып “Гаилә”, “Яшелчә” “Уенчыклар”темаларын кабатлау. Диалогларны кабатлау. “Кибетле” уеннары. | Мультфильм:<br>1. “Туган көн”<br>2. ”Кем нәрсә ярата?” |
| **БӘЙРӘМ “САБАНТУЙ”- 6 СӘГАТЬ (61-66)** | | | |
| | | Ел дәвамында өйрәнелгән сүзләр, сөйләм үрнәге кулланыла.“Гаилә”, “Яшелчә”, “Уенчыклар” темаларын кабатлау. “Кибетле” уеннары. | Аудиоязма №61-63<br>Мультфильм:<br>1.“Сабантуй бәйрәме” |

**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты.**

6-7 яшьлек балалар (мәктәпкә әзерлек төркеме) өчен якынча 60 сүз һәм сөйләм үрнәкләре.

**Актив сүзләр:** син кем, хәерле көн, тычкан, бу кем? бу нәрсә? нишли?, йоклый, утыра, ашый, эчә, нишлисең?, ашыйм, эчәм, уйный, уйныйм, утырам, барам, кая барасың?, син нишлисең?,сикер, сикерәм, сикерә, йөгерә, төлке, йөгер, йөгерәм, чәк-чәк, өчпочмак, яшь, бүре, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, чана, шуа, шуам, бие, бии, биим, ак, кара, җырла, җырлыйм, зур рәхмәт, китап укый, рәсем ясыйм, укыйм, дәфтәр, нәрсә яратасың?(пассив сүз)

Проектның эчтәлеге уртанчылар, зурлар төркемендә өйрәнгән сүзләргә таянып аралашуга корылган.

Атнага 30 ар минутлык 3 эшчәнлек (берсе режим вакытында, ике эшчәнлек дәресләр челтәре вакытында) оештырыла.

| **Актив сузләр** | **Сөйләм урнәге** | **Аудиоязма, Эш дәфтәре, Мультфильм** | **Эшчәнлек саны** |
|---|---|---|---|
| син кем? | | Аудиоязма №1 - 2 | 1-3 |
| хәерле көн | -Хәерле көн, Оля (Коля).<br>-Хәерле көн, әни (әти, бабай, әби). | Аудиоязма №3 - 5<br>Дәфтәрдә эш №1<br>Мультфильм: “Мияу адашкан” | 4-6 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| тычкан<br><br>бу кем? | <br><br><br>-Бу-әни (әти,кыз, малай...)?<br>- Әйе,  әни (әти,кыз, малай...). | Аудиоязма №6<br>Дәфтәрдә эш №2<br>Аудиоязма №7 - 8<br>Дәфтәрдә эш №3<br><br>Мультфильм:”Аю баласы дөнья белән таныша” | 7-7<br><br>8-9 |
| бу нәрсә? | - Бу- туп (курчак,машина).<br>-Нинди туп?<br>- Кечкенә (зур,матур,чиста...) | Аудиоязма №9 - 10<br>Дәфтәрдә эш №4 | 10-11 |
| нишли?<br>Йоклый | -Песи нишли?<br>-Песи йоклый. | Аудиоязма №11 | 12-13 |
| утыра | -Әни нишли?<br>-Әни утыра. | <br><br>Мультфильм: “Батыр Мияу һәм куркак Куянкай” | 14-15 |
| ашый<br>эчә | -Коля нишли?<br>-Коля ашый (эчә). | <br>Аудиоязма №12<br>Дәфтәрдә эш №5 | 16-18 |
| нишлисең?<br>ашыйм<br>эчәм | -Мияу, нишлисең?<br>-Ашыйм.<br>-Акбай, нишлисең?<br>-Эчәм. | <br>Аудиоязма №13 - 14<br><br><br><br>Мультфильм: “Тату гаилә” | 19-21 |
| уйный | -Оля (Коля), нишлисең? | Аудиоязма №15 | 22-24 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| уйныйм<br><br>утырам | -Уйныйм. | Аудиоязма №16 - 18<br><br>Мультфильм: “Юмарт аю” | 25-30 |
| барам<br>кая<br>барасың?<br><br>син<br>нишлисең? | -Кая барасың?<br>-Кафега барам.<br><br>-Син нишлисең?<br>-Мин бәрәңге ашыйм (чәй эчәм, уйныйм, барам, утырам, йоклый) | Аудиоязма №19<br><br>Аудиоязма №20<br>Дәфәрдә эш №6<br>Мультфильм: “Кафега барабыз”<br><br>Дәфтәрдә эш №7 | 31-33<br><br>34-36<br><br>37-38 |
| сикер-<br>сикерәм | Туп, туп- Матур туп.<br>Сикер-сикер, Матур туп. | Аудиоязма №21-23 | 39-42 |
| сикерә<br>йөгерә<br>төлке | Куян сикерә (йөгерә).<br>Туп сикерә.<br>Песи сикерә (йөгерә).<br>Төлке сикерә (йөгерә). | Мультфильм: “Урманда күңелле уеннар”<br><br>Аудиоязма №24<br>Дәфтәрдә эш №8 | 43-45 |
| йөгер-<br>йөгерәм<br><br>чәк-чәк | -Йөгер! Син нишлисең?<br>-Мин йөгерәм. | Аудиоязма №25-28<br><br>Мультфильм:<br>“Көчлеләр, кыюлар, җитезләр” | 46-48 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| өчпочмак | -Мин чәк-чәк ашыйм.<br>-Мин өчпочмак ашыйм. | Аудиоязма №29-30<br>Дәфтәрдә эш №9 | 49-51 |
| | | | 52-54 |
| яшь | -Сиңа ничә яшь?<br>-6 яшь. | Мультфильм:<br>“Җәнлекләр спорт бәйрәмендә” | |
| бүре<br>керпе | -Мин бүре. Мин зур, матур,<br>чиста. | Аудиоязма №31-32 | 55-55 |
| | | Аудиоязма №33-34<br>Дәфтәрдә эш №10 | 56-57 |
| тавык<br>әтәч | Әтәч зур, матур<br>Тавык кечкенә, матур | Мультфильм:“Циркта” | |
| үрдәк | -Син кем?<br>-Мин үрдәк. | Аудиоязма №35 - 36<br>Дәфтәрдә эш №11 | 58-58 |
| | | Аудиоязма №37 - 38<br>Дәфтәрдә эш №12 | 59-60 |
| чана<br>шуа | Куян чана шуа. | Мультфильм: “Шаян кошлар” | |
| шуам | Мин чана шуам. | Аудиоязма №39 - 40 | |
| | | | 61-63 |
| | | Аудиоязма №41<br>Дәфтәрдә эш №13 | |
| бие<br>бии | -Аю, әйдә, бие! | Мультфильм: “Урманда зур<br>концерт” | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| биим | | Аудиоязма №42 - 44<br>Дәфтәрдә эш №14 | 64-64 |
| ак<br>кара | -Оля кызыл шар ярата?<br>-Юк.<br>-Оля яшел шар ярата?<br>-Әйе, мин яшел шар яратам. | Аудиоязма №45 - 46<br><br>Мультфильм: “Акбай туган көнгә барырга җыена” | 65-66 |
| җырла-<br>җырлыйм | -Син нишлисең?<br>-Мин җырлыйм. | Аудиоязма №47<br>Дәфтәрдә эш №15 | |
| | Җырлыйбыз | Аудиоязма №45, 48 – 49<br><br>Мультфильм: “Мияуның туган көне” | 67-69 |
| зур рәхмәт | зур рәхмәт | Аудиоязма №50<br>Дәфтәрдә эш №16 | 70-70 |
| китап укый | Кыз китап укый. | Аудиоязма №51 - 53<br>Дәфтәрдә эш №17 | 71-72 |
| рәсем<br>ясыйм | рәсем ясыйм-алма ясыйм<br>мәктәп | Мультфильм: “Урман китапханәсендә” | 73-76 |
| | | Аудиоязма №54 - 60<br>Дәфтәрдә эш №18 | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| укыйм | -Кем укый.<br>-Мин укыйм. | Мультфильм “Уйный-уйный укыйбыз” | 77-78 |
| | бик тәмле | Аудиоязма №61 | |
| дәфтәр | - Бу нәрсә?<br>- Дәфтәр.<br>- Нинди дәфтәр?<br>- Зур (матур,кечкенә,чиста), ак (кара,кызыл,яшел,зәңгәр, сары) дәфтәр.<br>- Ничә дәфтәр?<br>- Алты (1-10)дәфтәр. | Аудиоязма №61-63<br>Дәфтәрдә эш №19<br><br>Мультфильм: “Урман мәктәбендә”<br><br>Аудиоязма №64 | 79-81 |
| Өстәл театры “Теремкәй” | Терем-терем, теремкәй,<br>Зур түгел, кечкенә.<br>Теремкәйдә тычкан яши.<br>Теремкәйдә куян яши.<br>Теремкәйдә бүре яши.<br>Теремкәйдә төлке яши.<br>Теремкәйдә аю яши.<br>Алар бик дус. | Мультфильм: “Теремкәй” | 82-84 |
| Өстәл театры : | -Кәҗә кая?<br>-Әнә, кәҗә кәбестә ашый. Кәҗә кәбестә ярата. | Аудиоязма №65-66<br><br>Мультфильм: “Кем нәрсә ярата?” | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| “Кем нәрсә ярата?”<br><br><br><br><br><br><br>“Белем иленә сәяхәт” | -Мин ипи яратам. Песи, син нәрсә яратасың?<br>-Мин сөт яратам. Сөт тәмле.<br><br>-Мә, кәҗә, ботка аша.<br>-Юк, кәбестә яратам. Кәбестә тәмле.<br><br>Алдагы үткән темалар лексикасы һәм сөйләм үрнәкләрен кабатлау. | Аудиоязма №67 - 72<br>Дәфтәрдә эш №20 | 85-101 |

**МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРНЫҢ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ СӨЙЛӘШӘ (АРАЛАША) БЕЛҮ КҮНЕКМӘЛӘРЕН ТИКШЕРҮ.**

**Тикшерү үткәрү буенча киңәшләр.**

Балаларның татар телендә аңлау һәм сөйләшә (аралаша) белү күнекмәләрен уку елы башында (октябрь ае) һәм уку елы ахырында (апрель аенда) тикшерелә. Уртанчылар төркеме балалары белән тикшерү уку елы ахырында үткәрелә. Уку елы уртасында тематик тикшерү (декабрь, январь) үткәререгә мөмкин.

Тикшерүне һәр бала белән аерым, 1 – 2 бала катнашында, ә йомгаклау эшчәнлеге булганда барлык балалар белән бергә дә үткәрергә була. Тикшерү вакыты 10-15 минутан артмаска тиеш.

Биремнәр балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып үткәрелә, уен-бирем рус телендә аңлатыла. Биремнәр мавыктыргыч һәм кызыклы булырга тиеш. Сораулар ачык, төгәл итеп, интонация белән бирелә.Тикшерүче балаларның җавабын тыңлаганда елмаеп, кирәк булса җавапны дөресләп, бала әйтә алмаганда булышырга тиеш.

Тикшерү барышында яңа материал бирелми. Тикшерүне эш дәфтәрләре, таратма, күрсәтмә рәсемнәр, интерактив тактада уеннар кулланып үткәрергә дә була.

Биремнәр, уеннар өчен кирәк булган күрсәтмәлелек алдан әзерләнеп куелган булырга тиеш. Тикшерүче һәр биремгә аерым балл куеп бара. Тикшерү ахырында баллар саны кушыла һәм 5 кә бүленә. Шулай итеп гомуми нәтиҗә ясала.

**Уку елы ахырында уртанчылар, уку елы башында зурлар төркеме балаларының “Минем өем” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| № | Баланың фамилиясе, исеме | Биремнәр | | | | | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **баллар** | **дәрәҗә** |
| | | “Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча дүрт – биш рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”) | Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч) | Тирә - юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану. | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сарап алу, тәкъдим итү, инкарь иү, раслау) | | |
| 1. | Коля | | | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, сорауларга җавап бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, аралашуда бик үк актив түгел. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**Балаларның татар телендә аралаша белү дәрәҗәсен тикшергәндә кулланырга мөмкин булган биремнәр.**

1. “**Минем өем” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**

***<u>1.</u>*** ***<u>Дидактик уен. "Бу кем?"</u>*** *<u>(I вариант)</u>*

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай)

Уен эчтәлеге: Өй рәсеме. Өй тирәсендә гаилә әгъзалары рәсемнәре (комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр). Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый: Бу кем? ("Әни"...).

***2. Дидиктик уен "Кем юк?"*** *(II вариант)*

(Лексика шул ук).Уен шул ук рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче бер рәсемне алып куя. Баладан сорый: "Кем юк?" ("Әби"...)

Уенны интерактив тактада да, бала белән бала арасында диалог формасында да үткәрергә була)

***3. Дидактик уен "Кәрзиндә нәрсә бар?"***

(Лексика: ипи, алма, сөт, чәй)

Уен эчтәлеге: Мияу кәрзин белән ашамлыклар алып килгән. Мияу ашамлык муляжларына күрсәтә, исемен сорый: "Бу нәрсә?" ("Алма"...)

***4. Дидактик уен "Нәрсә юк?"***

Мияу бер ашамлык муляжын яшереп куя: "Нәрсә юк?". Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. ("Алма"...) Уенны рәсемнәр кулланып та үткәреп була.

***5. Дидактик уен "Мин әйтәм, син күрсәт һәм әйт"***

(Лексика: әти, әни, кыз, малай, әби, бабай; куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи, ипи, алма, сөт, чәй).

Уен эчтәлеге: Балага уенчык яисә уенчык рәсемнәре бирелә. Бала, тәрбияче әйткән уенчыкны яисә уенчык рәсемен табып күсәтергә һәм исемен кабатлап әйтергә тиеш.

***6. Дидактик уен "Исемен әйтсәң бирәм"***

(Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)

Уен эчтәлеге: Тәрбияче өстәлендә уенчыклар яисә рәсемнәр. Тәрбияче балага уенчыкны(рәсемне) күрсәтә, сорый: "Бу нәрсә?"- "Алма"... ; "Бу кем?"-"Әти"... Бала уенчык исемен дөрес әйтсә аңа уенчыклар, яисә таратма рәсемнәр бирелә.

***7. Дидактик уен "Серле янчык"***

(Лексика: куян, аю, туп, машина, курчак, эт, песи)

Уен эчтәлеге: Балага уенчыклар күрсәтелә, исемнәрен әйтеп янчыкка салына. Бала янчыктагы уенчыкны капшап исемен әйтә, алып күрсәтә.

***8. Дидактик уен "Әйе-юк"***

Сүзнең дөрес үзләштерелүен тикшерү йөзеннән (аңлап яки аңламыйча әйтү) төрле вариантта сораулар бирелә: "Бу нәрсә?" - "Аю"...; "Бу аю?" - "Әйе, аю"...; "Бу куян?" - "Юк, песи"...

**Югары балл (2.7-3)** — сүз байлыгы җитәрлек, уенчык, әйберләрне үзлектән, аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә.

**Уртача балл (2-2,6)** - сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

**Уртачадан түбән балл (1-2)** - аңлый, русча җавап бирә.

**2. Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”).**

***Ситуатив күнегүләр:***

а) Ситуатив күнегү “Куян аюга кунакка килә”. Ул ишектән кергәндә аюга нәрсә әйтә? (Ничек исәнләшә?), "Исәнме аю".

б) Ситуатив күнегү “Куян аюда кунакта булды”. Ишектән чыгып киткәндә куян аю белән ничек саубуллаша? (Нәрсә әйтә?) "Сау бул, аю".

в) Уен ситуациясе "Кунак сыйлау". Акбайда (Мияуда) кунакта.

Тәрбияче Акбай (Мияу) ролендә. Ул баланы, ашамлык, җиләк-җимеш (алма, груша, банан һ.б.) муляжлары белән "сыйлый". Тәрбияче баланың "рәхмәт" әйтә белүен билгели.

г) Уен ситуациясе "Дустыңны сыйла". Балаларны парлаштырып бер-берсен сыйларга тәкъдим итү. Рәхмәт әйтә белүләрен билгеләү.

д) Ситуатив күнегү "Акбайга ("Мияуга", "Курчакка", "Дустына") уенчык бүләк ит".

**Югары балл (2,7-3)** - бала ситуацияләрдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.
**Уртача балл (2-2.6)** - тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.
**Уртачадан түбән (1-2)** - аңлый, сорауга җавапны русча әйтә.

**3. Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч).**

**1. Сүзле уен "Мин әйтәм - син эшлә" ("Командир").**

**2. Сүзле уен "Шаян уенчыклар"** (Уен баланың боерыкларны аңлы рәвештә үтәвен тикшерү өчен бирелә. Уенның эчтәлеге: Тәрбияче уенчыкка боерык бирә, мәсәлән: Утыр! Ә уенчык “ашый” башлый. Бала боерыкны дөрес итеп үтәп күрсәтә).

**Югары дәрәҗә (2,7-3)** - бала боерыкны аңлап, дөрес үти.
**Уртача дәрәҗә (2-2,6)** - ялгыша.
**Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)** - татарча аңламый, боерыкларны үтәми.

**4.Тирә-юньдәге предметларның сыйфат билгеләрен, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану.**

***1. Дидактик уен "Уенчык нинди?" (зур, кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур).***

Уен эчтәлеге: зур-кечкенә уенчыклар күрсәтелә. Тәрбияченең "Нинди?" соравына бала уенчыкның исемен сыйфат билгесе белән әйтергә тиеш.

-Нинди курчак? - Зур (кечкенә, чиста, пычрак, әйбәт, матур) курчак.

Эш дәфтәрендәге 11 нче биремне кулланып була.

2. ***Дидактик уен "Тап, күрсәт һәм әйт"*** ***(чиста, пычрак).***

Комплекттагы күрсәтмә рәсемнәр кулланып үткәрелә. Тәрбияче әйткән рәсемне бала табып күрсәтә, әйтә.("Чиста туп", "Пычрак аю"...).

Эш дәфтәрендәге 13 нче биремне кулланып була.

**3.** ***Дидактик уен "Курчакка бүләк".***

Тәрбияче зур курчакка- зур туп, кечкенә курчакка- кечкенә туп бүләк итәргә куша. “ Мә, зур туп ", “Мә, кечкенә туп".

**4.** ***Дидактик уен "Дөрес сана".***

Санау күнекмәләрен билгеләү (1-5 кадәр). Тәрбияче уенчыклар, муляжлар санарга тәкъдим итә. Төркемдәге балаларны да санарга була. "Ничә малай?", "Ничә кыз?".

**5.** ***Дидактик уен "Ничә?".***

Санау күнекмәләрен тикшерү өчен шулай ук, укыту методик комплектындагы күрсәтмә рәсемнәрне дә кулланып була.

\- Ничә туп? - Биш туп.

**Югары дәрәҗә (2,7-3)** - әйберләрнең сыйфат билгеләрен, күләмен исем белән кушып дөрес әйтә.

**Уртача дәрәҗә (2-2.6)** - 1-2 билгесен әйтә.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)** - әйберләрнең билгеләрен, күләмен рус телендә әйтә.

**5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сарап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау).**

***1. Уен ситуациясе "Әйдәгез танышабыз".***

"Син кем?" соравына аңлап җавап бирүе билгеләнә. К нам пришла новая кукла, она хочет с вами познакомиться: - Исәнмесез. Мин Алсу. Син кем? (Мин Оля (Коля). -Мин Алсу, мин кыз. Син кыз? (Юк, мин малай (әйе, мин кыз).

***2.Уен ситуациясе "Кунак каршылыйбыз ".***

а) Тәрбияче: К нам идут гости.

***Спроси. "Кто там?". "Кем анда?"*** - Мин әби (бабай).

***"Позови бабушку (дедушку)".*** - Әби (бабай) кил монда.

***"Поздоровайся с бабушкой (дедушкой)"*** - Исәнме, әби (бабай).

***"Спроси у бабушки (дедушки) как дела?"*** - Әби (бабай) хәлләр ничек? - Әйбәт, рәхмәт.

***"Предложи бабушке (дедушке) сесть".*** - Әби (бабай) утыр.

***"Предложи бабушке (дедушке) пить чай"*** - Мә, чәй, эч.

***Скажи: "До свидания!"*** Сау бул, әби! (бабай).

б) Балага "кунак" белән исәнләшергә, хәлен сорарга, чакырып утыртырга, сыйларга ("аша,эч") һәм саубуллашырга тәкъдим итеinä.

Эш дәфтәрендәге 3 нче биремне кулланып була**.**

***1. Уен ситуациясе "Кунакларны сыйла".***

***Угости Акбай хлебом, Мияу молоком***.

-Мә, Акбай ипи, аша. - Рәхмәт.

-Мә, Мияу сөт, эч. - Рәхмәт.

Эш дәфтәрендәге 16 нчы биремне кулланып була**.**

***2. Уен ситуациясе "Бер - береңне сыйла ".***

*(Ашамлык муляжлары кулланып)* ***"Угости яблоком".***

- Мә, алма, аша. - Рәхмәт.

***"Спроси, яблоко вкусное?"***

- Алма тәмле? - Әйе, тәмле.

Эш дәфтәрендәге 6 нчы биремне кулланып була**.**

***3. Уен ситуациясе "Уенчыклар илендә"***

***1 . Ты пришел в магазин игрушек. Попроси игрушку, которая тебе нравится***.

-Куян бир (әле).- Рәхмәт.

***2. Предложи поиграть с игрушкой.***

- Мә, туп, уйна. - Рәхмәт.

***3. Позови друга, предложи помыть игрушку.***

-Коля, кил монда. - Мә, туп, ю.

***4. Поменяйтесь игрушками. Попроси у друга игрушку, предложи ему свою .***

- Коля, туп бир - Мә, туп. - Рәхмәт.

**Югары дәрәҗә (2,7-3)** - аралаша, сөйләм күнекмәләрен актив куллана.

**Уртача дәрәҗә (2-2,6)** - тәрбияче ярдәмендә аралаша.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1-2)** - аңлый, русча җавап бирә.

**Уку елы ахырында зурлар, уку елы башында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| № | Баланың фамилиясе, исеме | Биремнәр | | | | | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | **1** | **2** | **3** | **4** | **5** | **баллар** | **дәрәҗә** |
| | | “Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “сау бул”, “рәхмәт”. “исәнмесез”, “ сау булыгыз”) | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) | | |
| 1. | Коля | | | | | | | |
| 2. | Оля... | | | | | | | |

**Нәтиҗәләрне билгеләү**

| | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**“Уйный – уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану.**
**(Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)**

***1. Дидактик уен “Бу нәрсә?”***

(Лексика: аш, ботка, сөт, кашык, тәлинкә, чынаяк).

Уен эчтәлеге: Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый:

Бу нәрсә? (“Аш”...)

***2. Дидактик уен “Кәрзиндә нәрсә бар?”***

(Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).
Уен эчтәлеге: Куян кәрзин белән яшелчәләр һәм җиләк-җимеш алып килгән. Куян сорый: “Нәрсә бар?” (“Кәбестә”...)

3. ***<u>Дидактик уен “Нәрсә юк?”.</u>***

(Лексика: кишер, суган, бәрәңге, кыяр, кәбестә, алма).
Куян бер яшелчә муляжын яшереп куя: “Нәрсә юк?”. Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. Уенны рәсемнәр кулланып та үткәрергә була.

4. ***<u>Дидактик уен “Дөресен әйт”.</u>***

(Лексика: күлмәк, чалбар, сарафан, өстәл, урындык, карават).
Уен эчтәлеге: Балага рәсемнәр бирелә. Бала рәсемнәрнең исемен атый һәм күрсәтә.

**<u>Югары балл (2.7-3)</u>** — сүз байлыгы җитәрлек, яшелчәләр, савыт-сабалар, киемнәр, өй җиһазлары атамаларын аңлап дөрес күрсәтә, исемнәрен әйтә һәм куелган сорауларга җавап бирә.

**<u>Уртача балл (2-2,6)</u>** - сүз байлыгы бар, кайбер сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

**<u>Уртачадан түбән балл (1-2)</u>** - аңлый, русча җавап бирә.

### 2. Ягымлы сүзләр куллану (“Исәнме”, “Сау бул”, “Рәхмәт”, “Исәнмесез”, “ Сау булыгыз”).

***Ситуатив күнегүләр (уртанчылар төркемендәге ягымлы сүзләр бүлеген кара):***

а) Поздоровайся с Акбаем.
б) Спроси как дела у Акбая.
в) Скажи спасибо Акбаю. Спроси как дела.
г) Попрощайся с Акбаем.
д) Поздоровайся с воспитателем, Мияу и Акбай.
е) Попрощайся с воспитателем, Мияу и Акбай.

**<u>Югары балл (2.7-3)</u>** — бала сөйләмдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.

**<u>Уртача балл (2-2,6)</u>** – уен ситуацияләрен тәрбияче ярдәмендә төзи.

**<u>Уртачадан түбән балл (1-2)</u>** – аңлый, җавап бирә алмый.

### 3. Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал).

Балаларның боерыкларны бирә белү күнекмәләрен тикшерү. Балалар бер-берсенә боерык бирәләр. Саша, аша! – Саша ашау хәрәкәтләре күрсәтә. Алга таба Саша үзе башка балага боерык бирә һәм шундый тәртиптә дәвам итетелә.
(Лексика: кил, утыр, сикер, ю, аша, эч, уйна, ки, сал).

**<u>Югары балл (2,7-3)</u>** – 8-9 сүз.
**<u>Уртача балл (2-2.6)</u>** – 5-6 сүз.
**<u>Уртачадан түбән (1-2)</u>** – 1-2 сүз.

**4. Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).**

***<u>1. Сюжетлы-рольле уен "Кибет"</u>***

Балаларга рус телендә кибет уены үткәрү аңлатыла һәм өч төп сорауны куя белүләрен максат итеп куясың. Уен ямшелчә, киемнәр, савыт-саба, өй җиһазлары рәсемнәре кулланып үткәрелә.
(Лексика: Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).

***2. <u>Дидактик уен "Нинди?".</u>***

Тикшерүдә сорауларны аерым кулланып та үткәрергә була.
Әйберләрне билгесен ачыклау өчен бирелә торган сораугa аңлап җавап бирү һәм ул сорауларны үзлектән куя белү.
(Лексика: нинди? кызыл, сары, яшел, зәңгәр).

**3.** ***<u>Дидактик уен "Ничә?".</u>***

Санау күнекмәләрен билгеләү (1- 10 кадәр).

*4.* ***<u>Дидактик уен "Дөрес сана".</u>***

Тәрбияче уенчыклар, муляжлар, укыту методик комплектындагы күрсәтмә рәсемнәрне санарга тәкъдим итә. Балалар бер-берсенә сорау бирәләр һәм җавап бирәләр. Шулай ук, сорауны тәрбияче үзе дә бирә ала. *"Ничә...?"*.

**<u>Югары балл (2,7-3)</u>** – диалогта 3 сорауны да аңлап куллана.
**<u>Уртача балл (2-2.6)</u>** – диалогта 2 сорауны аңлап куллана.
**<u>Уртачадан түбән (1-2)</u>** – диалогта 1 сорауны аңлап куллана.

**5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкаръ итү, раслау).**

***<u>1. Уен ситуациясе "Әйдәгез танышабыз".</u>***

"Син кем?" соравына аңлап җавап бирүе билгеләнә.
К вам пришла новая кукла, она хочет с вами познакомиться:
- Исәнмесез. Мин Алсу. Син кем? (Мин Оля яки Коля).
- Мин Алсу, мин кыз. Син кыз? (Юк, мин малай).

***<u>2. Уен ситуациясе "Кунак каршылыйбыз".</u>***

а) Тәрбияче:

- К нам идут гости. Спроси. “Кто там?”. “Кем анда?”
- Мин Акбай.
- Позови Акбая.
- Акбай,  кил монда.

б) У Акбая сегодня день рождение. Подари свою игрушку
- Акбай, мә кызыл туп.
- Рәхмәт.

в) Угости гостей супом или кашей.
- Мә, аш (ботка) (аша).

г) Что бы сьесть угощение попроси ложку.
- Кашык бир.
- Нинди кашык?
- Зур, матур, зәңгәр кашык.
- Рәхмәт.

3. ***<u>Уен ситуациясе “Кибеттә”.</u>***

Бала белән бала аралашуы тикшерелә.

- Исәнме! Хәлләр ничек?
- Әйбәт, рәхмәт.
- Аю бир.
- Нинди аю?
- Зур аю, чиста аю, матур аю.
- Ничә?
- Ике аю.
- Мә, ике аю.
- Рәхмәт.
- Сау бул.

**<u>Югары балл (2,7-3)</u>** – бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.
**<u>Уртача балл (2-2.6)</u>** – сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.
**<u>Уртачадан түбән (1-2)</u>** – аңлый, русча җавап бирә.

**Уку елы ахырында мәктәпкә әзерлек төркеме балаларының**
**“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү.**

| № | Баланың фамилиясе, исеме | Биремнәр | | | | | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | баллар | дәрәҗә |
| | | “Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану (“исәнме”, “исәнмесез”, “сау бул”, “сау булыгыз”, “рәхмәт”, “зур рәхмәт”, “хәерле көн”, “хәлләр ничек?”, “әйбәт”) | Боерыкны бирә белү (кил, утыр, сикер, уйна, ю, аша, эч, ки, сал, бие, жырла, йөгер, йокла) | Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау куя белү. (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?) | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь иү, раслау) | | |
| 1. | Коля | | | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | | | |

| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | |
|---|---|
| Югары дәрәҗә 2,7 дән 3 кә кадәр | Бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша. |
| Уртача дәрәҗә 2 дән 2,6 га кадәр | Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша. |
| Уртачадан түбән дәрәҗә 1 дән 2 гә кадәр | Аңлый, русча җавап бирә. |

**1.“Без инде хәзер зурлар, мәктәпкә илтә юллар” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча биш – алты рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла)**

1. ***<u>Дидактик уен “Бу нәрсә?”</u>***

(Лексика: тычкан, бүре, төлке, керпе, тавык, әтәч, үрдәк, аю).
Уен эчтәлеге: Тәрбияче рәсемнәргә күрсәтеп сорый:
- Бу нәрсә? (“бүре”...)

2. ***Дидактик уен "Портфельдә нәрсә бар?"***

(Лексика: китап, дәфтәр, рәсем, мәктәп).

Уен эчтәлеге: Тәрбияче портфельдән рәсемнәр яки предмет алып күрсәтә, исемен сорый:

- Портфельдә нәрсә бар?- ("Дәфтәр бар"...)

3. ***Дидактик уен "Портфельдә нәрсә юк?"***

Бала нәрсә юклыгын әйтергә тиеш. Уенны рәсемнәр кулланып та үткәрергә була.

4. ***Дидактик уен "Дөресен әйт"***

(Лексика: чәк- чәк, өчпочмак, бәрәңге, аш, ботка, су).

Уен эчтәлеге: Балага рәсемнәр бирелә. Бала рәсемнәрне атый.

**Югары балл (2.7-3)** — 10-14 сүз.

**Уртача балл (2-2,6)** – 7-9 сүз.

**Уртачадан түбән балл (1-2)** – 1-6 сүз.

**2. Ягымлы сүзләр куллану**

**("Исәнме", "Исәнмесез", "Сау бул", "Сау булыгыз", "Рәхмәт", "Зур рәхмәт", "Хәерле көн","Хәлләр ничек?", "Әйбәт")**

***Ситуатив күнегү:***

Телефоннан сөйләшү.

Эш дәфтәрендәге 1 нче биремне кулланып була.

**Югары балл (2,7-3)** — бала сөйләмдә ягымлы сүзләрне урынлы куллана.

**Уртача балл (2-2,6)** – тәрбияче ярдәмендә җавап бирә.

**Уртачадан түбән балл (1-2)** – аңлый, сорауларга җавапны русча бирә.

**3. Боерыкны бирә белү.**

(Лексика: кил монда, утыр, сикер, ю, аша, эч, уйна, ки, сал, йөгер, бие, җырла, йокла).

***Дидактик уен: "Командир"***

Эш дәфтәрендәге 9 нчы биремне кулланып була.

Бер бала икенче балага боерык бирә. Мәсәлән:

-Коля, сикер! (Коля сикереп күрсәтә).

-Коля, син нишлисең?(Колядан сорый) – Мин сикерәм.

-Коля нишли? (Башка баладан сорый) – Коля сикерә.

**Югары балл (2,7-3)** — 11-13 сүз белән боерык бирә, син нишлисең, нишли сорауларын бирә белә.

**Уртача балл (2-2,6)** – бары боерык бирә, сорауларны куя алмый.
**Уртачадан түбән балл (1-2)** – 1-5 сүз белән боерык бирә, сорауларны русча әйтә.

**4. Уен ситуацияләрендә үзлектән сорау бирә белү.**
**(Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә? Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли? Кая барасың?)**

***1. Уен ситуацияләре:***

а) “Кибет” (Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?)
б) “Телефоннан сөйләшү” (Кая барасың? Син нишлисең?)
в) “Танышу” (Син кем? Бу кем? Бу нәрсә? Нишли?)

***2. Сюжетлы-рольле уен “Кибет”***

Балаларга рус телендә кибет уены үткәрү аңлатыла һәм өч төп сорауны куллана белүләре тикшерелә.Уен яшелчә, киемнәр, савыт-саба, өй җиһазлары, йорт кошлары, уенчык рәсемнәре кулланып үткәрелә.
(Лексика: Нәрсә кирәк? Нинди? Ничә?).

***3.Дидактик уен “Нинди?”.***

Тикшерүдә сорауларны аерым кулланып та үткәрергә була.
(Лексика: кызыл, сары, яшел, зәңгәр, ак, кара).

**4. *Дидактик уен “Сана”.***

Санау күнекмәләрен билгеләү (1- 10 кадәр).
**Югары балл (2,7-3)** – сорауларны аңлап куллана.
**Уртача балл (2-2,6)** – аңлый, тәрбияче ярдәме белән куллана.
**Уртачадан түбән (1-2)** – русча җавап бирә.

**5. Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау)**

***1. Уен ситуациясе “Әйдәгез танышабыз”***

- Исәнмесез. Син кем? - (Мин Оля яки Коля).
- Мин кыз. Син кыз? - (Юк, мин малай).
- Синә ничә яшь?- (6 (7) яшь).

***2.Уен ситуациясе “Телефоннан сөйләшү”.(диалогны сан, сыйфат, күләм берәмлеге кертеп баетырга була)***

- Исәнме. Хәлләр ничек?
- Әйбәт.
- Нишлисең?

- Мин уйныйм. Син нишлисең?
- Мин ашыйм.
- Нәрсә?
- Алма ашыйм.
- Алма тәмле(ме)?
- Әйе, алма тәмле.
- Сау бул.

***3.Уен ситуациясе “Кая барасың?”*** (*мәктәп, кафе, цирк һ.б.*)
- Исәнме! Хәлләр ничек?
- Әйбәт, рәхмәт.
- Кая барасың?
- Кафега барам.
- Кафеда нәрсә бар? (ашамлыклар атарга мөмкин)
- Саша нишли?
- Саша бәрәңге ашый.

4.***Ситуатив күнегү.***

а) Син нишлисең?
- Мин биим (утырам, сикерәм, ашыйм, эчәм, уйныйм, йөгерәм, җырлыйм, йоклыйм).

**Югары балл (2,7-3)** – бала сөйләмдә актив, үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.
**Уртача балл (2-2.6)** – сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.
**Уртачадан түбән (1-2)** – аңлый, русча җавап бирә.

**Туган телгә өйрәтү, сөйләм үстерү юнәлеше буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру төрләре:** Балалар бакчасында татар балаларына туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек конспектлары Н.Е.Веракса,Т.С.Комарова, М.А.Василҗева редакциясендә чыккан “ Туганнан алып мәктәпкә кадәр.Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы” нигезендә төзелгән.Федераль дәүләт таләпләре буенча өч белем бирү өлкәсе: танып белү, коммуникация ( сөйләм үстерү), матур әдәбият белән таныштыру карала. Белем бирү өлкәләрен үзләштерү гомум кабул ителгән педагогик принципларга нигезләнә. Эшчәнлек конспеклары үстерешле белем бирү, белем бирү барышында тәрбияләү, фәннилек, эзлеклелек һәм системалылык, аңлаешлылык,балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алу, гуманлылык, күрсәтмәлелек һ.б. төп педагогик принципларга таянып эшләнде. Гуманлылык принцибын исәпкә алып, белем бирү процессы бала шәхесен ихтирам итүгә һәм психологик якланганлык хисләре булдыруга юнәлдерелә.Белем бирү нәтиҗәсендә белемнәр үзләштерелеп, күнекмәләр генә формалаштырылып калмый, ә тоемлау, аңга алу, хәтер, игътибар, сөйләм, фикерләү белән бәйләнешле барлык танып белү процесслары да, шулай ук
ихтыяр һәм эмоцияләр дә үстерелә- бала шәхесенең төрле яклы үсеше алып барыла.

Эшчәнлек төрләрендә сөйләмдә **сүзлек эше, сөйләмнең грамматик төзелеше өстендә эш, аваз культурасы тәрбияләү,бәйләнешле сөйләм үстерү, матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру** бурычлары хәл ителә.

**Сүзлек өстендә эш** – бәйләнешле сөйләм нигезе.

- Гомуми кулланылыштагы лексика хисабына ( предметларны, аларның төп билгеләрен, сыйфатларын, эш- хәрәкәтләрен атау) сүзлекне баету.
- Сүзлеккә төгәллек кертү. Балаларга сүзне әйтү үрнәген бирү, аны һәр бала белән күп тапкыр кабатлау.
- Сүзлекне активлаштыру.

**Сөйләмнең грамматик төзелешен формалаштыруның төп шарты-** тәрбиятенең, өлкәннәрнең грамоталы сөйләме һәм сөйләмнең морфологик, синтаксика ягын, сүз ясалу ысулларын үзләштерү буенча торган күнегүләр.

**Аваз культурасы тәрбияләү** буенча эш аның сөйләм сулышын, ишетеп аңга алу, артикуляция аппаратын үстерү һ.б. шундый компонентларны үз эченә ала.

**Бәйләнешле сөйләм үстерү** сөйләмнең ике формасын – диалогик һәм монологик сөйләмен үстерүне күздә тота. Диалогик сөйләм үстерүдә сорау- җавап формасы, балаларның үзләренең сорау бирә, бер- берсенә мөрәҗәгать итә белүе – иң отышлы формалар. Балаларның кечкенә хикәяләрне мөстәкыйль төзи белүе монологик сөйләм барлыкка килүдә мөһим күрсәткеч булып тора. Балаларны **матур әдәбият һәм халык иҗаты белән таныштыру** – сөйләм үсешенең әһәмиятле чарасы. Дөньяны бербөтен итеп кабул итү, беренчел күзаллаулар формалаштыру. Әдәби сөйләм үстерү. Сөйләм сәнгатенә якынайту, шул исәптән эстетик зәвык, әдәби әсәрне аңга алуларын үстерү.

**Беренче кече яшьтәге (2-3 яшь)** балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасы мәктәпкәчә яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеген оештыру системасыннан аерыла. Балаларны туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү әйләнә-тирә белән таныштыру процессында бара. Шушы үзенчәлекләрне исәпкә алып, кече яшьтәге балаларның сөйләм эшчәнлеге эчтәлеген төзегәндә әйләнә-тирә предметларны һәм күренешләрне танып белүдә нәрсә чыганак булып торуы игътибар үзәгенә алына. Балаларның сөйләмен үстерү "Кроха" программасында (Г.Г. Григорьева, Н.П. Кочетова, Д.В. Сергеева һ.б.) күрсәтелгән түбәндәге эшчәнлек төрләренә нигезләнеп төзелә:

I. Табигый шартларда табигать һәм социаль тирәлек белән турыдан туры таныштыру.

1. Табигатьне (күренешләрне һәм объектларны) күзәтү.

2. Предметлы дөнья белән таныштыру: предметлар һәм кораллар (исеме, сыйфаты, үзлекләре, эш-хәрәкәтләре).

3. Социаль күренешләр (үзең, якын кешеләр, өлкәннәр хезмәт турында күзаллаулар) белән таныштыру.

II. Образлы уенчыклар, пластик художестволы образлар аша тирә-юнь белән белән таныштыру

1. Уенчыклар карау.

2. "Тылсымлы капчык", "Бу өйдә кем (нәрсә) яши?" дидактик уеннары, курчак белән дидактик уеннар.

3. Уеннар, күңел ачулар, уен-көлкеләр.

4. Йомыш кушулар (индивидуаль һәм кечерәк төркемнәргә бүлеп).

III. Художество картиналары аша (живописный, графический художественный образ) (буяулар һәм буяусыз ясалган образлар (графика) әйләнә-тирә белән таныштыру.

1. Өстәлгә куела торган кечкенә картиналарны, китаптагы иллюстрацияләрне, стенадагы картиналарны карау.

2. "Җанлы" кечкенә картиналар белән эшчәнлек.

IV. Нәфис сүз аша әйләнә-тирә белән таныштыру.

1. Матур әдәбият, юаткычлар, шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр уку.

2. Тәрбияче белән бергә кыска гади әкиятләрнең эчтәлеген сөйләү.

V. Күрсәтмәлелектән башка тирә-юнь белән таныштыру һәм сөйләм үстерү.

1. Күрсәтмәлелектән башка һәм ситуциядән тыш тәрбияченең сөйләве.

2. Балалар белән әңгәмәләр һәм сөйләшүләр (тәҗрибәдән чыгып, күзәтүләрдән соң).

Федераль дәүләт таләпләреннән чыгып, методик әсбапта танып белү, коммуникация, матур әдәбият белән таныштыру кебек өч белем бирү өлкәсе карала. Балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы-тематик планлаштыру нигезендә бара. План ел дәверендә төрле темалар үзләштерүне күздә тота. Болар - "Балалар бакчасы", "Көз", "Мин дөньяның бер кешесе", "Минем әйләнә-тирәм", "Кыш", "Яңа ел бәйрәме", "Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр", "Халык иҗаты", "Яз", "Җәй".

## Танып белү. Эшчәнлек оештыру конспектлары.
## Белем бирү өлкәләре. ( Беренче кече яшьтәге балаларга( 2-3 яшь)

| Сроклар | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| **20.08 - 10.09.** | **Безнең бакча** | “Чишенү бүлмәсен карау” | Балаларны чишенү бүлмәсе, аның билгеләнеше, андагы җиһазлар белән таныштырырга, группадагы бүлмәләрдә ориентирлашу тәҗрибәсе тупларга. Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, диалогта катнашу теләген үстерергә. Җиһазларга сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | Йомшаккай бездә кунакта | Балаларның группадагы уенчыклар турындагы белемнәрен киңәйтергә, тәрбияче сорауларына җавап бирү осталыгы формалаштырырга, уенчык исемнәре һәм аларның эш-хәрәкәтен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлек запасын киңәйтергә. Тыңлау һәм сорауларга җавап бирү теләге үстерергә. Сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | Йомшаккай тагын бездә кунакта. | Балаларны уенчыкларны карарга һәм аларның аерым өлешләрен билгеләргә өйрәтергә; уенчыкларның өлешләре исемнәрен, төсен, хәрәкәтен белдерә торган сүзләрне актив сүзлеккә кертергә. Тәрбияче соравына кычкырып җавап бирү осталыгын үстерергә. Сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте, көлкеле уенчыклар белән уйнаудан канәгатьләнү, шатлану хисләре тәрбияләргә.. |
| | | Е.Батуринаның “Тупны коткарабыз” картинасын карау. | Картинаның эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә; аның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтергә. Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, тәрбияче артыннан аерым сүзләрне һәм фразаларны актив кабатлауларын үстерергә. Башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләргә. |
| | | Юыну бүлмәсен карау. | Балаларның юыну бүлмәсендәге предметларның (сабын, сөлге, кран, су, теш щеткасы, теш пастасы) функциональ билгеләнеше турындагы күзаллауларын ачыкларга. Сүзләрне (сабын, сабынны, сабын белән һ.б.)төрле грамматик формаларда куллану осталыгын, сөйләм активлыгын, инициативасын үстерергә. Балаларда сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте, пөхтәлек, чисталык, башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләргә. |
| **11.09.- 30.09.** | **Көз** | Көзге табигать. | Көз турында балаларның элементар күзаллауларын (табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр, кешеләр киеме) формалаштырырга. Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, тәрбиячене тыңлый белү осталыгын үстерегә. Көзге табигатькә соклану хисләре тәрбияләргә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Җиләк-җимешләр. | Тышкы билгеләре һәм тәме буенча җиләк-җимешләр аерырга өйрәтергә; җиләк-җимешләр һәм аларның уңышын җыеп алу турында күзаллауларын киңәйтергә, җиләк-җимешләрнең исемнәре һәм аларнын билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баетырга.<br>Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, сенсор сәләтләрен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Балаларда сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте**,** әйләнә-тирә табигать объектларына кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | “Безнең Алсу” сериясеннән картина карау. | Картинадагы предметларны аера һәм атый, картинаның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә белергә өйрәтергә, сүзлекне активлаштырырга.<br>Балаларның игътибарын, хәтерен, тәрбияче күрсәтмәләрен ишетә һәм үти белүләрен үстерергә.<br>Картинаны кызыксынып карау теләге тәрбияләргә. |
| | | Помидор, кыяр, кишер белә[н] таныштыр[у] | Балаларның помидор, кыяр, кишер турындагы белемнәрен ныгытырга; помидор, кыяр, кишернең форма, төс, тәм үзенчәлекләре (кызыл, йомшак, шома, тәмле, сусыл, хуш исле помидор, помидор шар формасында; яшел, каты, шома, кытыршы кыяр; шома, кызыл, тәмле, каты кишер) белән таныштырырга.<br>Балаларның сенсор тоемлауларын, тәрбиячене ишетү һәм сорауларга җавап бирә белү осталыкларын үстерергә.<br>Балаларда сөйләм этикетының гади формулаларын (исәнләшү, саубуллашу) куллана белү гадәте**,** зурлар хезмәтенә хөрмәт, сәламәт тормыш алып бару теләге тәрбияләргә. |
| | | Картинкадагы кошларны карау. | Балаларда күгәрчен, саескан турында гомуми күзаллаулар булдырырга; аларның кызыклы гадәтләрен күрергә өйрәтергә.<br>Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сүзлек запасын үстерергә.<br>Кошларга карата йомшак караш, дустанә мөнәсәбәт тәрбияләргә. |
| | | Көз (йомгаклау чарасы). | Балаларның көз турындагы белемнәрен (яфраклар саргая, сары яфраклар, яфраклар коела, яңгырлар күп ява, кешеләр җылы киемнәрен кияләр) ныгытырга. Тәрбияче сорауларына дөрес җавап бирергә, рәсем ясаганда буяуны кәгазь битенә дөрес һәм тигез төшерергә өйрәтергә. Төсләрне ныгытырга.<br>Балаларның актив сөйләмен, ишетеп кабул итүне, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерергә. Балаларда рәсем ясауга кызыксыну уятырга.<br>Көзге табигать белән соклану хисләре, пөхтәлек тәрбияләргә. |
| **1.10.-15.10.** | **Мин дөньяның бер кешесе** | Минем исемем бар | Баланы үзенең һәм иптәшләренең исемен әйтергә өйрәтергә, иптәшләренең исемен истә калдырырга, оялчанлыкларын җиңәргә ярдәм итәргә.<br>Тәрбияче әйткәнне ишетүдә һәм аңлауда, кайбер фразаларны (Минем исемем Алсу) кабатлауда күнектерергә. Балаларның хәтерен, игътибарын үстерергә.<br>Балаларда үзләренә һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык, дустанә мөнәсәбәт |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | тәрбияләргә. |
| | | Бу - мин. | Организм һәм аның өлешләре турында балаларда күзаллау формалаштырырга, балага үзен, бербөтен итеп кабул итәргә өйрәтергә, гәүдә өлешләре турында белемнәрне ачыкларга һәм ныгытырга.<br>Гәүдә өлешләренең атамалары (баш, күзләр, колаклар, борын, авыз, тешләр, чәчләр, куллар, аяклар) хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга.<br>Үзеңне, үзеңнең гәүдә өлешләрен ярату һәм сакчыл караш тәрбияләргә, культура-гигиена күнекмәләрен үтәү теләге тудырырга. |
| **16.10.-04.11.** | **Минем әйләнә-тирәм** | Яраткан уен бүлмәбез. | Балаларны балалар бакчасы шартларына ияләндерүне дәвам иттерергә, уен (группа) бүлмәсе һәм алдагы почмаклар белән таныштырырга, һәр әйбернең үз урыны дигән күзаллауны балаларның аңына җиткерергә.<br>Сүзләрне һәм кыска фразаларны ачык әйтүләрен үстерергә, сүзлекне активлаштырырга.<br>Җиһазларга сакчыл караш һәм яшьтәшләренә карата ягымлылык тәрбияләргә. |
| | | “КамАЗ” машинасы. | Балаларны “КамАЗ” машинасын һәм аның өлешләрен таный, атый белергә өйрәтергә, уенның сүзләренә туры китереп хәрәкәтләр ясау осталыгы булдырырга.<br>Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, хәтерен, сөйләмен, эмоциональ сферасын үстерергә.<br>Балаларда йөк транспортына, өлкәннәр хезмәтенә кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | “Минем урамым” “җанлы картинка”сын карау. | Балаларны урам һәм аның объектлары белән таныштырырга. аларга карата кызыксыну тудырырга.<br>Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, сүзлеген үстерергә.<br>Урамга соклану хисе тәрбияләргә. |
| **15.11.-31.12.** | **Яңа ел бәйрәме** | Электр лампасы белән таныштыру. | Электр турында балаларга элементар төшенчә (электр тогы электр чыбыкларында яши; утны яндыру өчен өзгечкә (выключатель) басарга кирәк, шуннан соң электр чыбыкларыннан ток йөри башлый) бирергә. Электр, ток, чыбык, өзгеч (выключатель) сүзләре хисабына сүзлекне киңәйтергә һәм активлаштырырга.<br>Балаларның игътибарын, хәтерен, кабул итүләрен үстерергә. Ток белән бәйләнешле булган куркынычсызлык кагыйдәләрен балаларга җиткерергә.<br>Сакчыллык тәрбияләргә. |
| | | Гирлянда. | Балаларга гирлянда турында элементар белемнәр бирергә, электр тогы турындагы күзаллауларын ныгытырга, кызыл, яшел, сары төсләрне таный һәм аера белүдә күнектерергә.<br>Балаларның игътибарын, кызыксынучанлыгын, сүзлеген һәм шатлану хисләрен үстерергә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Бергә шөгыльләнү теләге тәрбияләргә. |
| | | Яшел чыршы.<br>. | Балаларны чыршыны карарга өйрәтергә, Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларына төгәллек кертергә һәм баетырга.<br>Балаларның "Яңа ел бәйрәме" темасы буенча сүзлекләрен активлаштырырга, тәрбияче соравына җавап бирү осталыкларын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор сәләтләрен үстерергә.<br>Матурлыкны күрә һәм соклана белү хисләре, чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | Чыршы бизибез.<br>. | Балаларның Яңа ел бәйрәме турындагы күзаллауларын баетуны дәвам итәргә.<br>Балаларның "Яңа ел бәйрәме" темасы буенча сүзлекләрен активлаштырырга, тәрбияче соравына җавап бирү осталыкларын, игътибарын, күзәтүчәнлеген, сенсор сәләтләрен үстерергә.<br>Чыршы уенчыкларына карата сакчыл караш тәрбияләргә |
| | | Без музыка залында. | Чыршы бәйрәменә әзерләнү уңаеннан балаларны музыка залының бизәлеше, чыршы уенчыклары белән таныштырырга (материалы, төсе, формасы); чыршы уенчыклары, йомры, пыяла, шома, ялтырый сүзләре хисабына балалар сүзлеген активлаштыруны дәвам итәргә.<br>Балаларның кабул итүләрен, күзәтүчәнлеген, игътибарын, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Балаларда эстетик хисләр тәрбияләргә. |
| **01.01.-31.01.** | **Кыш** | Ап-ак кар ява. | Балаларны кар һәм аның сыйфаты (ап-ак, эри, йомшак, салкын, җиңел) белән таныштырырга, тәрбияче сорауларына җавап бирүдә күнектерергә.<br>Балаларның сүзлек запасын, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерергә.<br>Кышкы табигатькә соклану хисе, бергәләп уйнау теләге тәрбияләргә. |
| | | Алсуны урамга киендерәбез. | Балаларның кышкы киемнәр турындагы белемнәренә төгәллек кертергә; прогулкага киендерү эзлеклелеген һәм киемнәрнең билгеләнешен истә калдырырга өйрәтергә, тәрбияче сорауларына җавап бирүдә күнектерергә.<br>Балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, сүзлек запасын үстерергә.<br>Башкаларга ярдәм итү теләге, киемнәргә сак караш тәрбияләргә. |
| | | Ләйлә суыктан курыкмый. (О.И.Соловьева картинасы буенча). | Картинада ясалган предметларны дөрес танып һәм атап, картинаны карарга өйрәтергә; предметларны, эш-хәрәкәтне, төсне белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүзлекне активлаштырырга, картинаның эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирүдә күнектерергә.<br>Кабул итүне, игътибарны, хәтерне үстерергә.<br>Сюжетлы картинкалар карау теләге тәрбияләргә. |
| | | Күгәрченнәр, | Табигать объектларына булган кызыксынуларын стимуллаштырырга; мәйданчыкка |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | чыпчыклар– безнең нәни кошчыклар | килгән кошлар белән таныштырырга; “гөр-гөр”, “чырык-чырык”, “кар-кар” аваз иялтемнәрен ачык әйтүдә күнектерергә; томшык, сикерә, гөрлиләр, җим, чүплиләр, чырылдый, җитез, өлгер сүзләре хисабына сүзлекне баетырга.<br>Балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Кошлар турында кайгырту, аларга ярдәм итү, аларны тукландыру теләге тәрбияләргә. |
| **01.02.-08.03.** | **Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр** | Безнең әтиләр. (Сюжетлы картинкалар карау). | Балаларны әтиләр һөнәренә кагылышлы булган сюжетлы кечкенә картинкаларны карарга, аларның эчтәлеген аңларга өйрәтергә; эш гамәлләрен белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга.<br>Балаларның игътибарын, хәтерен, фикерләвен, куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, сүзлек запасын үстерергә.<br>Төрле профессия кешеләренә һәм әтиләр хезмәтенә карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | Безнең апа. (Тәрбияче ярдәмчесенең хезмәтен күзәтү). | Тәрбияче ярдәмчесе хезмәте белән бәйле эш хәрәкәтләрен таный һәм атый белергә өйрәтергә (савыт-саба юа, ашарга алып килә, сөлгеләрне алмаштыра, бүлмәне җыештыра һ.б.); сүзлекне активлаштырырга, аны яңа сүзләр белән баетырга. Уенчыкларны зурлыгы буенча классификацияләргә өйрәтергә.<br>Балаларның игътибарын, күзәтәчәнлекне, тәрбиячене ишетә һәм сорауларга җавап бирү, катлаулы булмаган биремнәрне үти белү осталыгын үстерергә<br>Әйләнә-тирәдәге кешеләр хезмәтенә кызыксыну һәм тыңлаучанлык тәрбияләргә. |
| | | “Алсу бәйрәмгә җыена” дидактик уены. | Якын тирәлектәге предметлар (киемнәр, аларның төсе һәм материалы) белән таныштыруны дәвам итәргә; сүзлекне активлаштырырга, ефәк, ак төстә кебек яңа сүзләр кертү; Балаларның игътибарын, хәтерен, сорауларны ишетә һәм аларга бер сүз яки кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Курчак белән уйнарга теләк һәм курчакларга сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | Безнең әниләр. (Сюжетлы картинкалар карау). | Балаларны әниләр һөнәренә кагылышлы булган сюжетлы кечкенә картинкаларның эчтәлеген аңларга өйрәтергә; эш-хәрәкәтне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга.<br>Балаларның кабул итүләрен. куелган сорауларга кыска җөмлә белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерергә.<br>Төрле һөнәр кешеләренә һәм әниләр хезмәтенә карата кызыксыну, хөрмәт тәрбияләргә.. |
| **09.03.-20.03.** | **Халык иҗаты** | Матрёшкалар. | Балаларны, халык уенчыклары буларак, матрёшкалар белән таныштыруны дәвам итәргә; матрёшканы ачарга һәм дөрес итеп җыярга өйрәтергә; сүзлек запасын киңәйтергә һәм активлаштырырга; балаларны үзләренә әйтелгән (мөрәҗәгать ителгән) |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | сүзләрне тыңлый белүдә күнектерергә; матрёшкага карата уңай эмоцияләр формалаштырырга. Игътибарны, хәтерне, сенсор сәләтләрне, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Халык иҗатына кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | Матрёшкалар. | Халык уенчыкларын дөрес атауда, төсендә һәм размерында булган аермалыкларны күрә белүдә күнектерергә; сүзлекне (зур, кечкенә, сарафан, яулык) активлаштырырга.<br>Балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Балаларда халык уенчыкларына кызыксыну тәрбияләргә. |
| **01.04.-30.04.** | **Яз** | Яз, яз килә... | Балаларга язгы күренешләр турындагы элементар белемнәр (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела) бирергә. Сүзлек запасын киңәйтергә һәм активлаштырырга.<br>Балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерергә.<br>Язгы күренешләргә кызыксыну, табигатьтә барган үзгәрешләргә шатлана белүләрен тәрбияләргә. |
| | | Җәнлекләр урманда яшиләр. | Җәнлекләр турында балаларның белемнәрен киңәйтергә һәм ныгытырга, җәнлекләрне таный һәм атый белергә өйрәтергә.<br>Балаларның диалоглы сөйләмен активлаштырырга, фикерләүне, мөстәкыйльлекләрен үстерергә.<br>Җәнлекләргә карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | Сыерчыклар, карлыгачлар килде (картинкалар карау). | Балаларны кошларны картинкада танырга һәм атарга өйрәтергә. Балаларның сүзлеген активлаштырырга, сүзлеккә сыерчык, сыерчык оясы, карлыгач сүзләрен кертергә.<br>Игътибарны, күзәтүчәнлекне, тәрбияче белән аралашу, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Кошларга һәм табигатнең башка объектларына кызыксыну, кошларга карата сакчыл караш, кайгыртучанлык хисләре тәрбияләргә. |
| | | Песилетал бөреләрен карау. | Балаларны песиле тал, аның өлешләре (ботаклар, бөреләр) белән таныштырырга; табигатьтәге язгы күренешләр турында белемнәр формалаштыруны дәвам итәргә; сүзлек запасын киңәйтергә һәм сүзлекне активлаштырырга (песиле тал, ботак, бөре, йомшак, хуш исле).<br>Балаларның кабул итүен, игътибарын күзәтүчәнлекләрен, хәтерен, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Табигать объектына карата сак караш, кызыксыну, табигатьтәге матурлыкны күрә белүләрен тәрбияләргә. |
| **01.05.-31.05.** | **Җэй** | Тузганак чәчәген карау. | Балалрны үсемлекләр белән таныштыруны дәвам итәргә; тузганак чәчәге турында белемнәр бирергә, аны танырга, атарга, төзелеше (чәчәге, сабагы, яфраклары) буенча |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | аера белергә өйрәтергә; сүзлек запасын киңәйтергә; тузганак, чәчәк, сабак сүзләрен сөйләмдә активлаштырырга.<br>Балаларның сенсор сәләтләрен, кабул итүләрен, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерергә.<br>Табигать белән турыдан-туры аралашудан шатлык хисләре уятырга; матурлыкны күрә белүне, үсемлекләргә сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | Йорт хайваннары. | Балаларның йорт хайваннары (сыер, ат, песи, эт) турындагы белемнәрен (кайда яшиләр, нәрсә ашыйлар) киңәйтергә. Хайваннарның исемнәрен, хәрәкәтләрен атауда күнектерергә.<br>Сүзлекне баетырга, тәрбияченең сорауларына җавап бирү, мөстәкыйльлек һәм активлык күрсәтү теләге үстерергә.<br>Йорт хайваннарына кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | “Балалар тавыкны һәм чебиләрне ашаталар” (авторлары В. Езикеева, Е. Радина) картинасын карау. | Балаларны картинаны карарга, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә, тәрбияченең һәм иптәшләренеңнең аңлатмаларын тыңларга өйрәтүне дәвам итәргә.<br>Сөйләмне томшык, тавык, чебиләр, табак кебек сүзләр хисабына баетырга, игътибарны, хәтерне, образлы фикерләүне үстерергә.<br>Йорт кошларына карата сак караш тәрбияләргә. |
| | | Ком үзлекләре. | Балаларны комны тикшерү ысулларына (комны учка алып, йомарларга һәм сибәргә), төсе буенча комның дымлылыгын билгеләргә өйрәтергә.<br>Коры, дымлы, юеш, сибелүчән, сибелә, әвәләү сүзләре хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга, игътибарны, сенсор сәләтләрне үстерергә.<br>Ком белән уйнауга кызыксыну тәрбияләргә. |

## 2. Коммуникация

| Сроклар | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| **20.08.-10.09.** | **Безнең бакча** | Кем нәрсә эшли? | Балаларның, аралашу чарасы буларак, сөйләмен үстерергә ярдәм итәргә, картинкалар карарга, анда сурәтләнгән предметларны һәм аларның сыйфатларын атарга, сурәтләнгән уенчыкны, предметны өстәлдә табып, исемен, гамәлен атый белергә өйрәтергә.<br>Игътибарын, кабул итүләрен үстерергә.<br>Уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләргә. |
| | | Предметларның төсләрен тану | Төсләрне белдерә торган сыйфатлар хисабына балаларның сөйләмен баетырга (кызыл, яшел, сары), [ү] авазының дөрес әйтүдә күнектерергә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | һәм “Паровоз” дидактик күнегүе . | Балаларның игътибарын, кабул итүләрен, төсләрне тану һәм атау осталыгын үстерергә.<br>Эшчәнлеккә карата кызыксыну, бер-берең белән шөгыльләнү теләге тәрбияләргә. |
| | | Уенчыклар бездә кунакта. | Төсне, зурлыкны, эш-гамәлне белдерә торган сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баетырга (зур, кечкенә, яшел, кызыл, утырт, эчерт, керт), аралашу осталыгын формалаштырырга.<br>Тәрбияченең күрсәтмәсе буенча исеме, төсе, размеры буенча балаларның предметны табу осталыгын, сенсор сәләтләрен, игътибарын, хәтерен үстерергә.<br>Уенчыкларга карата сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләргә. |
| | | Пирамидалар. | Балаларны предметларның сыйфат билгеләрен - зурлыгын, төсен билгеләргә һәм атарга өйрәтергә. Төсне (кызыл, яшел, сары, зәңгәр), зурлыкны (зур, кечкенә, зуррак, кечкенәрәк, иң зурысы, иң кечкенәсе) белдерә торган сүзләр ярдәмендә сүзлекне активлаштырырга. Аваз иялтемнәрен ачык әйтүдә күнектерергә.<br>Игътибарны, кабул итүне, сенсор сәләтләрне үстерергә.<br>Түземлелек, дидактик уеннарга кызыксыну тәрбияләргә. |
| **11.09.-30.09.** | **Көз** | Яшелчәләр. | Яшелчәләрне белдерә торган исемнәр (бәрәңге, помидор, суган, кишер, аларның үзлекләре) хисабына балаларның сүзлеген баетырга, тәрбияче кисәтүе буенча яшелчәләрне тану осталыгына өйрәтергә, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерергә.<br>Балаларның сенсор сәләтләрен үстерергә.<br>Яшелчәләргә карата уңай караш, тыңлаучанлык тәрбияләргә. |
| | | “Җил исә” уен күнегүе. “Кем нәрсә ашый?” дидактик күнегүе. | Балаларның төсләр турындагы күзаллавын ныгытырга. Җәнлекләрнең нәрсә ашавы турындагы белемнәрен ачыкларга, ялап эчә, кимерә, чүпли, ашый дигән фигыльләрне сөйләмдә активлаштырырга. Авыз аша һаваны әкрен, салмак кына чыгарырга өйрәтергә.<br>Сөйләм сулышын, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерергә.<br>Җәнлекләргә, кошларга карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | Урманда. | Балаларның олылар белән аралашу теләген хупларга, исем һәм сыйфатларны кулланырга өйрәтергә: йомшак йонлы койрык, озын колаклы куян, юан тәпиле аю, соры бүре. Кыргый хайваннарның тышкы билгеләрен һәм гадәтләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне активлаштырырга:төлке бара,куян сикерә,аю алпан- тилпән йөри һ.б.<br>Ишетү игътибарын, координацияләрне, ритм хисен үстерергә.<br>Кыргый хайваннарга карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| **1.10.-15.10.** | **Мин дөньяның бер кешесе** | Алсу бүлмәсе. | Балаларны җиһазны таный һәм атый белергә өйрәтергә, өстәл, урындык, караваt, шкаф, көзге кебек исемнәр хисабына сүзлекне активлаштырырга, сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерергә (Өстәл артыннан чык, өстәл астыннан чык). |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Балаларның эмоциональ сфераларын, кызыксынуларын үстерергә.<br>Бергә шөгыльләнү теләге тәрбияләргә. |
| | | “Бу өйдә кем яши?” дидактик уены. | Группага йөрүче балаларның исемнәрен истә калдырырга ярдәм итәргә, фигыльләрне хәзерге һәм киләчәк заманда куллана белергә өйрәтергә (Бергә яшәрбез, Кем яши? Ишек шакый? һ.б.). Сорау сүзләрен куллана белүдә күнектерергә.<br>Игътибарны, кабул итүләрен, диалогик сөйләмне үстерергә.<br>Бер–береңә карата игътибарлылык һәм кызыксыну тәрбияләргә. |
| **16.10.-04.11.** | **Минем әйләнә-тирәм.** | Алсу бездә кунакта. | Балаларны шәһәрдә яшәүче кешеләрнең һөнәрләре (табиб, полиция хезмәткәре) белән таныштырырга, грамматик яктан җөмләләрне аңларга һәм аларны сөйләмдә дөрес кулланырга өйрәтүне дәвам итәргә.<br>Игътибарны, хәтерне, күзәтүчәнлекне, кабул итүне үстерергә.<br>Һөнәрләргә карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | Әминәнең туган көненә килегез. | [К] авазын сүзләрдә һәм сөйләмдә әйтә белүләрен ныгытырга, килеш кушымчаларын дөрес әйтергә өйрәтергә. Савыт-сабаларны белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне киңәйтергә һәм активлаштырырга, гомумиләштерүче сүзләрне (савыт–саба) аңлый һәм куллана белүләрен формалаштыруны, җөмләләр белән җавап бирүдә күнектерүне дәвам итәргә.<br>Инициативалы сөйләмне, игътибарны, хәтерне үстерергә. Башкаларга мөрәҗәгать итәргә теләк тудырырга (“Кунакка кил”).<br>Үзара аралашуга омтылыш тәрбияләргә. |
| | | Минем гаиләм. | Сүзләрдән ягымлы сүзләр (әти-әтием, әни-әнием, әби-әбием, сеңел-сеңлем) ясарга өйрәтергә, [Ә] авазының әйтелешен ныгытырга, аның ачык тиешле дәрәҗәдә кычкырып әйтүдә, тәрбияче сорауларына җавап бирүдә күнектерергә.<br>Игътибарны, хәтерне, зурлар һәм балалар белән ирекле аралашуларын (йомыш кушканда-конверт эчендә нәрсә бар-кара әле; картинкадагы кешеләрнең халәтен күрсәтергә) үстерергә.<br>Гаилә әгъзаларына ихтирам тәрбияләргә. |
| **15.11.-31.12.** | **Яңа ел бәйрәме** | Купшы чыршы. | Сузык һәм тартык авазларны, аваз иялртемнәрен ачык әйтүдә, сыйфатларны дөрес куллана белүдә күнектерергә. “Төбендә” сүзен сөйләмдә кулланырга өйрәтергә.<br>Сорауларга җавап бирү осталыкларын, игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерергә.<br>Табигать объектларына (чыршыга) соклану хисләре тәрбияләргә. |
| | | Куян чыршы янында. | Сөйләмдә бәйлек сүзләрне (эчендә, артында, астында, өстә, өстендә) кулланырга, “кайда?, “кая?” сорауларына җавап бирергә, тәрбияче һәм иптәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итәргә. Тавыш көчен дөрес куллану белү осталыгын формалаштырырга.<br>Игътибарны, тәрбиячекнең сүзле күрсәтмәләре буенча эшләү осталыгын үстерергә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Нәфис сүзгә кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | Песи белән кәҗә чыршы янында. | Балаларны тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтүне дәвам итәргә. Сөйләмдә фигыльләр һәм сыйфатлар куллануны активлаштырырга. [Ж] авазын иҗекләрдә, сүзләрдә һәм җөмләләрдә дөрес һәм ачык әйтүләрен формалаштырырга, аваз иялтемнәрен кабатлаганда тавыш көчен җайлый белүдә күнектерергә.<br>Игътибарны, кабул итүне, тәрбияченең сүзле күрсәтмәләрен үтәү осталыгы үстерергә.<br>Хайваннарга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләргә. |
| | | Тылсымлы таякчык. | Балаларны сузык һәм тартык авазларны, аерым сүзләрне ачык итеп әйтергә өйрәтергә, аларның төсләр турындагы күзаллауларын ныгытырга. Төсне белдерә торган сыйфатларны активлаштырырга.<br>Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, ишетү осталыкларын үстерергә.<br>Бергә шөгыльләнү теләге тәрбияләргә. |
| **01.01.-31.01.** | **Кыш** | Кошлар. | Балаларны аваз иялтемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтергә, алардан фигыльләр (гөр – гөрли, чырык-чыркылдый, кар-каркылдый) ясарга өйрәтергә. Гомумиләштерә торган сүзләрне (тавык, әтәч, каз –йорт кошлары) куллануда күнектерегә. Кошлар исеме, гәүдә өлешләре, хәрәкәтләр атамасы хисабына сүзлекләрен активлаштырырга. Балаларны кошлар белән таныштыруны дәвам итәргә.<br>Балаларның игътибарын, хәтерен, сөйләмнең аваз культурасын үстерергә.<br>Кошларга карата кызыксыну, алар турында кайгырту теләге тәрбияләргә. |
| | | Юлны чистартабыз. | Балаларның кыш турында, кыш көне башкарыла торган хезмәт күнекмәләре турындагы белемнәрен формалаштырырга. Көрәк белән эшләү күнекмәсенә өйрәтергә. Урам себерүче хезмәте белән таныштырырга. Урам себерүче, көрәк, кар көрәргә, атарга кебек сүзтезмәләр һәм сүзләр хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга. Аерым сүзләрне (зур көрәк, кечкенә көрәк, ак кар, күп кар, әз кар) аермачык әйтүдә күнектерергә.<br>Хезмәт күнекмәләрен, кеше хәрәкәтләрен имитацияләүне үстерергә.<br>Зурларга ярдәм итү һәм гади хезмәт хәрәкәтләре үтәү теләге тәрбияләргә. |
| **01.02.-08.03.** | **Әтиләр һәм әниләр, бабайлар һәм әбиләр** | “Шундый ук предметны тап” дидактик уены. | Үз фикерләрен грамматик яктан дөрес итеп ике-өч сүздән торган фразалар (гади җөмләләр) белән белдерергә өйрәтергә. Гомумиләштерә белүдә күнектерергә. Аталган предметларны чынбарлыкта һәм картинада танырга өйрәтергә, предметларның билгеләнешен ачыкларга. Предметларның исемнәрен атау хисабына (сабын теш щеткасы, теш пастасы, сөлге, кыстыргыч) һәм сөйләмдә кулланылган фигыльләр ярдәмендә сүзлекне баетырга, активлаштырырга.<br>Тәрбияче сорауларына гади җөмлә белән тулы җавап бирү осталыгын, игътибарны, сенсор сәләтләрне үстерергә.<br>Культура-гигиеник күнекмәләр тәрбияләргә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Машина һәм самолет (Уенчыклар карау). | Балаларны уенчыкларның өлешләрен, сыйфат билгеләрен - төсен, формасын аерырга һәм атарга өйрәтергә. Исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны дәвам итәргә. [У] сузык авазын әйтүдә күнектерергә. Очучы, очып китү, очып төшү, йөк машинасы, самолет сүзләре хисабына сүзлекне активлаштырырга. Уенчыклар (машина, самолет) белән таныштыруны дәвам итәргә.<br>Балаларның нинди? кайда? нәрсә ташый? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерергә.<br>Шофер, очучы һөнәрләренә хөрмәт тәрбияләргә. |
| | | Мәрьямне табыйк. | Балаларны кайда? кая? сорауларына җавап бирергә, сөйләмдә өстенә, артына, астына сүзләрен кулланырга өйрәтергә.<br>Балаларның игътибарын, хәтерен үстерергә.<br>Уенга кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | “Зур-кечерәк-иң кечкенә” дидактик уены. | Балаларны предметларның зурлыгы буенча чагыштырырга һәм аерырга өйрәтергә. Зур, зуррак, иң зур, кечкенә, кечерәк, иң кечкенә сүзләре хисабына сүзлекне активлаштырырга.<br>Балаларның тәрбияче күрсәтмәсе буенча эшли белүләрен, кабул итүен, игътибарын үстерергә.<br>Әйләнә-тирәдәге табигать объектларына карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | Кына гөле (бальзамин) | Балаларны бүлмә гөле – кына һәм аның өлешләре белән таныштырырга. Сабак, яфрак, чәчәк сүзләре хисабына сүзлекләрен активлаштырырга.<br>Балаларның зурлар белән аралашуын, аңлауларын, күзәтүчәнлекләрен, игътибарларын үстерергә.<br>Бүлмә гөлләренә карата кызыксынучанлык, аларны карау теләге тәрбияләргә. |
| **09.03.-20.03.** | **Халык иҗаты** | Бармак уены Белән таныштыру. “Йорт хайваннары” күнегүе. | Халык авыз иҗаты белән таныштыруны дәвам иттерергә. Катлаулы булмаган фразаларны куллануда күнектерергә. Йорт хайваннарының исемнәрен ныгытырга, мөгери, кычкыра, мыраулый, өрә дигән фигыльләр хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга. [М], [у] авазларын төгәл әйтергә өйрәтергә.<br>Хәтерне, кабул итүне, авазларны әйтү культурасын үстерергә.<br>Халык авыз иҗатына, йорт хайваннарына кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | “Чуар тавык” әкиятен сөйләү.<br>. | Балаларны халык авыз иҗаты әсәрләре белән таныштыруны дәвам итәргә, әкиятне тыңлау теләге тудырырга. Чуар, күкәй, алтын, гади, тычкан кебек сүзләр хисабына балаларның сүзлеген баетырга.<br>Тәрбияче башлаган фразаны дәвам иттерү осталыгын, хәтерне, игътибарны, кабул итүне үстерергә.<br>Әкият персонажларына карата кызыксыну тәрбияләргә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **01.04.-30.04.** | **Яз** | Бүлмә гөлләре (фикус, яран). | Балаларның гади сорауларга җавап бирү осталыгын камилләштерергә, бүлмә гөлләренең өлешләрен атарга, аларның сыйфат билгеләрен белдерә торган сүзләр хисабына сүзлекне баетырга.<br>Гөлләргә карата кызыксынуларын үстерергә.<br>Элементар хезмәт күнекмәсе булдыру теләге тәрбияләргә. |
| | | Йөк машинасы. | Машина, аның өлешләре турындагы балаларның белемнәрен арттырырга, ком, аның үзлекләре белән таныштырырга, машинаның төрен, өлешләрен, комның үзлекләрен белдерә торган исемнәр, сыйфатлар хисабына сүзлекне активлаштырырга. [В], [п] авазларының дөрес әйтелешен булдырырга. Кызыксынучанлыкны, кабул итүне үстерергә.<br>Тәрбияче һәм яшьтәшләре белән аралашу теләге тәрбияләргә. |
| | | Язгы урманда<br>. | Кайда?, нинди? сорауларына җавап бирергә өйрәтергә; өстә, агач төбендә сүзләрен куллану хисабына сөйләмнең грамматик төзелешен камилләштерергә; аваз ияртемнәрен ачык, төгәл әйтүдә күнектерергә; [ш] авазын ныгытырга. Табигатьтәге сезон үзгәрешләре турында белемнәрен формалаштыруны дәвам итәргә.<br>Балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерергә.<br>Табигать объектларына сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | Бозау,бәрән, колын, кәҗә бәтие, сез кайда? | Балаларның йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтергә. Бозау, бәрән, колын, кәҗә бәтие сүзләре хисабына сүзлекне баетырга һәм активлаштырырга. Тәрбиячене сүзле күрсәтмәләрен үти белү осталыгын формалаштырырга.<br>Игътибарны, хәтерне үстерергә.<br>Башкаларга ярдәм итү теләге, тыңлаучанлык, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләргә. |
| **01.05.-31.05.** | **Җәй** | Безнең участок. | Исемнәр, фигыльләр, сыйфатлар хисабына сүзлекне активлаштырырга. Фигыльләрне һәм сыйфатларны исемнәр белән яраклаштыруда күнектерергә. Балаларны участокта үсә торган үсемлекләр исеме белән таныштыруны дәвам итәргә. Табигатьтәге сезонлы үзгәрешләр турында белемнәрне киңәйтергә.<br>Төсләрне, матурлыкны белдерүче сыйфатлар ярдәмендә сөйләм теле компонентларын үстерергә.<br>Табигать объектларына карата кызыксыну, хезмәткә хөрмәт тәрбияләргә. |
| | | Кызыксынучан Тел. | Балаларны [т], [д], [к] авазлары кергән аваз ияртемнәрен әйтергә өйрәтергә; аваз ияртемнәрен төрле югарылыктагы тавыш (калын, нечкә) белән әйтүдә күнектерергә; [т], [д], [к] авазларын сүзләрдә, фразаларда әйтүне ныгытырга.<br>[Т], [д], [к] авазларын әйтү хисабына сөйләмнең аваз культурасын, балаларның фантазиясен үстерергә.<br>Игътибарлылык тәрбияләргә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Зоопарк | Җылы якның кайбер хайваннары белән таныштырырга; сөйләмдә сыйфатлар кулланырга өйрәтүне дәвам итәргә; яшәү шартлары буенча гомумиләштерергә өйрәтергә.<br>Предметлар, уенчыклар турында сөйләм аша ирекле аралашуларын үстерергә.<br>Җылы як хайваннарына карата сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | Рәхмәт, җәй! | Балаларны яшелчәләрне, җиләк-җимешләрне тәме буенча аерырга өйрәтүне дәвам итәргә; яшелчәләр, җиләк-җимешләр, агачлар турындагы белемнәрне киңәйтергә.<br>Сөйләм теле компонентларын, нормаларын үстерергә.<br>Игътибар белән тыңлауларын, табигать объектларына сакчыл караш тәрбияләргә. |

## 3. Матур әдәбият

| Сроклар | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| **20.08.-10.09.** | **Безнең бакча** | “Үчтеки, үчтеки” такмагын уку | Фольклор әсәрләренә кызыксыну уятырга; шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтергә.<br>Балаларның эмоциональ сферасын үстерергә.<br>Нәфис сүзгә мәхәббәт тәрбияләргә |
| | | Ә.Бикчәнтәева-ның“Туп-туп-тубыбыз” шигырен уку | Балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә, таныш предметларны таный һәм атый белергә өйрәтергә, шигырьне укыганда, шигырьнең аерым сүзләрен әйтергә мөмкинлек бирергә, тупның төсләрен ныгытырга.<br>Балаларның эмоциональ сферасын үстерергә.<br>Уңай эмоциональ атмосфера тудырырга, уенчыкларга сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | С.Сөләйманова-ның “Ике” шигырен уку | Балаларда шигъри әсәргә кызыксыну уятырга, поэтик әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтергә, баланың үзе турында күзаллауларын формалаштыруны дәвам итәргә, “кул”, “аяк”, “колак”, “күз”, сүзләре хисабына сүзлекне киңәйтергә һәм активлаштырырга.<br>Һәр әгъзаның яшәү өчен әһәмияткә ия булуын һәм кирәклеген тоемлауларын үстерергә.<br>Культура-гигиеник күнекмәләр тәрбияләргә. |
| **11.09.-30.09.** | **Көз** | Хайваннарны чакыру эндәшен уку | Эндәшнең эчтәлеген аңларга өйрәтергә, фольклорның бу төр жанрына кызыксыну уятырга, текстның эчтәлеге буенча аваз ияртемнәрен, ымлыклар әйтүдә күнектерергә тәрбияченең сорауларына аңлап җавап бирүләрен ныгытырга.<br>Балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген үстерергә.<br>Хайваннарны ярату теләге тәрбияләргә. |
| | | Д.Гарифулинның “Йә, алар кемнәр икән” шигырен уку. | Шигъри әсәрне аңлап кабул итәргә өйрәтүне дәвам итәргә, “бак-бак”, “Мә-мә”, “Кар-кар” аваз ияртемнәрен кабатларга.<br>Балаларны шигырьдә бирелгән диалогка җәлеп итәргә; сүзлекне үстерергә һәм активлаштырырга. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | Кошларга, хайваннарга карата мәрхәмәтлелек тәрбияләргә. |
| | | Б.Рәхмәтнең “Су” шигырен уку. | Текстка туры китереп, хәрәкәтләр ясарга өйрәтергә, шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә, [ю] авазын ачык итеп әйтүдә күнектерергә, шигырьнең эчтәлегенә эмоциональ җавап бирүләренә булышлык итәргә.<br>Сүзлекне үстерергә һәм активлаштырырга.<br>Культура-гигиена күнекмәләрен тәрбияләүне дәвам итәргә |
| **1.10.-15.10.** | **Мин дөньяның бер кешесе** | Г.Тукайның “Гали белән кәҗә” шигырен уку. | Шигъри әсәрне аңларга өйрәтергә; балаларга дөньянын бер кешесе дигән күзаллауны бирергә. Кәҗәне таныргa өйрәтүне дәвам итәргә.<br>Кәҗә, чирәм, сакал сүзләре хисабына сүзлек запасын киңәйтергә, хәрәкәтләрне үстерергә.<br>Бер-беренә карата һәм хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләргә. |
| | | З.Туфайлованың “Ул зу-у-у-ур үскән” шигырен уку | Шигъри әсәрне кабул итәргә һәм хезмәтнең нәтиҗәсен күрә белергә өйрәтергә, утырткан, сипкән, үскән кебек эш-хәрәкәтне белдерә торган фигыльләр хисабына сүзлекне киңәйтергә, активлаштырырга; шигырьне истә калдыруларына булышлык итәргә; сүз төркемнәрен дөрес кулланып диологлы сөйләмне баетырга.<br>Уңай эмоциональ халәтне үстерергә.<br>Гөлләргә карата сакчыл караш, гөлнең матурлыгына соклана белүләрен тәрбияләргә. |
| | | “Песи-нечкәбил” бишек җырын уку. | Шигъри әсәрнең эчтәлеген аңлатырга, бишек җырын сәхнәләштерергә һәм текстка туры китереп хәрәкәтләр башкара белергә өйрәтергә.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>Фольклор әсәрләренә кызыксыну тәрбияләргә. |
| **16.10.-04.11.** | **Минем әйләнә-тирә** | М.Җәлилнең “Маэмай” шигырен уку. | Шигъри әсәр белән таныштырырга, аңлап кабул итәргә өйрәтергә, бармак театры элементларын куллануны дәвам итәргә.<br>Сүзлек запасын киңәйтергә (маэмай, борын, йөгерә, өрә, ишетә, күрә).<br>Йорт хайваннарына кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | М. Җәлилнең “ Әтәч” шигырен уку. | Күрсәтмәлек кулланмыйча әдәби әсәрне тыңлый һәм кабул итү күнекмәләрен формалаштырырга, кычкырганда барлыкка килгән тавышлары буенча йорт кошларын таный һәм атый белергә өйрәтергә, [к] авазының әйтелешен ныгытырга.<br>Шигырьне бармаклар театры ярдәмендә сәхнәләштерү күнекмәләрен үстерергә.<br>Йорт кошларына карата мәхәббәт тәрбияләргә. |
| | | Ж.Тәрҗемановның “Маэмай” шигырен уку | Шигъри әсәрне аңларга өйрәтүне дәвам итәргә, аерым сүзләрне (Акбаем, маэмаем, өрә) һәм зур булмаган фразаларны (“ташлар ыргытмагыз!”, “Мине котыртмагыз!”) кабатларга өндәргә.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>Эткә карата миһербанлылык тәрбияләргә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **15.11.-<br>31.12.** | **Яңа<br>ел бәйрәме** | Ә.Бикчәнтәеваның<br>“Беренче адым”<br>шигырен уку. | Балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә; кайбер сүзләрне әйтергә өндәргә; бирелгән сорауларга җавап бирергә өйрәтергә. Игътибарын үстерергә.<br>Күмәк эшчәнлек күнекмәләре тәрбияләргә. |
| | | “Карга әйтә...”<br>эндәшен уку. | Шигъри әсәрне кабул итәргә өйрәтергә, кошлар турында балаларның белемнәрен ныгытырга һәм киңәйтергә; аларның тышкы кыяфәтенә игътибар итәргә, сүзлекне баетырга; [к] авазының дөрес әйтелешен булдырырга.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>кошларга карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| **01.01.-<br>31.01.** | **Кыш** | Ә.Ерикәйнең<br>“Беренче кар”<br>шигырен уку | Шигъри әсәрне аңлап кабул итәргә өйрәтергә дәвам итәргә; әсәр аша табигать дөньясына җәлеп итәргә, кышкы күренешләр турында белемнәрен формалаштырырга; “йомшак”, “ап-ак” сыйфатлары хисабына сүзлек запасын киңәйтергә һәм активлаштырырга.<br>Катлаулырак сорауларга җавап бирә белүләрен, хәтерен, уңай эмоцияләрен үстерергә.<br>Табигатькә мәхәббәт, туган телне өйрәнүгә кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | Җ.Тәрҗемановның “Йокы бабай”<br>әкиятен сөйләү. | Хикәянең эчтәлеген балаларга аңларга ярдәм итәргә.<br>Игътибар белән тыңлауларын үстерергә.<br>Бирелгән сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләргә. |
| | | С. Летованың<br>“Кар бабай”<br>хикәясен уку. | Күләме буенча зур булмаган әдәби әсәрне (хикәяне) күрсәтмәлелектән башка гына тыңларга һәм сорауларга аңлаешлы итеп җавап бирергә өйрәтүне дәвам итәргә, балаларның әңгәмәдә җиңел һәм иркен аралашуларына ирешергә, сүзлек запасын киңәйтергә (яхшы күңел, йомшак күңел, киң күңел).<br>Балаларның игътибарын, бергәләп тыңлау күнекмәсе үстерергә.<br>Сүз сәнгатенә кызыксыну тәрбияләргә. |
| **01.02.-<br>08.03.** | **Әтиләр<br>һәм әниләр,<br>бабайлар<br>һәм әбиләр** | Ш.Маннурның<br>“Яратам”<br>шигырен уку. | Балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә; шигырьне тыңлау теләге уятырга, сорауларга аңлап җавап бирүдә, [ә] авазын ачык итеп әйтүдә күнектерергә.<br>Балаларның игътибарын, кабул итүен үстерергә.<br>Әти-әниләргә, туганнарга мәхәббәт тәрбияләргә. |
| | | “Кәккүк-чыпчык”<br>уены**.** | [Ч] һәм [к] авазларын дөрес һәм ачык итеп әйтергә өйрәтергә, сүзлекне активлаштырырга.<br>Балаларның эмоциональ сферасын үстерергә.<br>Фольклор әсәрләренә кызыксыну тәрбияләүне дәвам иттерергә. |
| | | Г.Таһированың<br>“Йокла, курчак”<br>шигырен уку. | Балаларга шигырьнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә; шигырьне тыңлау теләген уятырга, [ә], [ү] авазларын ачык итеп әйтүдә күнектерергә.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>Курчакка карата кайгыртучанлык тәрбияләргә. |
| | | Ә.Каринең | Шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итәргә; фланелеграфта шигырь эчтәлегенә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Тавык” шигырен уку. | туры килгән рәсемнәр яки уенчыклар күрсәтергә; тавыкны рәсемнәрдә һәм уенчыкларда танырга өйрәтергә. Тәрбияче артыннан кайбер фразаларны кабатларга өндәп, балаларның сөйләмен активлаштырырга.<br>Балаларның игътибарын, кабул итүләрен, сорауларга җавап бирү осталыкларын үстерергә.<br>Әбиләргә карата ихтирам, игътибар, ярату хисләре тәрбияләү. |
| | | Э.Шәрифуллинаның “Иң матур әни” шигырен уку. | Шигъри әсәрне тыңларга өйрәтүне дәвам итәргә. Тәрбияче артыннан кайбер фразаларны кабатларга өндәп, балаларның сөйләмен активлаштырырга.<br>Балаларның игътибарын, кабул итүләрен, сорауларга җавап бирү осталыкларын үстерергә.<br>Әниләргә карата ихтирам, игътибар, ярату хисләре тәрбияләү. |
| **09.03.-20.03.** | **Халык иҗаты** | “Камыр малай” әкиятен уку (рус халык әкияте). | Балаларны “Камыр малай” әкияте белән таныштырырга, әкиятнең эчтәлеген аңларга ярдәм итәргә. Шар әвәләү (камыр кисәген түгәрәкләү хәрәкәтләре ясап кулларда тәгәрәтү) күнекмәсен ныгытырга.<br>Сорауларга җавап бирү осталыгын үстерергә.<br>Әкиятләрне тыңлау, аңа карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | “Камыр малай” әкиятен кабатлау. | Әкиятне тәрбияче белән бергә сөйләргә өйрәтергә, аерым фразалар әйтү хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга.<br>Балаларның игътибарын, кабул итүен үстерергә.<br>Әкият геройларына карата кызыксынучанлык тәрбияләргә. |
| | | “Теремкәй” рус халык әкиятен уку. | Балаларны яңа әсәр белән таныштырырга; әкиятне игътибар белән тыңларга өйрәтергә.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>Халык иҗатына кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | “Теремкәй” әкиятен сәхнәләштерү. | Әкият белән таныштыруны дәвам итәргә. Аваз ияртемнәрен ачык кабатларга өйрәтергә.<br>Сәхнәләштерүгә кызыксыну уятырга; уен барышында фразаларны дөрес әйтү осталыгын үстерергә.<br>Халык әкиятләренә кызыксыну тәрбияләргә. |
| **01.04.-30.04.** | **Яз** | Ш.Галиевнең “Яз” шигырен уку | Балаларның шигъри әсәрне аңлап кабул итүләренә ирешергә, шигырь ярдәмендә яз турындагы белемнәрен киңәйтергә, [т] авазын, “тып” аваз ияртемен ачык итеп әйтүдә күнектерергә; сүзлек запасын киңәйтергә һәм активлаштырырга.<br>Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, кызыксынучанлыгын үстерергә.<br>Язгы табигать күренешләренә соклану хисе тәрбияләргә. |
| | | “Тор-тор, тургай” (баланы уятканда) такмагын уку. | Такмакның эчтәлеге белән таныштырырга; [т] авазын ачык итеп әйтүдә күнектерергә.<br>Аваз ияртемнәрен әйтү хисабына балаларның сүзлекләрен үстерергә.<br>Фольклор әсәрләренә кызыксыну тәрбияләргә кошларга карата кызыксыну |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | тәрбияләргә. |
| | | “Тук,тук, тукран...” эндәшен уку. | Шигъри текстны тыңлый белү осталыгы формалаштырырга, кошлар (тукран белән) таныштыруны дәвам иттерергә, аваз ияртемнәрен ачык кабатларга, [т], [к] авазлары әйтелешен кабатларга.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>Кошларга карата сакчыл караш тәрбияләргә. |
| | | “Кояш, чык,чык...” эндәшен уку. | Балаларга эндәшнең эчтәлеген аңларга, сюжетның эзлеклелеген истә калдырырга ярдәм итәргә.<br>Тыңлый белү сәләтен, эмоциональ сферасын үстерергә.<br>Күмәк эшкә кызыксыну тәрбияләргә . |
| | | Р.Батулланың “Нурбәк” әкиятен уку. | Әкиятне игътибар белән аңлап тыңларга өйрәтүне дәвам итәргә; [а], [у], [ә] сузык авазларын һәм аваз ияртемнәрен ачык итеп әйтүдә күнектерергә; әкият персонажларын уенчыкларда танырга һәм атарга өйрәтергә.<br>Балаларның игътибарын үстерергә.<br>Әкият геройларына карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| | | К.Д.Ушинский-нын “Казлар” хикәясен уку. | Казларны һәм үрдәкләрне аера белергә өйрәтергә, матур әдәбият әсәре - хикәяне күрсәтмәлелек кулланмыйча тыңлый белүләренә ирешергә; аваз ияртемнәрен аермачык әйтүдә, күплек һәм берлек сандагы исемнәрне аера белүдә һәм дөрес куллануда күнектерергә.<br>Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен, тәрбиячененң күрсәтмәләрен үти алу осталыкларын үстерергә.<br>Йорт кошларына карата кызыксыну тәрбияләргә. |
| **01.05.-31.05.** | **Җәй** | Ә.Каринының «Чебиләр» шигырен уку**.** | Күрсәтмәлелек кулланмыйча шигъри әсәрне тыңларга өйрәтергә; кайбер фразаларны тәрбияче артыннан кабатларга өндәргә, [ч] авазын, аваз ияртемнәрен дөрес әйтүдә күнектерергә. Эмоциональ сфераны үстерергә.<br>Йорт кошларына карата кайгыртучанлык тәрбияләргә. |
| | | С.Сөләйманованың “Кызыл әтәч” шигырен уку. | Шигъри әсәрне тыңларга өйрәтергә; гади сорауларга җавап бирү теләге уятырга, “кикри-күк” аваз ияртемен кабатлауда күнектерергә.<br>Балаларның кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен, тәрбиячененң күрсәтмәләрен үти алу осталыкларын, эмоциональ сферасын үстерергә.<br>Йорт кошларына карата мәрхәмәтлелек тәрбияләргә. |
| | | Д. Гарифуллин-ның “Мыраубикә” шигырен уку. | Шигырь ярдәмендә песи белән таныштыруны дәвам итәргә, песи турындагы белемнәрен ныгытырга һәм киңәйтергә, “мыр-мыр”, “гыр-гыр” аваз ияртемнәрен ачык итеп кабатлауда күнектерергә.<br>Сорауларга җавап бирү теләге үстерергә.<br>Песиләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләргә. |

**Икенче кече яшьтәге( 3-4 яшь)** балалар белән туган телне өйрәнүгә юнәлдерелгән эшчәнлек конспектлары Н.Е.Веракса, Т.С.Комарова, М.А.Васильева редакциясендә чыккан “Туганнан алып мәктәпкә кадәр. Мәктәпкәчә мәгарифнең якынча төп белем бирү программасы” нигезендә төзелгән. Федераль дәүләт таләпләре буенча танып белү, коммуникация (сөйләм үстерү), матур әдәбият белән таныштыру кебек өч белем бирү өлкәсе карала. Белем бирү өлкәләрен үзләштерү гомумкабул ителгән педагогик принципларга нигезләнә.

Икенче кече яшьтәге( 3-4 яшь) балалар эшчәнлеген оештыру комплекслы – белем бирү өлкәләрен үзләштерү гомумкабул ителгән педагогик принципларга нигезләнә. План ел дәверендә “Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы!”, “Көз”, “Мин һәм минем гаиләм”, “ Минем йортым, минем шәһәрем”, “Яңа ел бәйрәме”, “ Кыш”, “Ватанны саклаучылар көне”, “Сигезенче март”, “Халык җәүһәрләре”, “Яз”, “Җәй” кебек темалар үзләштерүне күздә тота.

## 1. Танып белү өлкәсе

| Сроклар | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| **20.08.-10.09.** | **Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы!** | Кояш чык! | 1) ел фасылы буларак җәй турындагы күзаллауларын киңәйтү, тәүлек өлешләрен дөрес әйтүдә күнектерү;<br>2) балаларның сөйләмен, игътибарын, ишетү хәтерен, хыял итүләрен, фикерен, вак моториканы, рәсем ясау күнекмәсен, иҗади сәләтләрен үстерү;<br>3) балаларда табигать көчләренә дөрес караш тәрбияләү. |
| | | Йомшаккай әзерләгән сюрприз | 1) агачтан ясалган уенчыкларны карау барышында материал буларак агач, аның үзлекләре (каты, нык) белән таныштыру, тәрбияче сорауларына җавап бирүдә күнектерү.2) предметларның төсен, формасын, зурлыгын билгели белү осталыгын, анализаторлар эшчәнлеген, сүзлек байлыгын, хәтерен, игътибарны үстерү.<br>3) уенчыкларга карата сак караш һәм уеннан соң уенчыкларны урынына кую гадәте тәрбияләү. |
| | | Манара | 1) балаларны төрле зурлыктагы һәм төстәге төзү материалы шакмак белән таныштырырга, үрнәк буенча манара корылмасын төзергә өйрәтү.<br>2) кабул итүләрен, предметның төсен, формасын, зурлыгын аера белү, шакмакларны берсе өстенә икенчесен кую осталыгын ныгыту.<br>3) бергә шөгыльләнү теләген, балалар бакчасына карата уңай эмоцияләр тәрбияләү. |
| **11.09.-30.09.** | **Көз** | Куян үстергән кишер һзм помидор | 1)балаларның табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турындагы күзаллауларын киңәйтү, яшелчәләр (кишер, помидор) турындагы белемнәрен ныгыту;<br>2) балаларның тышкы күренеше, тәме, формасы буенча яшелчәләрне (кишер, помидор) аера белү осталыгын, игътибарын, кабул итүләрен, диалоглы сөйләмен, сенсор сәләтләрен үстерү;<br>3) балаларда сорауларга җавап бирү теләге, табигатькә уңай караш тәрбияләү. |
| | | | 1) балаларның табигатьтәге көзге үзгәрешләр, көзге уңыш турындагы күзаллауларын |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | киңәйтү, яшелчәләр (кыяр, шалкан) турындагы белемнәрен ныгыту;<br>2) балаларның тышкы күренеше, тәме, формасы буенча яшелчәләрне (кыяр, шалкан) аера белү осталыгын, игътибарын, кабул итүләрен, диалоглы сөйләмен, сенсор сәләтләрен үстерү;<br>3) балаларда сорауларга җавап бирү теләге, табигатькә уңай караш тәрбияләү. |
| | | Сары, кызыл яфраклар | 1) балаларның бер-берсен алмаштырып килә торган көз, кыш ел вакытларының характерлы билгеләре белән таныштыру, бер ел вакыты икенчесен алмаштыруы турындагы күзаллауларына төгәллек кертү, көзге яфраклар турындагы белемнәрен (яфраклар төсләрен үзгәртәләр, коелалар), авазлар әйтелешен ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, бәйләнешле сөйләмен, сорауларга җавап бирү, көзге табигатьнең матурлыгын күрә белү осталыгын үстерү;<br>3) балаларда чиста, пөхтә эшләү теләге тәрбияләү. |
| **1.10.-15.10.** | **Мин һәм минем гаиләм** | Кунак каршылыйбыз | 1) савыт-сабаның аерым предметлары атамасына, аларның кулланылышына төгәллек кертү; тәрбияче белән бергә кыска хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү; сөйләшүгә җәлеп итү; 2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, тәрбияче биргән сорауны ишетү һәм аңлау, сорауга аңлаешлы итеп җавап бирү, үз исемен әйтә белү осталыгын үстерү,<br>3) балаларда сөйләм этикеты осталыгы (исәнләшү, танышу, саубуллашу), өлкәннәргә булышу теләге, савыт-сабага сакчыл караш тәрбияләү. |
| **16.10.-04.11.** | **Минем йортым, минем шәһәрем** | Мин – “КамАЗ” оныгы**.** | 1) балаларны туган шәһәр, аның исеме (Яр Чаллы), шәһәрдә ясала торган “КамАЗ” машинасы белән таныштыруны, юл йөрү кагыйдәләре турында элементар белемнәр бирүне дәвам итү;<br>2) кабул итүләрен, диалогик сөйләмне, сүзләрне, кыска фразаларны ачык әйтү осталыгын, “КамАЗ” машиналары белән кызыксыну үстерү;<br>3) туган шәһәр, “КамАЗ”эшчеләре белән горурлану хисләре тәрбияләү. |
| **15.11.-31.12.** | **Яңа ел бәйрәме** | Тылсымлы шкатулка. | 1) бәйрәм культурасына җәлеп итү, Яңа ел бәйрәмен каршыларга әзерләү, чыршы уенчыклары белән таныштыруны, аларны карарга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның чыршы уенчыкларының төсен, формасын, зурлыгын, кулланылышын билгеләү, диалогик сөйләмен, сорауларга җөмлә белән җавап бирү осталыгын, хисси тәҗрибәсен, кабул итүләрен үстерү; берничә сенсор билгеләре буенча бертөрле предметларны группага берләштерү осталыгын ныгыту;<br>3) чыршы уенчыкларына сак караш тәрбияләү, балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру. |
| | | Куян белән тиенне чыршы бәйрәменә чакырабыз | 1) балаларның кышкы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре, кыргый җәнлекләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, тикшеренүләр, суның үзлекләре турында күзаллаулар бирү, авазларның артикуляциясен ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, хәтерен, үстерү, танып белү кызыксынуларын формалаштыру; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | 3) балаларда Яңа ел бәйрәме уңаеннан яхшы кәеф, шатлык хисләре булдыруга шартлар тудыру, җәнлекләргә карата кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. |
| **01.01.- 31.01.** | **Кыш** | “Чанада шуабыз” картинасын карау | 1) балаларны картинаны карарга һәм аның эчтәлеген аңларга, эчтәлеге буенча җөмләдәге сүзләрне туры китереп, сорауларга җавап бирергә өйрәтү дәвам итү; 2) диалогик сөйләмне, игътибарны, күрсәтмә-образлы фикерләүне, сөйләм темпын үстерү; 3) кышның матурлыгын күрү сәләтен тәрбияләү. |
| | | Җимлек янында. . | 1) кышлаучы кошларны күзәтүне оештыру, аларны тышкы кыяфәтләре буенча танырга өйрәтүне дәвам итү, аваз ияртемнәрен әйтүдә күнектерү, кисточканың очы белән ярма бөртекләре ясауны ныгыту; 2) балаларның сүзлек запасын, күзәтүчәнлеген, игътибарын үстерү, 3) кошларга карата сак караш, алар белән кызыксыну, кышын тукландыру теләге тәрбияләү. |
| **01.02.- 23.02..** | **Ватанны саклаучы-лар көне** | Ватанны саклаучылар көне | 1) балаларны Ватанны саклаучылар көне белән таныштыру; 2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, диалоглы, монологлы сөйләм осталыгын үстерү; 3) балаларда Туган илгә мәхәббәт, малайларда көчле,кыю булу теләге тәрбияләү. |
| **24.02.- 08.03..** | **Сигезенче Март** | Минем әнием | 1)әниләр турындаәңгәмә корырга, әниләрнең исемен әйтә белү осталыгын ныгытуны, әзер формалардан кәгазь битендә бизәк төзеп, аны ябыштырырга өйрәтүне дәвам итү; 2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, сүзлек байлыгын үстерү; 3) балаларда пөхтәлек, әниләргә карата җылы мөнәсәбәт, хөрмәт, мәхәббәт тәрбияләү. |
| **09.03.- 31.03.** | **Халык җәүһәрләре** | Тере һәм уенчык кошларны карау | 1) тере һәм уенчык кошны чагыштырып, уенчыклар (дымка уенчыгы) белән таныштыруны, уенчыкның нинди материалдан ясалган булуын ачыклауны, төсләрне, дымка бизәге элементларын ныгытуны дәвам итү ; 2) балаларның игътибарын, күзәтүчәнлеген, сорауларга җавап бирү осталыгын үстерү; 3) кошлар, уенчыклар белән кызыксыну, кошларга, уенчыкларга сак караш, кошлар турында кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| **01.04.- 20.04.** | **Яз** | Урамда яз | 1) балаларны язга хас булган күренешләр белән таныштыруны дәвам итү (кар эри, тамчы тама, кояш җылыта, сулар җыела), язгы табигатьтәге гади бәйләнешләрне (кояш ныграк җылыта – көннәр җылына – кар эри һ.б.) атау хисабына сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру; 2) балаларның күзәтүчәнлеген, игътибарын, күзаллавын үстерү; 3) язгы күренешләр белән кызыксыну, табигатьтә барган үзгәрешләргә шатлана белүләрен тәрбияләүне дәвам итү. |
| **02.05.- 31.05.** | **Җэй** | “Кәҗә һәм кәҗә бәтиләре” картинасын карау | 1) балаларга картинаның эчтәлеген аңларга, тәрбияче белән бергә аның турында сөйләргә ярдәм итү, йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү; 2) балаларның кабул итүләрен игътибарын, диалоглы сөйләмен, дуслык турындагы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | күзаллауларын үстерү;<br>3) тәрбияче сөйләгәнне тыңлый белү осталыгы, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | | Тузганак чәчәген карау | 1) балаларны туган як үсемлекләре (тузганак) белән таныштыруны дәвам итү;<br>2) үсемлекләрне карау барышында әңгәмә алып бару осталыгын, хәтерне, игътибарны, күзәтүчәнлекне үстерү;<br>3) үсемлекләр белән кызыксыну, эстетик хисләр тәрбияләү. |

## 2. Сөйләм үстерү ( коммуникация) өлкәсе

| Сроклар | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| **20.08.-10.09.** | **Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы!** | “Ә” авазы | 1) “ә” сузык авазын төгәл итеп әйтергә өйрәтергә, авазны кыска һәм озак итеп әйтүдә күнектерергә. “Ә” авазын аерым, сүзләрдә һәм җөмләләрдә әйтүдә ныгыту;<br>2) балаларның эмоциональ сферасын, сорауларга теләп җавап бирү осталыгын үстерү;<br>3) сюжетны чагылдыра торган уеннарда катнашу теләге тәрбияләү. |
| **11.09.-30.09.** | **Көз** | Бакчада алмалар өлгерде | 1) балаларның көз, табигатьтәге көзге үзгәрешләр, җиләк-җимешләр (алма, аның билгеләре) турында күзаллауларын баету нигезендә сүзлек запасын киңәйтү һәм активлаштыру, тиңдәш кисәкләр кергән җөмләләр төзергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, сенсор сәләтләрен, артикуляция аппаратын үстерү;<br>3) коллективта эшләү, сорауларга җавап бирү теләге тәрбияләү. |
| | | Алтын көз | 1) тиңдәш кисәкләрдән торган җөмләләр төзергә өйрәтүне, аерым предметлардан төркем төзергә, характерлы билгеләре буенча предметны төркемнән аерырга өйрәтүне дәвам итү; предметларның саны буенча бәйләнеш урнаштырганда “бер”, “күп”, “аз”, “берәү дә юк” сүзләрен куллана, сүзләрдә [с], [з], [ф], [к] тартыкларын ачык итеп әйтә белү осталыгын камилләштерү;<br>2) балаларның игътибарын, зиһенгә алуларын һәм табигатьнең матурлыгын тоемлауларын, тәрбияче соравына аңлаешлы итеп җавап бирә белүләрен үстерү;<br>3) сорауларга җавап бирү теләге, табигатькә карата яхшы мөнәсәбәт тәрбияләү. |
| **1.10.-15.10.** | **Мин һәм минем гаиләм** | Безнең гаилә | 1) балаларның гаилә һәм гаилә әгъзалары турындагы белемнәрен ныгытуны дәвам итү,исемнәрне сан, тартым белән төрләндерү (әни-әниләр, әни-әнием) осталыгын камилләштерү;<br>2) балаларның зурлар белән ирекле аралашуларын, игътибарын, хәтерен, кабул итүен, фикерләвен үстерү;<br>3) гаиләгә һәм гаилә әгъзаларына карата игътибарлы, кайгыртучан булырга өндәү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **16.10.-04.11.** | **Минем йортым, минем шәһәрем** | Песи баласы уенчыгы турында хикәяләү | 1) балаларның гаилә турындагы күзаллауларын киңәйтүне, уенчыкны карауга балаларны җәлеп итүне, уенчыкны тасвирлау буенча бирелгән сорауларга җавап бирергә, тәрбияче ярдәмендә уенчык турында кыска хикәя төзергә өйрәтүне дәвам итү;<br>2) балаларның, игътибарын, кабул итүләрен, күзәтүчәнлеген, сүзлеген үстерү;<br>3) тәрбияче һәм иптәшләре белән аралашу теләге, йорт хайваннарына карата мәрхәмәт тәрбияләү. |
| | | Алсуның яңа өе. | 1) балаларны җиһаз белән таныштыру, билгеләнеше буенча гомумиләштерергә өйрәтү, бирелгән сорауны аңлау һәм җавап бирүне формалаштыру;<br>2) җиһаз предметларының атамасын һәм билгеләнешен ачыклау, аларның нинди материалдан эшләнгәнен аеру осталыгын, артында, янында, өстендә кебек сүзләр хисабында сүзлекне үстерү;<br>3) җиһазга карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| **15.11.-31.12.** | **Яңа ел бәйрәме** | Төлке бездә кунакта | 1) сөйләмдә бәйлек сүзләрне (эчендә, артында, астында, өстә, өстендә) кулланырга, “кайда?, “кая?” сорауларына җавап бирү, тәрбияче һәм иптәшләре белән ирекле аралашырга өйрәтүне дәвам итү;<br>2) игътибарны, тәрбияченең сүзле күрсәтмәләре буенча эшләү осталыгын үстерү;<br>3) җәнлекләргә карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| **01.01.-31.01.** | **Кыш** | Алсуны урамга киендерәбез. (Кышкы киемнәрне карау) | 1) кышкы киемнең билгеләнешен, төсен, детальләрен, материалын аерып алып, аны карарга өйрәтү, исемне сыйфат белән туры китереп, сорауларга җавап бирүне дәвам итү;<br>2) тукыма, мех, йомшак, җылы, шома, ак, яшел (зәңгәр) сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру, конкрет-образлы фикерләүне, игътибарны, күрү хәтерен үстерү;<br>3) киемнәргә карата сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | Кар ява<br>. | 1) балаларның кыш турында күзаллауларын киңәйтү, кар, аның билгеләре белән таныштыруны дәвам итү, сөйләмдә сыйфатларны дөрес куллана белү осталыгы камилләштерү;<br>2) балаларның игътибарын, диалоглы сөйләмен, рәсем ясауга кызыксынуларын, пространствода ориентлашуларын, сөйләм сулышын үстерү;<br>3) башкаларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| **01.02.-23.02..** | **Ватанны саклаучылар көне** | Очучылар | 1) балаларны самолетның өлешләрен, зурлыгын, формасын аерырга һәм атарга өйрәтүне, исемнәрне сыйфатлар белән яраклаштыру күнекмәләре формалаштыруны, [у] сузык авазын әйтүдә күнектерүне уенчыклар (самолет) белән таныштыруны дәвам итү, очучы, очып китү, очып төшү, аска, өскә, уңга, сулга, самолет сүзләре хисабына сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның нинди? кайда? кая? нәрсә? сорауларына тулы фразалар белән җавап бирү осталыгын, игътибарын үстерү;<br>3) очучы һөнәренә хөрмәт, патриотик хисләр тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **24.02.-08.03..** | **Сигезенче Март** | Кояш гомере телим мин, әнием сиңа! | 1) балаларның әниләр бәйрәме, әниләре турындагы белемнәрен киңәйтү, [ә] авазын ачык итеп әйтү осталыгын камилләштерү, әңгәмәдә катнашуга җәлеп итү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, хәтерен, диалоглы сөйләм формасын үстерү;<br>3) балаларда әниләргә мәхәббәт һәм аларга ярдәм итү теләге тәрбияләү. |
| **09.03.-31.03.** | **Халык җәүһәрләре** | "Теремкәй" рус халык әкиятен сөйләү | 1) балаларны әкиятне игътибар белән тыңларга, сюжетның эзлеклелеген күзәтә белергә өйрәтү;<br>2) Тычкан-Чыелдык, бака-Бакылдык, куян-Куркаккай, төлке-Хәйләбай, бүре-Соры колак, аю- Камыт аяк сүзтезмәләре хисабына балаларның сүзлеген активлаштырырга, ихүтибарны, ишетү, күрү хәтерен үстерү; 3) халык иҗатына кызыксыну тәрбияләү. |
| **01.04.-20.04.** | **Яз** | Бозау, колын, бәрән турында сөйлибез | 1) язгы табигатьнең характерлы үзенчәлекләре турында күзаллауларын киңәйтү, тәрбияче белән бергә уенчык турында кечкенә хикәя (2-3 җөмлә) төзергә, кире мәгънәдәге сүзләрне (зур - кечкенә, калын – нечкә) аера белергә өйрәтүне дәвам итү, балаларның аваз ияртемнәрен әйтә белүләрен ныгыту;<br>2) балаларның кабул итүләрен һәм монологлы сөйләмен, кул хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) балаларда хайваннар тормышына кызыксыну тәрбияләү. |
| **02.05.-31.05.** | **Җәй** | Автобуста сәяхәт | 1) сүзләрнең мәгънәсен аңларга өйрәтүне дәвам итү, балаларның аваз ияртемнәрен әйтә белүләрен, йорт хайваннары төшенчәсен ныгыту, йорт хайваннары, кошлар турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>2) кошларның, хайваннарның хәрәкәтен белдерә торган фигыльләр, иркәләп, яратып әйтелгән сүзләр хисабына сүзлекләрен активлаштыру, балаларның, игътибарын, хәтерен, кабул итүләрен үстерү;<br>3) тере һәм тере булмаган табигать күренешләренә кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Мин җәйне яратам | 1) табигатьтәге җәйге үзгәрешләр турындагы күзаллауларын киңәйтү, билгеле бер ситуациягә туры килгән фигыльләрне сөйләмдә куллануларын активлаштыру, сөйләмдә "бер", "күп" төшенчәләрен ныгыту;<br>2) балаларның игътибарын, диалоглы сөйләмен, уңай хис-кичерешләрен, кабул итүләрен үстерү; 3) табигатькә сакчыл караш тәрбияләү. |

## 3. Матур әдәбият белән таныштыру өлкәсе

| Сроклар | Бүлекләр | Тема | Бурычлар |
|---|---|---|---|
| **20.08.-10.09.** | **Сау бул, җәй! Исәнме, балалар бакчасы!** | З. Гомәрованың " Ул шуңа кечкенә" дигән шигырен уку | 1) балаларның шигъри әсәр белән таныштыру, эчтәлеген тыңлый һәм аңлый белү осталыгын формалаштыру, аерым сүзләрне, фразаларны тәрбияче артыннан кабатлау мөмкинлеге бирергә, сүзлекне активлаштыру;<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен, хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) әсәргә кызыксыну, сәламәт яшәү теләге тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Э.Мөэминова-ның “Үз телендә сөйләшә” шигырен уку | 1) балаларны Э. Мөэминованың “ Үз телендә сөйләшә” дигән шигыре белән таныштыру, тәрбияче артыннан аерым сүзләрне кабатларга өйрәтү;<br>2) кабул итүләрен, игътибарын, фикерләүләрен, туган телгә кызыксынуларын үстерү;<br>3) туган телгә мәхәббәт һәм аны өйрәнү теләге тәрбияләү. |
| | | Ә. Бикчәнтәева-ның “Туп” шигырен яттан өйрәнү | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү, сорауларга җавап бирүдә күнектерү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен, интонацияле сөйләмен үстерү;<br>3) балаларда кайгыртучанлык, бергә шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |
| **11.09.-30.09.** | **Көз** | “Аю белән Бабай” әкиятен уку. | 1) әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирү осталыгын камилләштерү, үсемлекләр турындагы белемнәргә төгәллек кертү, сүзлекне киңәйтү һәм активлаштыру;<br>2) кулның вак мускулларын, балаларның игътибарын, кабул итүләрен, диалогик сөйләмнәрен үстерү;<br>3) халык авыз иҗаты әсәрләренә мәхәббәт, тәрбияләү. |
| | | Ә. Ерикәйнең “Көз” шигырен яттан өйрәнү | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга, аны истә калдырырга һәм сәнгатьле итеп сөйләргә өйрәтүне дәвам итү, шигырьдәге килде, саргайды, шиңде, сибелде фигыльләре хисабына сүзлекне баету;<br>2) балаларның кабул итуләрен, хәтерен, күзәтүчәнлекләрен, игътибарлыкларын үстерү; 3) көзге матурлыкка соклану хисләре тәрбияләү. |
| | | М. Фәйзуллина-ның “Көзге яңгыр” шигырен уку | 1) шигырьнең эчтәлеге белән балаларны таныштыру, тәрбияче сөйләмен аңлау осталыгын камилләштерү, шигырьнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирергә өйрәтү, чикләнгән мәйданда йөгерүдә күнектерү;<br>2) кабул итүләрен, игътибарны, тәрбияче сигналы буенча йөгерү һәм зонтик астына качу осталыгын үстерү; 3) шигъри әсәргә кызыксыну, тыңлаучанлык тәрбияләү. |
| **1.10.-15.10.** | **Мин һәм минем гаиләм** | “Баш бармак...”шигъри әсәрен уку. | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру; бармак атамаларын истә калдыру,бармак уеннарына өйрәтү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, хәтерне, интонацияле сөйләмен, бармак хәрәкәтләрен үстерү; 3) халык аваз иҗатына хөрмәт, организм әгъзаларына сакчыл караш тәрбияләү. |
| | | Ә.Бикчәнтәеваның “ “Бәтиләр” шигырен уку | 1) шигырнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, йорт хайваннары турындагы белемнәрен киңәйтү һәм тирәнәйтү, сорауларга җавап бирүдә, аваз ияртемнәрен кабатлауда күнектерү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, сүзлеген, сенсор музыкаль ишетү сәләтен үстерү.<br>3) йорт хайваннарына карата кайгыртучанлык хисләре тудыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Ш. Маннурның “Яратам” шигырен яттан өйрәнү. | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, тәрбияче сорауларына җавап бирергә өйрәтүне дәвам итү, сүзлекне активлыштыру һәм баету, гомумиләштерә торган сүзне сөйләмдә куллануда күнектерү;<br>2) шигъри әсәрне яттан сөйләү теләге, кабул итүне, хәтерне, игътибарны үстерү;<br>3) гаиләгә карата хөрмәт, туганлык хисләре тәрбияләү. |
| | | Кем нәрсә ярата?” татар халык әкиятен сөйләү. | 1) әкиятнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, сорауларны аңлау һәм аларга җавап бирү осталыгын камилләштерү, балаларның йорт кошлары һәм хайваннары турындагы кузаллауларына төгәллек кертү, аваз ияртемнәрен ачык һәм дөрес әйтүдә күнектерү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, образлы фикерләүләрен, ишетү сәләтен үстерү; 3) кошларга, хайваннарга карата кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| **16.10.-04.11.** | **Минем йортым, минем шәһәрем** | “Әлли бәлли итәргә ...” бишек җырын уку. | 1) бишек җырының эчтәлеге белән таныштыру, тәрбияче сөйләмен аңлау сәләтен камилләштерү, сөйләмдә” тирбәтергә” фигылен куллана белергә өйрәтү;<br>2) кабул итүне, игътибарны, конкрет образлы фикерләүне үстерү;<br>3) сөйләм этикетының гади формулаларын (“Алсу йокың тәмле булсын!”) һәм бишек җырларын тормышта куллана белү теләге тәрбияләү. |
| | | Н. Каштанның “ Безнең сыер” шигырен уку. | 1) шигырьнең эчтәлеген балаларга аңларга ярдәм итү, тәрбияче сөйләмен аңлау осталыгын камилләштерү, кайбер сүзләрне ( мөгери, китер,йөгер,му – уу, су – у-у) әйтеп җибәрү, ү аваз ияртемнәрен әйтүдә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен үстерү;<br>3) йорт хайваннарына карата сакчыл караш,кайгыртучанлык тәрбияләү. |
| | | Җ. Тәрҗеманов-ның “ Үзен бик чиста йөртә” шигырен уку. | 1) балаларны яңа шигырь белән таныштыру, аның эчтәлеген аңлап, кабул итүләрен камилләштерү, сорауларга төгәл итеп җавап бирүдә күнектерү;<br>2) кабул итүләрен, игътибарын, хәрәкәтләрен, фикерләүләрен үстерү;<br>3) балаларда пөхтә һәм чиста йөрү теләге тәрбияләү. |
| | | “Олыга – утын ярырга” бармак уены | 1) фольклор әсәрләренә кызыксыну уяту; шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга өйрәтүне дәвам итү; 2) балаларның эмоциональ сферасын үстерү;<br>3) нәфис сүзгә мәхәббәт тәрбияләргә |
| **15.11.-31.12.** | **Яңа ел бәйрәме** | Б.Рәхмәтнең “ Кыш бабай” шигырен яттан өйрәнү. | 1) шигъри әсәр белән таныштыру, тәобияче ярдәме белән шигырьне яттан сөйләү омтылышын хуплау, сорауларга текст сүзләре белән җавап бирүдә күнектерү;<br>2) балаларның кабул итүләрен ,хәтерен, сүзлеген,игътибарын, хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) балаларда Кыш бабайга, Яңа ел бәйрәменә карата уңай эмоциональ хисләр тәрбияләргә. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | И.Шәймөхәммәтовның “Мактанчык бака” әсәрен уку. | 1) балаларны хикәя белән таныштыру, “мактанчык” сүзен сөләмдә активлаштыру, тәрбияче биргән сорауларга аңлап җавап бирүдә күнектерү, әйләнә-тирә турындагы белемнәрен киңәйтү;<br>2) балаларның кабул итүен,хәтерен,игътибарын,сүзлеген үстерү;<br>3) балаларда тыйнаклык, бергә шөгыльләнү теләге тәрбияләү. |
| | | Р. Вәлиеваның “Сүз тыңлаучан булыгыз” шигырен уку. | 1) балаларны Р.Вәлиеваның шигыре белән таныштырырга, сорауларга җавап бирү осталыгын активлаштырырга, “Җиһаз” сүзен актив сүзлеккә кертергә. Җиһаз атамаларын таный һәм атый белүләрен формалаштырырга.<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын , хәтерен, диалогик сөйләмен, классификацияли белүләрен үстерү;<br>3) куанычлылык, тыйнаклык, кунакта үз – үзеңне тота белү кагыйдәләрен тәрбияләргә. |
| **01.01.-31.01.** | **Кыш** | Һ.Такташның “Ләйлә” шигерен уку | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга дөрес җавап бирә белү осталыгын камилләштерү, тәрбияче артыннан аерым сүзләрне, фразаларны кабатларга мөмкинлек бирү, ел фасыллары турындагы белемнәрен тирәнәйтү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) кышкы табигатькә соклану хисе, башка кешеләрнең кичерешләрен аңлауны тәрбияләү. |
| | | Җ. Дәрзаманов-ның “Алмаз” шигырен уку**.** | 1) балаларны Җ. Дәрзамановның шигыре белән таныштыру, тәрбиячененң сорауларына җавап бирүдә күнектерү, җыр тыңлаганда активлык күрсәтергә өйрәтү;<br>2) кабул итүләрен, игътибарны, сүзлекне, музыкаль ишетү сәләтен үстерү;<br>3) дөрес киенү теләге һәм шигырьләргә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Ә.Бикчәнтәев-нең “Салкын саф һава” шигырен ятлау. | 1) балаларны шигъри әсәрнең эчтәлеге белән таныштыру, кышкы табигать турындагы белемнәрен тирәнәйтү, шигъри текстны истә калдырырга ярдәм итү;<br>2) сорауларга җавап бирү, әдәби сөйләм осталыгы үстерү;<br>3) шигъри әсәргә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| **01.02.-23.02..** | **Ватанны саклаучы-лар көне** | З. Туфайлова-ның “ Шофер булам” дигән шигырен уку. | 1) балаларны шигырьнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга җавап бирә белүләрен камилләштерү, сүзлекне баету һәм активлаштыру;<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарларын, конкрет - образлы фикерләүләрен үстерү; 3) шофер хезмәтенә карата кызыксыну һәм юл йөрү кагыйдәләрен үтәү теләген тәрбияләү. |
| | | Ә. Исхакның “Гүзәл” шигырен уку. | 1) шигырьнең эчтәлеге белән балаларны таныштыру, тәрбияче сорауларына аңлы рәвештә җавап бирү осталыгын камилләштерү, җырның сүзләренә туры килә торган хәрәкәтләр ясарга өйрәтү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, диалогик сөйләмен, хәрәкәтләрен үстерү; 3) балаларда культура – гигиеник күнекмәләрен тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| **24.02.-08.03..** | **Сигезенче Март** | Д. Аппакованың “Рөстәм” әсәрен уку. | 1) чәчмә әсәрнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, тәрбияченең сорауларына җавап бирүдә күнектерү; 2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, диалоглы сөйләмнәрен үстерү; 3) әдәплелек тәрбияләү. |
| | | “Чәбәк-чәбәк әбкәсе...” юаткычын уку | 1) балаларны юаткычның эчтәлеген күрсәтмәлектән башка гына тыңлый белү осталыгын формалаштыру; юаткычның кайбер сүзләрен тәрбияче артыннан кабатларга мөмкинлек бирү; 2) балаларның кабул итүен, игътибарын, кул һәм гәүдә хәрәкәтләрен үстерү; 3) татар халык авыз иҗатына карата кызыксыну, әниләргә карата хөрмәт тәрбияләү. |
| | | З. Туфайловның “Әни сүзе” шигерен ятлау. | 1) балаларны шигырь белән таныштыру, истә калдыру, тәрбияче биргән сорауларга шигырь сүзләре белән җавап бирергә өйрәтү; 2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, сәнгатьле сөйләмен, сенсор сәләтләрен, уңай эмоцияләрен үстерү; 3) әниләргә карата мәхәббәт тәрбияләү |
| | | Г. Нәбиуллин-аның “Әнигә булышам” шигырен уку. | 1) балаларны Г. Нәбиуллинаның шигыре белән таныштыру, бирелгән сорауларга җавап бирергә өйрәтү; 2) кабул итүләрне, игътибарны, хәтерне, диологик сөйләмне, кулларның вак маторикасын үстерү; 3) тырышлык, әниләргә ярдәм итү теләге, пөхтәлек тәрбияләү. |
| **09.03.-31.03.** | **Халык җәүһәрләре** | Л. Толстойның “Өч аю” әкиятен уку | 1) күләмебуенча зур булган әкиятне игътибар белән тыңларга һәм аңларга өйрәтү, балаларга әкиятне, алар кызның язмышы өчен дулкыналырлык һәм чишелешенең яхшы тәмамлануына шатланырлык итеп сөйләү, сүзлекне активлаштыру; 2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, фикерлүләрен үстерү; 3) балаларда интонацияле сәнгатьле сөйләм, кеше хәлен аңлый белүләрен, әкиятләргә кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Л. Толстойның “ Өч аю” әкиятен сөйләү | 1) күләме буенча зур булган әсәрне игътибар белән тыңларга һәм аңларга өйрәтү, эчтәлеген аңлауларына ирешү, башкаларның эмоциональ халәтен аңлый белергә өйрәтү; 2) игътибарны, диалоглы сөйләшүне,кабул итүне,хәтерне, интонацияле, сәнгатьле сөйләмне үстерү; 3) җиһазга карата сак караш, әйләнә тирәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен тәрбияләү. |
| | | Л. Толстойның “ Өч аю” әкиятен сөйләү | 1) балаларны яңа әкият белән таныштыру, әкият сюжетының башын күзәтергә өйрәтү, әкият геройларының характерлы билгеләренә, хәрәкәтләренә балаларның игътибарын җәлеп итү; 2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, хәтерен, хәрәкәтләрен, сөйләм активлыгын үстерү; 3) балаларда халык әкиятләренә кызыксыну тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | “Төлке, Куян һәм Әтәч” әкиятен сөйләү | 1) рус халык әкиятен балаларның исләренә төшерү, сюжетның үсеше артыннан күзәтү, әкиятнең эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирерә өйрәтү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, хәтерен, игътибарын, фикерләвен, интонацияле сәнгатьле сөйләмне үстерү;<br>3) балаларда кеше хәленә керә белүчәнлекне, кайгыртучанлык, ярдәм итүне, бер-берсенә карата игътибарлылык, дуслык тәрбияләү |
| **01.04.-20.04.** | **Яз** | Д. Гарифуллин-ның “ Тавыклар һәм Таһир” шигырен уку | 1) шигъри әсәр белән таныштыру, йорт кошлары турындагы белемнәрне тирәнәйтү, сорауларны аңлап ,дөрес җавап бирдә күнектерү, аваз ияртемнәре әйтелешен кабатлау, бер һәм күп төшенчәләрен ныгыту;<br>2) балаларның кабул итүләрен, хыял итүләрен, игътибарын, тәрбиячене ишетә белү осталыгын, кул хәрәкәтләрен, иҗадилыкларын үстерү;<br>3) балаларда йорт кошларына карата  кайгыртучанлык ,үзләре башкарган эшкә шатлана белүләрен тәрбияләү. |
| | | Р. Батулланың “ Елак әтәч” әсәрен уку | 1) әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга дөрес һәм аңлап җавап бирүдә күнектерү, төрле орлыкларны (бодай, дөге) аера белүләрен формалаштыру;<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын үстерү, кул чукларының вак мускулларын, сөйләмнәрен активлаштыру;<br>3) тешләрне саклау,аларны карау теләге ,кайгыртучанлык хисләре тәрбияләү. |
| | | Б. Рәхмәтнең “Яз” шигырен ятлау | 1) балаларны Б. Рәхмәтнең “Яз” шигере белән таныштыру, истә калдырырга ярдәм итү, эчтәлегенә туры китереп, сорауларына җавап бирергә өйрәтү, яз турындагы белемнәрне киңәйтү;<br>2) кабул итүне, игътибарны, хәтерне, сөйләмнең интонацияле сәнгатьле үстерү;<br>3) шигырьгә язгы табигатькә карата кызыксыну тәрбияләү. |
| | | Х.Вахитның “Уңган сыерчык” шигырен уку | 1) балаларны шигырь белән таныштыру, тәрбияче сорауларның шигырь сүзләре белән җавап бирүне ныгыту, музыка астында түгәрәктә бер – берсенә комачауламый йөрүләрен формалаштыру, кошлар турындагы белемнәрне киңәйтү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, диалогик сөйләмен, хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) балаларда туган якка мәхәббәт, сыерчыкларга карата кызыксыну тәрбияләү. |
| **02.05.-31.05.** | **Җэй** | ”Тилгән” эндәшен уку | 1) балаларны күләме буенча зур булмаган шигъри әсәрне тыңларга һәм аңларга өйрәтүне дәвам итү, шигырьдәге аерым сүзләр һәм фразалар хисабына сүзләрне киңәйтү, сүзләрне истә калдырырга ярдәм итү, кошлар (тилгән) турындагы белемнәрне тирәнәйтү;   2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын, конкрет – образлы фикерләвен үстерү;   3) балаларда дөрес интонацияле сөйләм тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Аю белән хатын әкиятен уку | 1) әкиятнең эчтәлеге белән таныштыру, сорауларга аңлап җавап бирү осталыгын камилләштерү, сүзлекне киңәйтү, активлаштыру. [3] авазын ачык әйтүдә күнектерү;<br>2) балаларның игътибарын, кабул итүләрен, фикерләүләрен, чикләнгән бүлмәдә йөгерүләрен үстерү;<br>3) халык авыз иҗатына мәхәббәт, мәрхәмәтлелек, кеше хәленә керә белүчәнлек тәрбияләү. |
| | | Җ. Тәрҗеманов-ның “ Кикрикүк” шигырен уку. | 1) шигъри әсәрнең эчтәлеген аңларга ярдәм итү, сорауларны аңлау осталыгын камилләштерү, тема буенча сүзлекне баету һәм активлаштыру, тәрбияче артыннан аерым фразаларны кабатлауда һәм аваз ияртемнәрен дөрес әйтүдә күнектерү;<br>2) балаларның кабул итүләрен, игътибарын диалогик сөйләм осталыгын, вакыт өлешләрендә ориентирлануларын, бармак хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) балаларда әдәби әсәргә кызыксыну тәрбияләү. |
| | | М. Мазуновның “Кәҗә” шигырен уку | 1) шигырьнең эчтәлеге белән балаларны таныштыру, сорауларга бәйләнешле итеп җавап бирүдә, аваз ияртемен дөрес әйтүдә күнектерү;<br>2) балаларның кабул итүен, игътибарын, фикерләвен, бәйләнешле сөйләмен, кул хәрәкәтләрен үстерү;<br>3) кәҗәгә карата уңай караш, кайгыртучанлык тәрбияләү. |

**Зурлар төркеме ( 5-6 яшь)** балалары өчен **“Туган телдә сөйләшәбез” укыту –методик комплекты** Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының (23.11. 2009)655 нче номерлы боерык нигезендә расланган “Мәктәпкәчә мәгарифнең төп гомуми белем бирү программасы структурасына федераль дәүләт таләпләре” (алга таба ФДТ.-авт.),Татарстан республикасының 2010-2015 елларга мәгариф системасын үстерү стратегиясе кысаларында балалар бакчаларында балаларга туган телне өйрәтүне ,сөйләм үстерү, әдәби телдә сөйләшү күнекмәләре булдыру юнәлешен тормышка ашыру максатын күздә тотып төзелде.Ул түбәндәге бурычларны билгели:

- Балаларны ана телендә дөрес һәм яхшы итеп сөйләшергә өйрәтү;
- Тел системасының фонетик, лексик, грамматик төзелеше дәрәҗәләрен формалаштыру;
- бәйләнешле сөйләм үстерү;
- Тел һәм сөйләм күренешләрен аңлау(тоемлау) сәләте булдыру

ФДТ дә билгеләнгән 4 төп тәрбия юнәлеше үсешенә нигезләнеп,

(1-“Физик үсеш,” 2 “Социаль-шәхси үсеш”, 3-“Танып белү-сөйләм үсеше,” 4- “Нәфис-нәфасәти үсеш”) комплекслы – тематик план төзелде. План ел дәверендә “Минем бакчам”, “Мин яратам сине Татарстан”, “Саулык –зур байлык,” “Исемең матур кемнәр куйган, ” “Кунак булсаң- тыйнак бул” “Исәнме мәктәп, ” “Кояш системасы,” “Дуслык белән көчле без, “Идел буе мозаикасы” һәм башка күп проектлар балалар тормышын чагылдыручы, үсемлек һәм тереклек дөньясына кагылышлы, экологик культура, табигатькә аңлы караш, туган җиргә, телгә мәхәббәт тәрбияләүгә булышлык итүче шигырьләр, әкиятләр, хикәяләр; нәниләрдә кешелеклелек хисләре, үз-үзеңне тоту күнекмәләре, өлкәннәргә хөрмәт тәрбияләүгә, нәрсә – яхшы, нәрсә – начар, үзара дустанә мөнәсәбәтләргә, тормыш куркынычсызлыгы нигезләренә, юл хәвефсезлеге кагыйдәләренә, табигатьтә үз-үзеңне тоту күнекмәләренә кагылышлы эшчәнлекне үз эченә ала.

**Эшчәнлек оештыру конспектлары**

| Тема | Актив сүзләр, Сөйләм урнәге | Аудиоязма, Эш дәфтәре,Мультфильм |
|---|---|---|
| **(Сентябрь) «Яхшы сүз-җан азыгы»- 4 сәгать** | | |
| 1.1Танышу<br><br>1.2“Шалкан”әкияте (катнаш эшчәнлек)<br><br>2.1Сыйла | Исәнме, хәерле иртә, песи Мияу,эт Акбай. Син малаймы? Әйе, мин малай. Юк, мин кыз.<br>Шалкан,әти,әни,кыз,малай,песи,эт,әби,бабай.<br><br>Бу өй матур, бу өй зур. | Аудиоязма №1 . Дәфтәрдә эш №1<br><br>Мультфильм: 1. “Шалкан” |

| | | |
|---|---|---|
| 2.2“Баллы кишер”әкияте (катнаш эшчәнлек) | Мин зур, матур, кил монда, утыр, аша, эч,сикер, бир<br><br>Баллы. Баллы кишер. Баллы алма.<br>Зур кишер.Тәмле кишер | 2. “Баллы кишер” |
| **Абдулла Алиш иҗаты – 2 сәгать** | | |
| 3.1Абдулла Алиш - балалар язучысы.<br><br>3.2“Бар матур бакча” (катнаш эшчәнлек) | Кызым, йомшак , куянкай, авырта<br><br>Баллы. Баллы кишер. Баллы алма.<br>Зур кишер.Тәмле кишер. | “Куян кызы” әкиятен уку.<br><br>Аудиоязма<br>Җырлы-биюле уен «Бар матур бакча». |
| **Хуш киләсең, ямьле көз! -2 сәгать** | | |
| 4.1Җәйләр үтте, көзләр җитте.<br><br>4.2“Бар матур бакча” (катнаш эшчәнлек) | Көз килде.Җил исә. Яңгыр ява. Көз,сары яфрак, сап-сары, яфрак ята. Нинди? Яфраклар кызыл; сары , яшел яфраклар ята.<br><br>Баллы кишер,зур,тәмле кишер,бәрәңге,суган, кыяр. | <br><br>Җырлы-биюле уен «Бар матур бакча». |
| **(Октябрь) Көз күчтәнәчләре - 2 сәгать** | | |
| 1.1Бар матур бакча. Түтәлләрдә үсте яшелчә.<br><br>1.2Яшелчәләр кибете. (катнаш эшчәнлек) | Нинди? Ничә?<br>- Кы-кы-кы-кыяр - бу яшел кыяр.<br>Ки-ки-ки- кишер -бу зур кишер.<br>Су-су-су-суган - бу әче суган.<br><br>Кыяр,суган,кәбестә,бәрәңге. Саннар.Төсләр. | Аудиоязма № 6.<br>З.М.Зарипова “Татарча сөйләшәбез” 5 -6 яшь, 15-17 бит . К.В. Закирова “Балачак аланы”, 512 бит.<br><br>К.В.Закирова «На поляне детства» (163с) «Шалкан» әкияте буенча шәүлә театры. |
| **Мин яратам сине, Татарстан- 3 сәгать** | | |
| 2.1Туган җирем- | Татарстан. Казан, республика, флаг, герб, гимн. | “Туган телдә сөйләшәбез”. Методик |

| | | |
|---|---|---|
| Татарстан.<br><br><br>2.2Уйный- уйный эшлибез.(катнаш эшчәнлек)<br><br>3.1Туган ил кайдан башлана? | <br><br><br>Кыяр,суган,кәбестә,бәрәңге,кишер.<br><br><br>Казан, матур шәһәр, (Казанда татарлар, башкортлар, руслар, чувашлар яши.) Алар дус яши. | кулланма өчен аудио-кушымта 4-5 яшь № 14-15. З.М.Зарипова, “Туган телдә сөйләшәбез”, 16бит. Аудиоязма 8. К.В.Закирова «Бала-чак аланы» (277б.)Анимацион сюжет (15 тема).<br>фоторәсемнәр “Виды города Казани” Изучаем русский язык.6-7лет. Аудио –кушымта.№73. Аудио-кушымта 4-5 яшь № 58. |
| **Төсләр дөньясы – 3 сәгать** | | |
| 3.2Төсле туплар. (катнаш эшчәнлек)<br><br>4.1Төсләр дөньясы.<br><br><br><br><br>4.2Юл маҗаралары. (катнаш эшчәнлек) | Кызыл,сары,сикер,туп.<br><br><br>Сары, кызыл, яшел, зәңгәр Кызыл-кып-кызыл; сары-сап-сары, яшел.<br><br><br><br><br>Кызыл,сары,сикер,яшел | .Аудиоязма 13 нче кисәк. Ковробук, муляжлар,рәсемнәр, курчак театры өчен атрибутлар.<br>“Татарча сөйләшәбез” 5-6 яшь, 24-27 бит. З.М. Зарипова,Р.С.Исаева ”Үстерешле уеннар”45 бит. Р.С.Исаева “200 игр” часть 2,12 бит. 9 уен.<br><br>К.В. Закирова «На поляне детства» (153-154 с.).Анимацион сюжет (18 тема). |
| **(Ноябрь)Кем эшләми, шул ашамый – 2 сәгать** | | |
| 1.1Яшелчә салаты.<br><br>1.2Уңыш бәйрәме. (катнаш эшчәнлек) | Салат ясау өчен яшелчәләр.<br><br>Нәрсә бар?<br>Нәрсә кирәк? | З.М.Зарипова “Татарчасөйләшәбез” 5 -6 яшь, 28 бит.<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (230 с.) Ковробук, лепбук, |
**2 балл** – бала җавап биргәндә 2-3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә. Тәрбияче ярдәм иткәндә таныш әкиятне сәхнәләштерүдә катнаша.

Тәрбияче: - Балалар, камыр малайны пешергәннәр

Бала: әби белән бабай.

Тәрбияче: - Камыр малайны

Бала: Тәрәзә төбенә куйганнар.

Тәрбияче: Камыр-курчак кипкәч,

Бала: Тәрәзәдән сикереп төшә.

Тәрбияче: Камыр малай йөгереп китә, йөгерә-йөгерә

Бала: Урманга җитә.

**3 балл** – бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үзенең инициативасы яки тәрбияченең үтенече буенча картинада сурәтләнгәнне сөйли ала. Әкиятнең эчтәлеген сөйләгәндә эзлеклелекне саклап сәхнәләштерүдә теләп катнаша.

**Югары дәрәҗә** - 10-12 балл.

**Уртача дәрәҗә** - 6-9 балл.

**Түбән дәрәҗә** - 3-5 балл.

**“Туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү” буенча баланың персональ картасы**

| Баланың исеме фамилиясе | Баланың сүзлек запасы | Сөйләмнең грамматик ягы | Сөйләмнең аваз культурасы | Бәйләнешле сөйләм | Гомуми үсеш дәрәҗәсе | Индивидуаль эш өчен тәкъдимнәр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |

**Икенче кече яшьтәгеләр төркемендә сөйләм телен үзләштерү дәрәҗәләренә диагностика**
**Диагностик биремнәр (5-14 ноябрь)**

**1. Баланың сүзлек запасы**

1). Дидактик уен “Бу нәрсә?”

Материал: савыт-саба, йорт җиһазлары, йорт хайваннары, кыргый хайваннар, киемнәр сурәтләнгән предметлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага савыт саба (тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, табак) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Савыт-саба).

Тәрбияче балага йорт җиһазлары (карават, өстәл, урындык, шкаф) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт җиһазлары).

Тәрбияче балага йорт хайваннары (эт, песи, сыер, кәҗә) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт хайваннары).

Тәрбияче балага кыргый хайваннар (куян, төлке, аю) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы хайваннарны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Кыргый хайваннар).

Тәрбияче балага киемнәр (күлмәк, куртка, башлык) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Киемнәр).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – предметларның исемен атаганда авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана алмый.

**2 балл** – предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә хаталар җибәрә.

**3 балл** – предметларның исемен дөрес атый, гомумиләштерүче сүзләрне дөрес билгели.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

1). Дидактик уен “Кем нәрсә эшли?”

Материал: китап укучы әни, өрә торган эт, уйный торган малай, рәсем ясаучы кыз сурәтләнгән сюжетлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага китап укучы әни төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Әни). Әни нәрсә эшли? (Укый). Әни нәрсә укый? (Әни китап укый).

Тәрбияче балага өрә торган эт төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу нәрсә? (Эт). Эт нәрсә эшли? (Эт өрә). Ул ничек өрә? (Эт һау-һау дип өрә).

Тәрбияче балага уйный торган малай төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Малай). Малайның исеме ничек? (Бала малайга исем биреп карый). Малай нәрсә эшли? (Малай уйный). Ул нәрсә белән уйный? (Ул машина белән уйный).

Тәрбияче балага рәсем ясаучы кыз төшерелгән сюжетлы картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу кем? (Кыз). Кызның исеме ничек? (Бала кызга исем биреп карый). Кыз нәрсә эшли? (Кыз рәсем ясый). Ул нәрсә белән рәсем ясый? (Ул карандаш белән рәсем ясый). Кыз нәрсә рәсеме ясый? (Кыз кояш рәсеме ясый).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала биремнәрне үти алмый. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә бала хаталар ясый.

**2 балл** – бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбияченең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

**3 балл** – бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбияченең сорауларына җавап биргәндә җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбияченең сорауларына теләп, ышанычлы итеп җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

1). Дидактик уен “Бу нәрсә? Ул ничек кычкыра?”

Материал: ат, кәҗә, тавык, каз, карга сурәтләнгән картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага ат (кәҗә, тавык, каз, карга) төшерелгән картинка күрсәтә һәм сораулар бирә: - Бу нәрсә? (Ат). Ат ничек кешни? (Их-ха-ха). - Бу нәрсә? (Кәҗә). Кәҗә ничек кычкыра? (Ме-е-е). - Бу нәрсә? (Тавык). Тавык ничек кыткылдый? (Кыт-кыт). - Бу нәрсә? (Каз). Каз ничек каңгылдый? (Ка-ка-ка). - Бу нәрсә? (Карга). Карга ничек каркылдый ? (Кар-кар).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала 1-2 биремне генә үти ала.

**2 балл** – бала биремнәрне тәрбияче ярдәме белән башкара, аның артыннан кабатлый.

**3 балл** – бала биремнәрне теләп башкара. Аваз ияртемнәрен дөрес һәм ачык итеп әйтә.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

1). Сюжетлы картина буенча әңгәмә

Материал: кар бабай ясаучы балалар сурәтләнгән сюжетлы картинка.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

- Карагыз әле, Йомшаккай бик матур бер картинка ясаган. – Бу картинкада кем ясалган? – Балалар нәрсә эшлиләр? - Картинка сиңа ошыймы?

2). “Камыр малай” әкиятен сәхнәләштерү.

Тәрбияче өстәл театры фигуралары куллана, балаларга сәхнәләштерүдә катнашырга тәкъдим ясый.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала сорауларга ишарәләр яки бер сүз белән генә җавап бирә. Әкиятне сәхнәләштерүдә авырлыклар кичерә. Тәрбияче артыннан аерым сүзләрне генә кабатлый.

Тәрбияче: - Балалар, камыр малайны пешергәннәр әби белән

Бала: Бабай.

Тәрбияче: - Камыр малайны тәрәзә төбенә

Бала: Куйганнар.

Тәрбияче: Камыр-курчак кипкәч, тәрәзәдән

Бала: Сикереп төшә.

Тәрбияче: Камыр малай йөгереп китә, йөгерә-йөгерә урманга

Бала: Җитә.

**2 балл** – бала җавап биргәндә 2-3 сүздән торган гади җөмләләргә өстенлек бирә. Тәрбияче ярдәм иткәндә таныш әкиятне сәхнәләштерүдә катнаша.

Тәрбияче: - Балалар, камыр малайны пешергәннәр

Бала: әби белән бабай.

Тәрбияче: - Камыр малайны

Бала: Тәрәзә төбенә куйганнар.

Тәрбияче: Камыр-курчак кипкәч,

Бала: Тәрәзәдән сикереп төшә.

Тәрбияче: Камыр малай йөгереп китә, йөгерә-йөгерә

Бала: Урманга җитә.

**3 балл** – бала гади (кем? нәрсә?) һәм катлаулы (кемгә? нинди? кайчан? кайда? кая?) сорауларга җавап бирә. Үзенең инициативасы яки тәрбияченең үтенече буенча картинада сурәтләнгәнне сөйли ала. Әкиятнең эчтәлеген сөйләгәндә эзлеклелекне саклап сәхнәләштерүдә теләп катнаша.

**Югары дәрәҗә** - 10-12 балл.

**Уртача дәрәҗә** - 6-9 балл.

**Түбән дәрәҗә** - 3-5 балл.

**Диагностик биремнәр (21-31 март)**

**1. Баланың сүзлек запасы**

1). Дидактик уен “Бу нәрсә?”

Материал: савыт-саба, йорт җиһазлары, йорт хайваннары, кыргый хайваннар, киемнәр сурәтләнгән предметлы картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага савыт-саба (тәлинкә, чынаяк, чәй тәлинкәсе, чәйнек) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Савыт-саба). – Чәйнекнең борынын күрсәт. - Хәзер чәйнекнең капкачын күрсәт. – Чынаякның тоткасын күрсәт.

Тәрбияче балага йорт җиһазлары (карават, өстәл, урындык, шкаф) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт җиһазлары). – Өстәлнең аякларын күрсәт. – Урындыкның аркасын күрсәт. – Шкафның ишеген күрсәт.

Тәрбияче балага йорт хайваннары (эт, песи, сыер, кәҗә) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Йорт хайваннары). - Этнең колакларын күрсәт. – Песинең койрыгын күрсәт. - Сыерның мөгезен күрсәт. - Кәҗәнең сакалын күрсәт. Тәрбияче балага кыргый хайваннар (куян, төлке, аю) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм андагы хайваннарны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу хайваннарны бер сүз белән ничек атарга була? (Кыргый хайваннар). – Куянның тәпиләрен күрсәт. – Төлкенең борынын күрсәт. – Аюның гәүдәсен күрсәт.

Тәрбияче балага киемнәр (күлмәк, куртка, башлык) сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм предметларны атарга куша: - Бу нәрсә? - Бу предметларны бер сүз белән ничек атарга була? (Киемнәр). – Күлмәкнең җиңен (якасын, кесәләрен, сәдәфләрен) күрсәт.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – предметларның исемен, мөһим детальләрен, өлешләрен атаганда һәм күрсәткәндә авырлыклар кичерә, гомумиләштерүче сүзләрне куллана алмый.

**2 балл** – предметларның исемен дөрес атый, мөһим детальләрен, өлешләрен күрсәткәндә, гомумиләштерүче сүзләрне белдергәндә хаталар җибәрә.

**3 балл** – предметларның исемен, мөһим детальләрен, өлешләрен дөрес атый һәм күрсәтә, гомумиләштерүче сүзләрне дөрес билгели.

**“Бу кайчан була?” үстерелешле уены**

Балаларга тәүлек өлешләре сурәтләнгән карточкалар күрсәтелә. Тәрбияче тәүлек өлешенә туры килгән күренешләрне атый һәм сорау бирә, балалар тиешле карточканы табалар.

1. Кояш чыга, әтәчләр кычкыра, балалар бакчага барырга жыена, эти-әниләр эшкә китәләр. - Бу кайчан була? Бу тәүлек өлешенә туры килгән карточканы табып күрсәтегез.

2. Кояш яктырак карый, күзләрен киңрәк ача, балалар урамда уйный, төшке аш ашыйлар. - Бу кайчан була? Шушы тәүлек өлешенә туры килгән карточканы табып күрсәтегез.

3. Кояшкүзләрен йома, балалар бакчадан, эти-әниләр эштән өйләренә кайта, кичке аш ашыйлар, балалар “Тыныч йокы, нәниләр” тапшыруын карыйлар. - Бу кайчан була? Бу тәүлек өлешенә туры килгән карточканы табып күрсәтегез.

4. Кояш йоклый, ай яктырта, күк йөзендә йолдызлар яна, бар кешеләр дә йоклый. - Бу кайчан була? Бу тәүлек өлешенә туры килгән карточканы табып күрсәтегез.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – тәүлек өлешләрен аера белми.

**2 балл** – өстәмә сораулар биргәндә генә тәүлек өлешләрен аера һәм дөрес атый.

**3 балл** – тәүлек өлешләрен аера һәм дөрес атый.

**2. Сөйләмнең грамматик ягы**

1). Дидактик уен “Кем нәрсә эшли?”

Материал: Йомшаккай уенчыгы, төрле кошлар һәм җәнлекләр сурәтләнгән картинкалар.

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балаларга Йомшаккай турында сөйли: “Безнең Йомшаккайның дуслары бик күп. Дусларының кем икәнен белергә телисезме? Ул аларның фотографияләрен алып килгән. (тәрбияче бер һәм күп куяннар, үрдәкләр, колыннар, чебиләр, көчекләр, сыерлар, бәрәннәр сурәтләнгән картинкалар күрсәтә һәм сораулар бирә: Бу нәрсә? (Бер куян сурәтләнгән картинка күрсәтә). (Куян). Бу нәрсә? (Куяннар сурәтләнгән картинка күрсәтә). (Куяннар). Башка картинкалар белән эш шушы рәвешле алып барыла.

Тәрбияче сөйләвен дәвам итә: “Йомшаккай кошлар һәм җәнлекләр белән качышлы уйнарга ярата. Сез күзләрегезне йомыгыз. Йомшаккай кача. (Тәрбияче Йомшаккайны шкаф артына (эченә, өстенә, астына, янына) качыра.

Балалар күзләрен ачалар һәм  Йомшаккайны эзлиләр һәм аның кайда качканын әйтәләр. Мәсәлән: “Йомшаккай шкаф артына качкан”.

Тәрбияче сөйләвен дәвам итә: “Җәнлекләр һәм кошларны  эниләре эзләп килгән. Әйдәгез эниләренә аларны табарга булышыйк”. (Тавык сурәтләнгән картинка куела). Тавык (сыер, эт, ат, сарык, куян)  нәрсәне алырга килгән? Тавык чебине алырга килде.(Шул рәвешле куян куян баласын, сыер бозавын, эт көчеген, сарык бәрәнен, ат колынын таба).

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала биремнәрне үти алмый. Тәрбияченең сорауларына җавап бирә алмый. Тәрбияче актив ярдәм күрсәткәндә дә бала хаталар ясый.

**2 балл** – бала биремнәрне үтәргә тырыша, тәрбияченең сорауларына бер сүз белән генә җавап бирә.

**3 балл** – бала биремнәрне дөрес үти. Тәрбияченең сорауларына җавап биргәндә берлек һәм күплек сандагы исемнәрне, **бәйлек сүзләрне (эченә, өстенә, астына, янына),** кошлар һәм җәнлекләр, аларның балалары атамаларын сөйләмдә дөрес куллана,   җөмләләрне грамматик яктан дөрес төзи. Җөмләләрнең иясе һәм хәбәре бар. Тәрбияченең сорауларына теләп,  ышанычлы итеп җавап бирә.

**3. Сөйләмнең аваз культурасы**

1). Дидактик  уен “Минем кебек әйт”

Диагностик биремнең эчтәлеге:

Тәрбияче балага  үзе әйткән сүзләрне игътибар белән тыңлап, нәкъ шулай итеп кабатларга куша һәм сорау бирә: “Бу сүзләрдә нинди аваз бар?” Тәрбияче, әле бер, әле икенче авазны аерып, сүзләрне я кычкырып, я тыныч тавыш белән, я пышылдап әйтә. Мәсәлән: “Минем кебек әйт”.

А: Аааалсу, ааат, кааз, боткааа.

Ә: Әәәәмир, мәәәк, кәәәҗәәә.

О: ооон, йооорт, ооонык, кооолын.

Ө: өөөй, өөөстәл, көөөзге, көөөймә.

У: ууурман, ууенчык, кууян, куурчак.

Ү: үүүлән, үүүрдәк, күүүбәләк, үүүрмәкүүүч.

И: Иииинсаф, ииипиии, тииен, машииина, әниии.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала кирәкле авазны ишетми, күп сүзләрне дөрес интонация белән әйтми, хаталар ясый.

**2 балл** – бала  күп сүзләрне дөрес кабатлый,  дөрес  интонация белән әйтә, тәрбияче ярдәме белән кирәкле авазны билгели ала.

**3 балл** – бала кирәкле авазны ишетә, кабатлый, аны мөстәкыйль рәвештә дөрес интонация белән әйтеп, авазны билгели ала.

**4. Бәйләнешле сөйләм**

1). Сораулар буенча әңгәмә. – Синең өйдә нинди уенчыкларың бар? Син алар белән ничек уйныйсың? Кем белән уйныйсың? жгщмщСюжетлы картина буенча әңгәмә

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала бер уенчыкны гына атый.

**2 балл** – бала уенчыкларны санап кына чыга.

**3 балл** – бала үзенең шәхси тәҗрибәсенә нигезләнеп 3-4 җөмләдән торган хикәя төзи.

2). Тәрбияче балага Л.Толстойның "Өч аю" әкиятен сөйләргә тәкъдим итә. – Син "Өч аю" әкиятен беләсеңме? Аны сөйлә әле.

**Бәяләү критерийлары**

**1 балл** – бала әкият эчтәлегенә кагылышлы кайбер сүзләрне генә әйтә ала.

**2 балл** – бала тәрбияче биргән сораулар ярдәмендә генә әкиятнең эчтәлеген сөйли.

**3 балл** – бала әкиятнең эчтәлеген мөстәкыйль сөйли ала.

**Югары дәрәҗә** - 15-18 балл.

**Уртача дәрәҗә** - 11-14 балл.

**Түбән дәрәҗә** - 7-10 балл

**"Туган телгә өйрәтү һәм сөйләм үстерү" буенча баланың персональ картасы**

| Баланың исеме фамилиясе | Баланың сүзлек запасы | Сөйләмнең грамматик ягы | Сөйләмнең аваз культурасы | Бәйләнешле сөйләм | Гомуми үсеш дәрәҗәсе | Индивидуаль эш өчен тәкъдимнәр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |
| | | | | | | |

# Рус төркемендә тәрбияләнүче татар балаларының ана телен үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү (зурлар төркеме)

## Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр

| Танып белү | Аралашу | Матур әдәбият уку |
|---|---|---|
| -транспорт төрләрен кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне белү;<br>-предметның төсе, күләме, формасы, зурлыгы, авырлыгы, нинди мате-риалдан эшләнгән булуы турында сөйли алу, аларны төркемләү;<br>- төрле һөнәрләр (төзүчеләр, авыл эшчәннәре һ.б.)турында белү;<br>- туган шәһәрең (авылың), туган илең, аның башкаласы, юл йөрү кагыйдәләрен белү;<br>- үз туганнары, үзе турында сөйли алу, өй адресын әйтү;<br>- табигать күренешләрен күзәтеп, алар арасындагы бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара алу, кайбер закончалыкларны белү. | - сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллану, туры һәм кыек сөйләмнән файдалану;<br>- үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча мөстәкыйль рәвештә хикәя төзү;<br>- әкиятләрнең ахырын тәмамлау, зур булмаган әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә интонацияләрдән дөрес файдалану;<br>- сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләр куллану;<br>- мәгънәдәш сүзләр һәм капма-каршы сүзләр куллану;<br>- аралашуда актив булу, теләп катнашу. | - әсәрнең жанрын билгели алу (әкият, хикәя, шигырь);<br>- зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерү, рольләргә бүлеп шигырьләрне сөйләү;<br>- яраткан язучыларны атый белү;<br>-укыту методик комплектында күрсәтелгән 2-3 шигырьне сөйләү, табышмак, мәкальләрне искә төшереп әйтү;<br>- әдәби персонажның кылган гамәлләре турындагы фикерләрен башкаларга сөйләү;<br>- үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйли белү. |

## Балаларның белем дәрәҗәләре үсеше күрсәткече

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы | | | Бәйләнешле сөйләм | | | Фольклор ( мәкаль, табышмак) | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Ягымлы сүзләр куллану | Сүзләрне гомуми-ләштерү | Капма-каршы сүзләр | Үзең турында сөйләү | “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану | Аралаша белү (диалог) | | Баллар | Дәрәҗә |
| 1. | Дамир | | | | | | | | | |
| 2. | Алсу | | | | | | | | | |
| 3. | ... | | | | | | | | | |
| **Нәтиҗәләрне бәяләү** | | | | | | | | | | |
| **Югары дәрәҗә** | | | | | | | | | | |

| | |
|---|---|
| 17-21 балл | **Бала сөйләмдә актив, диалогта үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.** |
| **Уртача дәрәҗә**<br>12-16 балл | **Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.** |
| **Уртачадан түбән дәрәҗә**<br>1-11 балл | **Аңлый, русча җавап бирә.** |

## Танып белү

**Югары дәрәҗә (3 балл).** Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне таный һәм әйтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре ( төсе, күләме, формасы, зурлыгы, авырлыгы, нинди материалдан булуы) турында сөйли , аларны төркемли белә. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында белә. Юл йөрү кагыйдәләрен дөрес әйтә. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә.Үз туганнары, үзе турында сөйли, адресын әйтә.Табигатьтәге кайбер закончалыклырны белә, алар арасындагы бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә. Предмет һәм аның үзенчәлекләре ( төсе, формасы, күләме, нинди материалдан булуы) турында тулысынча сөйләми, исенә төшергәч, өстәп сөйли белә,төремли ала. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматны тулысынча биреп бетерә алмый. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында белә.Үз туганнары, үзе турында аз сөйли, сораулар биргәч, үзлектән тулыландыра.Табигатьтәге кайбер закончалыклырны аңлатканда, үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгарганда кыенлыклар кичерә.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Бала транспорт төрләрен, кеше тормышын җиңеләйтә, уңайлыклар тудыра торган әйберләрне атаганда хата җибәрә.. Предмет һәм аның үзенчәлекләре ( төсе, күләме, формасы, зурлыгы, авырлыгы, нинди материалдан булуы) турында тәрбияче ярдәменнән башка сөйли белми , төркемли алмый. Төзүче, транспорт хезмәткәрләре, авыл эшчәннәре хезмәте турында мәгълүматы юк. Туган иле, шәһәре (авылы), Россиянең, Татарстанның башкаласы турында әйтә белми.Үз туганнары, үзе турында тәрбияче ярдәмендә сөйли. Адресын белми.Табигатьтәге кайбер закончалыклырны аңлата, үзара бәйләнешләр турында нәтиҗә чыгара алмый.

## Аралашу

**Югары дәрәҗә (3 балл).** Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр куллана белә, туры һәм кыек сөйләмнән файдалана. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча мөстәкыйль рәвештә хикәя төзи.
Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген сөйләгәндә , иҗади хикәяләр төзегәндә интонацияләрдән дөрес файдалана. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләр куллана белә. Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйтә белә. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда теләп катнаша. Үстерешле аралашуда катнашу дәрәҗәсе камил.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Сөйләмдә төрле кушма җөмләләр кулланганда хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белә. Үз тәҗрибәсеннән чыгып, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә,бик мөстәкыйль түгел. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген тулы бирми , иҗади хикәяләр төзегәндә иҗади түгел. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләрне аз куллана . Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйткәндә хаталар җибәрә. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда катнаша, үстерешле аралашуда катнашуы камил дәрәҗәдә түгел.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Бала сөйләмдә гади җөмләләр куллана, үз тәҗрибәсеннән чыгып, начар сөйли, эчтәлекле рәсемнәр, картиналар буенча хикәя төзегәндә тәрбияче ярдәмен көтә. Әдәби әсәрләрнең эчтәлеген план буенча сөйли белми, иҗади хикәяләрнең эчтәлеге гади, интонацияләрдән файдаланмый. Сөйләмдә, башкалар белән аралашканда ягымлы сүзләрне аз куллана . Мәгънәдәш сүзләр, капма-каршы сүзләрне әйтми. Тәрбияче һәм балалар белән аралашуда сирәк катнаша, үстерешле аралашуда катнашуы юк дәрәҗәдә.

## Матур әдәбият уку

**Югары дәрәҗә (3 балл).** Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аера ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда актив катнаша, тиз истә калдырып, яттан сөйли. Язучыларны таный һәм атый белә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сөйләмдә мөстәкыйль куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйләп бирә ала.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аерганда ялгышлыклар җибәрә, ләкин тәрбияче ярдәмендә үзлектән төзәтә ала. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда активлык күрсәтми, ләкин катнаша. Язучыларны таный, әсәрләрен әйтүдә кыенлыклар кичерә. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны сирәк куллана. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя биргәндә, хаталар җибәрә. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга тулы итеп сөйләми.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Әсәрнең жанрын (әкият, хикәя) аера алмый. Зур булмаган әсәрләрне сәхнәләштерүдә, рольләргә бүлеп шигырьләр укуда катнашырга теләге юк. Язучыларны таныймый, әсәрләрен әйтә алмый. Шигырьләрне, мәкальләрне, санамышларны кулланмый. Әдәби персонажларның кылган гамәлләренә бәя бирә белми. Үзенең яраткан китабы турында башкаларга сөйли белми.

# Рус төркемендә тәрбияләнүче татар балаларының ана телен үзләштерү дәрәҗәсен билгеләү (мәктәпкә әзерлек төркеме)

## Ел ахырында үзләштерелергә тиешле белем һәм күнекмәләр

| Танып белү | Аралашу | Матур әдәбият уку |
|---|---|---|
| - сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллау;<br>- экологик бәйләнешләрне аңлата алу, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысын белү;<br>- табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүматлы булу;<br>-предметларны үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары буенча аерып ала һәм төркемли белү;<br>- үзе, әти-әнисе турында сөйли белү (фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, адресын, телефон номерын әйтә алу), өлкәннәр хезмәте, аларның эшлекле сыйфатлары турында мәгълүматлы булу. | - күмәк сөйләмдә катнашу (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле, мәгънәле һәм аңлаешлы итеп сөйли);<br>- сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап, төгәл куллану;<br>- сүзләрне контексттагы мәгънәсенә туры китереп сөйли белү күнекмәләре булу;<br>-предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, иҗади хикәяләр төзи белү;<br>- тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белү. | - әсәрнең жанрын билгели алу (әкият, хикәя, шигырь);<br>- китап геройларының хәленә керә белү, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирү, үз мөнәсәбәтен белдерү;<br>- шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйләү, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә белү;<br>- иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен тану;<br>- китаплардан яңа белемнәр алу мөмкинлеген аңлау. |

## Балаларның белем дәрәҗәләре үсеше күрсәткече

| № | Баланың исеме, фамилиясе | Сүз байлыгы | | | Бәйләнешле сөйләм | | | Фольклор ( мәкаль, табышмак) | Нәтиҗә | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Ягымлы сүзләр куллану | Сүзләрне гомуми-ләштерү | Капма-каршы сүзләр | Үзең турында сөйләү | “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану | Аралаша белү (диалог) | | Баллар | Дәрәҗә |
| 1 | Дамир | | | | | | | | | |
| 2 | Алсу | | | | | | | | | |

| 3 | ... | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | |
|---|---|
| | **Нәтиҗәләрне бәяләү** |
| **Югары дәрәҗә**<br>17-21 балл | **Бала сөйләмдә актив, диалогта үзлектән сорау бирә, яхшы аралаша.** |
| **Уртача дәрәҗә**<br>12-16 балл | **Сүз байлыгы бар, тәрбияче ярдәмендә аралаша.** |
| **Уртачадан түбән дәрәҗә**<br>1-11 балл | **Аңлый, русча җавап бирә.** |

**Танып белү**

**Югары дәрәҗә ( 3 балл).** Бала сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында күзаллый. Экологик бәйләнешләрне аңлата ала, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысын белә. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүмат бирә ала. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйли, аларны төркемли белә. Үзе, әти-әнисе турында сөйли белә (фамилиясен, исемен, әтисенең исемен, адресын, телефон номерын әйтә ала), өлкәннәр хезмәте, аларның эшлекле сыйфатлары турында мәгълүматы бар.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында баланың күзаллавы җитәрлек дәрәҗәдә түгел. Экологик бәйләнешләрне күрүдә авырыксына, тәрбияче яки балалар ярдәмендә үзе җавап бирә. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүматы бар, дөрес итеп тәрбияче ярдәмендә аңлата. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйләгәндә хаталар җибәрә, төркемләгәндә хаталар җибәрсә, үзлектән төзәтә белә. Үзе (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, адресы, телефон номеры, әти-әнисе) турында мәгълүматы тулы түгел.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Сәламәт яшәү рәвеше, дөрес туклану турында бала күзалламый. Экологик бәйләнешләрне, кешенең табигать белән бәйләнеше, үзара йогынтысы турында әйтә белми. Табигатьнең төрле объектлары турында мәгълүматы бирә алмый. Предметларның үзләренә генә хас билгеләре, үзенчәлекле сыйфатлары турында сөйли, әмма аларны төркемләми. Үзе (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, адресы, телефон номеры, әти-әнисе) турында мәгълүматы аз.

**Аралашу**

**Югары дәрәҗә ( 3 балл).** Бала күмәк сөйләмдә катнаша (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле, мәгънәле һәм аңлаешлы итеп сөйли). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча аңлап, төгәл куллана ала. Сүзләрне контексттагы мәгънәсенә туры китереп сөйли белә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, үзлектән иҗади хикәяләр төзи белә. Тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белә. Бәйләнешле сөйләме чиста, грамматик яктан дөрес.

**Уртача дәрәҗә ( 2 балл).** Бала күмәк сөйләмдә катнаша (сорауларны аз бирә, сорауларга җавап кайтара, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле сөйләгәндә хаталар җибәрә, ләкин үзлектән төзәтә). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча кулланганда хаталар җибәрә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып иҗади хикәяләр төзегәндә, хаталар җибәрә, тәрбияче ярдәмендә үзлектән төзәтә ала. Тәрбияче һәм яшьтәшләре белән әдәпле итеп сөйләшә белә.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Бала күмәк сөйләмдә катнашмый (сораулар бирә, сорауларга тулы җавап кайтара алмый, вакыйгалар, фактлар, күренешләр турында эзлекле сөйләгәндә хаталар җибәрә, үзлектән төзәтә белми). Сөйләмдә төрле сүз төркемнәрен мәгънәсе буенча кулланганда хаталар җибәрә. Предметлар, картиналар, рәсемнәр буенча, үз тәҗрибәсеннән чыгып, үзлектән иҗади хикәяләр төземи.

**Матур әдәбият уку**

**Югары дәрәҗә ( 3 балл).** Әсәрнең жанрын билгели ала (әкият, хикәя, шигырь). Китап геройларының хәленә керә белә, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә, үз мөнәсәбәтен белдерә. Шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сәнгатьле итеп сөйли, эчтәлеге буенча сорауларга җавап бирә белә. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таный. Китаплардан яңа белемнәр алу мөмкинлеген аңлый.

**Уртача дәрәҗә (2 балл).** Әсәрнең жанрын билгеләүдә (әкият, хикәя, шигырь) хаталар җибәрә. Китап геройларының хәленә керә белә, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә, үз мөнәсәбәтен аңлата алмый. Шигырьләрне, сәхнәләштергән әсәрләрне сөйләгәндә сәнгатьлелек җитми. Эчтәлеге буенча сорауларга җавап биргәндә, хаталар җибәрә. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таныганда,хаталар җибәрә, күп очракта узлектән төзәтми. Китаплар белән кызыксына, мөстәкыйльлеге чамалы.

**Уртачадан түбән дәрәҗә (1 балл).** Бала әсәрнең жанрын (әкият, хикәя, шигырь) тәрбияче ярдәменнән башка билгели алмый. Китап геройларының хәленә керә белми, кылган гамәлләренә дөрес бәя бирә алмый, үз мөнәсәбәтен дөрес аңлата алмый. Шигырьләрне тиз истә калдырмый, сәхнәләштергән әсәрләрне сөйләгәндә, сәнгатьлелеге, иҗадилыгы юк. Эчтәлеге буенча сорауларга тәрбияче ярдәмендә җавап бирә яки бирә алмый. Иллюстрацияләр, рәсемнәргә карап, өйрәнгән матур әдәбият әсәрләрен таныганда, күп хаталар җибәрә. Китаплар белән кызыксынмый.

## II. Эчтәлекле бүлек

### Балага үсеш юнәлешләре буенча белем бирү (биш белем өлкәсендә)

1.**Социаль-коммуникатив үсеш**. Балаларның Татарстан Республикасы, анда яшәүче халыклар, аларның хезмәте һәм профессияләре, туган як табигате турында белемнәрен уен эшчәнлеге вакытында тирәнәйтү. Балаларда патриотизм хисләре; үзен туган шәһәре (авылы), республикасы, иленең гражданины итеп тану; шәһәр, республика, ил символикасына (флаг, герб, гимнга) хөрмәт белән карауны һәм горурлану хисе тәрбияләү. Иҗтимагый чыгышы, расасы, теле, дине, җенесе һәм яшенә карамыйча, янәшәдә яшәүчеләргә (балаларга, өлкәннәргә) уңай мөнәсәбәт, түземлек (толерантлык); башка кешеләрнең хисләре, фикерләре, теләкләренә, карашларына хөрмәт тәрбияләү, үзенең башкалар фикере белән риза булмавын дәлилли яисә үз позициясен яклый белергә өйрәтү. Башка ил, этнос халыклары белән позитив аралашуның, хезмәттәшлек итүнең мәгънәсен аңлату. Якындагы социумда үз урыны, теге яки бу төркемдәге кешеләргә нинди мөнәсәбәттә булуы (балалар бакчасындагы төркем яисә бию түгәрәге әгъзасы, спорт мәктәбе укучысы, булачак гимназист һ. б.) турында күзаллаулар формалаштыру. Гаилә тарихына (карт бабай, бабай, карт әби, әби) карата кызыксыну тәрбияләү. Гаиләң белән горурлану хисләре, гаилә әгъзаларының уңышларына сөенү, бүләкләрен игътибарсыз калдырмау күнекмәләре тәрбияләү. Идел буе халыкларының әдәби әсәрләре, нәфис һәм мультипликацион фильмнары, әйләнә-тирәдәге тормыш турындагы күзаллауларын сюжетлы-рольле һәм режиссёрлык уеннарында иҗади куллануларына булышлык итү. Балаларның сәхнәләштерү һәм кую өчен Идел буе халыкларының экиятләрен, шигырьләрен, җырларын, биюләрен мөстәкыйль сайлап алуларын хуплау; куелачак спектакльгә кирәкле атрибутлар һәм декорацияләр әзерләргә, үзара вазифаларны билгеләргә һәм рольләр бүлешергә булышу. Театральләшкән эшчәнлектә театрның төрле төрләрен (бибабо, бармак, курчак, рәсемнәр һ. б. театрлар) куллану. Сәхнә сәнгатенә карата кызыксыну үстерү. Коллективта сүзле уеннар уйнарга омтылышларын хуплау. Идел буе халыклары уеннарын уйнау тәҗрибәсен баету.

2.**Танып-белү үсеше.** Туган як тарихы, мәдәнияты, сынлы сәнгать, туган якның табигате белән таныштыру исәбенә балаларның күзаллауларын киңәйтү. Туган як табигате, климаты, кешеләренең тормышы белән таныштыруны дәвам итү. Үз шәһәренең (авылының) истәлекле урыннары, халык һөнәрләре, милли кухня, Татарстан Республикасы халыкларының тел культурасы белән таныштыру. Картада туган шәһәрен, республикасын, башкаланы, Татарстандагы эре шәһәрләрне (Әлмәт, Яр Чаллы, Түбән Кама, Бөгелмә, Яшел Үзән һ. б. ны) күрсәтә һәм атый белергә өйрәтү. Борынгы шәһәрләр (Биләр, Болгар), аларның тарихы,культурасы, көнкүреше белән таныштыру. Авыл һәм шәһәр кешеләренең көнкүрешен чагыштырырга өйрәтү. Татар һәм рус халкының яши торган өе, йорт кирәк-яраклары, өс киемнәре үзенчәлекләренә игътибар итү. Туган шәһәрендә бара торган позитив үзгәрешләрне (балалар бакчалары, спорт комплекслары, театрлар һ. б. төзелү) күрә белергә өйрәтү. Казанның эре промышленность һәм сәүдә үзәге булуы, татар халкының элек-электән игенчелек, терлекчелек, күн эшкәртү, сәүдә

белән шөгыльләнүе турында балаларга сөйләү. Туган шәһәренең, башка шәһәрләрнең символикасын өйрәнүне дәвам итү, үз халкының бер өлеше булуын аңлый белергә ярдәм итү. Милли һәм дөнья культураларының үткәненә һәм бүгенге сенә балаларны якынайту. Музыка һәм театр сәнгатенең күренекле шәхесләре, аларның тормыш һәм иҗат юллары белән таныштыру (композиторлар: С. Садыйкова, С. Сәйдәшев, Ф. Яруллин һ. б., җырчылар: Ф. Шаляпин, И. Шакиров, Р. Ибраһимов һ. б., театр режиссёрлары: М. Сәлимҗанов, К. Тинчурин һ. б., В. Качалов, Г. Камал исемендәге театр актёрлары һ. б.). Аларның тормышларына һәм эшчәнлекләренә кызыксыну уяту. Күренекле фән эшлеклеләренең тормышы һәм эшчәнлекләре белән таныштыру (Н. И. Лобачевский, К. Ф. Фукс, И. М. Симонов, Н. Н. Зинин, А. М. Бутлеров, А. Е. Арбузов һ. б.). Балаларның танып белүгә карата кызыксынуларын канәгатьләндерү, Казан (Идел буе) федераль университеты укытучылары һәм аны тәмамлаучылар турында мәгълүмат бирү. Милләтебез каһарманнарының Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклары турында сөйләү (М. Җәлил, Г. Гафиятуллин, М. П. Девятаев, П. М. Гаврилов, Н. Г. Столяров һ. б.). Әти-әниләрне балаларга әби һәм бабаларының сугышта алган бүләкләре турында сөйләргә җәлеп итү. Ватанны саклаучыларга карата хөрмәт хисләре тәрбияләү (һәйкәлләр, обелискларга чәчәкләр кую һ. б.). Табигатьне саклау буенча балаларның белемнәрен тирәнәйтү. Туган якның тере һәм тере булмаган табигатенә сакчыл караш тәрбияләү, табигатькә катнашуыңнан соң туган уңай һәм тискәре нәтиҗәләрне алдан күрә белергә өйрәтү, табигатьнең ресурсларына сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, аны рациональ файдалану күнекмәләре формалаштыру. Үсемлек һәм җиләкләрне җыю кагыйдәләре белән таныштыру. Дәүләт тыюлыклары, анда яшәүче тереклек ияләре, Татарстан Республикасының Кызыл китабына кертелгән үсемлек (флора) һәм хайваннар (фауна) төрләре белән таныштыруны дәвам итү. Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясында сирәк очрый торган төрләргә сакчыл караш кирәклеген балаларның аңнарына җиткерү. Татарстанның елга, күлләрендә яшәүче тереклек ияләре белән таныштыру. Кеше тормышында чишмә, елгаларның тоткан урыны, әһәмияте турында сөйләү. Республика сулыкларын чиста тотарга теләк уяту. Туган як табигатенең матурлыгына, андагы форма, ис, төс муллыгына игътибар итү. Табигатьтәге үзгәрешләрне күрә белергә өйрәтү.

3.**Сөйләм үсеше.** Балаларны матур әдәбият әсәрләре, халык әкиятләре, фольклоры белән таныштыру. Татар теленә карата тотрыклы кызыксыну үстерү. Мәгълүмати аралашу технологияләре, аудио- һәм видеоязмалар, уку-укыту методик комплектлары ярдәмендә предметны, аның билгесен, хәрәкәтен белдерүче сүзләрне актив кулланышка кертү, гади аралашу өчен кирәк булган сөйләм берәмлекләре байлыгы булдыру. Балаларның сүз байлыгын арттыру. Төзелеше ягыннан катлаулы булмаган хикәя һәм сорау җөмләләр төзү күнекмәләрен ныгыту. Үзе турында, бер кеше гамәлләрен сурәтләгән ситуатив картиналар сериясе буенча, сюжетлы рәсемнәр, үз күзәтүләреннән чыгып, зур булмаган (3–5 җөмләле) хикәяләр төзи белергә өйрәтү. Балаларның төрле эшчәнлек вакытында татар халык фольклор әсәрләрен, еш кулланыла торган сүзләр һәм әйтемнәрне файдалануга омтылышларын хуплау. Татар телендә сөйләүче әңгәмәдәшенең сөйләмен тыңлый

белүне формалаштыру, нәрсә турында сөйләгәнен аңларга тырышу, телне аз белүенә карамастан, аның белән әңгәмәгә кереп, аралашырга омтылышын хуплау. Балаларны татар телен киләчәктә (башлангыч мәктәптә) тагын да аңлабрак, төшенеп өйрәнергә әзерләү.

4.**Нәфис сәнгать үсеше.** Балаларны татар халкының сәнгате (музыка, бию, рәсем сәнгате, матур әдәбият әсәрләре), анда яшәүче атаклы кешеләр белән таныштырып, аларда әхлакый-патриотик хисләр тәрбияләү. Милләтебезнең дини йолалары, халык авыз иҗаты, сынлы сәнгате һәм архитектурасы, музыка сәнгате белән таныштыру балаларда Туган илне ярату хисе тәрбияләргә булыша. Милли орнамент элементлары белән таныштыруны дәвам итү. Балалар белән «яшәү агачы» образын карау. Балаларның игътибарын композициянең үзенчәлегенә (симметриясез), шул ук вакытта төрле төсләр файдаланылган чәчәк бәйләменә юнәлдерү. Төрле материаллар кулланырга, реаль һәм әкияти образларны (Идел буе халыклары әкиятләрендәге геройларны да кертеп) сурәтләүнең төрле ысулларын берләштерергә мөмкинлекләр бирү. Республика тормышында булган истәлекле вакыйгаларны рәсемнәрдә чагылдыра белүләрен хуплау. Балаларның эшләрен бергәләп карау, нәрсә ясаганнары турында сөйли белергә өйрәтү. Балаларга эшләренең тематикасын киңәйтүгә булышлык итү. Актүбә һәм Шәмәрдән уенчыкларын натурадан карап әвәли һәм аларның характерлы үзенчәлекләрен бирә белергә өйрәтү. Ике-өч фигурадан торган скульптура төркемнәрен катлаулы булмаган сюжетларга («Сабантуйда», «Чәй эчкәндә», «Ат чабышлары» һ. б.га) берләштерү. Идел буе халыкларының әдәби әсәрләре геройларын күзаллау юлы белән әвәли белү күнекмәләрен формалаштыру. Туган шәһәре (авылы) тормышындагы вакыйгаларны чагылдыручы сюжетларны мөстәкыйль сайлый белүләрен активлаштыру. Башка белем бирү өлкәләренең эчтәлеге белән ярак-лаштырып, балалар эшләренең тематикасын киңәйтү. Балаларны Г. Тукай әсәрләре һәм аның иҗатын чагылдыручы сәнгать төрләре (Ф. Яруллинның «Шүрәле», Ә. Бәшировның «Су анасы» балетлары, Н. Җиһановның «Кырлай» симфониясе, Б. Урманче, И. Казаков, Б. Әлменов, Ф. Әминов һ. б. ның сынлы һәм рәсем сәнгатьләре әсәрләре) белән таныштыруны дәвам итү. Сәнгатькә карата уңай караш формалаштыру. «Казан» милли-мәдәни үзәгенең милли-мәдәният музеенда булу, анда борынгыдан сакланып калган өй кирәк-яраклары: көмеш поднослар, савыт-саба, бизәк төшерелгән бакыр кувшиннар, комганнар, йорт хайваннары фигуралары формасындагы бронза йозаклар; җәмәгать биналарының интерьерларын һәм экстерьерларын бизәүче декоратив композицияләр белән таныштыру. Борынгы бизәнү әйберләрен: йөзекләр, алкалар, beləзекләр, чулпылар, яка чылбырлары, хәситәләр һ. б.ны карау. Хәзерге заман рәссам-ювелирларның (И. Фазылҗанов, С. В. Ковалевская, В. О. Ковалевский һ. б.ның) иҗатлары белән таныштыру. Балаларның игътибарын бизәнү әйберләренең милли үзенчәлекләренә юнәлдерү. Татар халкының үзенчәлекле сәнгати һөнәре булган укабелән чигү турында сөйләү. Чигелгән түбәтәйләр, хатынкызның бәрхет аяк киеме, күкрәкчәләр, калфаклар һ. б.ны карау. Бигрәк тә популяр булган композицияләргә – «алтын каурый», чәчәк бәйләме, кошлар, бодай башагы, йолдызлар һәм ярымай мотивларына һ. б.га игътибар итү. Туган шәһәр (авыл)

архитектурасы – мәчет һәм храм архитектуралары (Кол Шәриф мәчете, Раифадагы Богородицкий ир-атлар монастыре) белән таныштыру эшен дәвам итү. Балаларны татар халкының музыка культурасына якынайту. Татар композиторларының музыкаль әсәрләрен тыңлау. Татарстан Республикасы, Россия Федерациясенең Дәүләт гимннары белән таныштыру. Горурлык хисләре тәрбияләү.

5.**Физик үсеш.** Татар халык хәрәкәтле уеннарын, физминуткалар кулланып балаларның хәрәкәт активлыгын үстерү, татар халык бәйрәмнәре, халык уеннары аша балаларның физик үсешен камилләштерү. Чәй янына бирелә торган милли камыр ризыклары: гөбәдия (дөге, йөзем һәм йомырка белән), кабартма, бавырсак, талкыш-кәләвә, чәкчәк, кош теле белән таныштыру. Балаларга республикадан читтә дә танылган дәвалану-ял итү урыннары һәм санаторийлар («Васильево», «Сосновый бор» («Нарат урманы»), «Крутушка», «Бакирово», «Санта» һ. б.) белән танышу мөмкинлеге бирү. Хәрәкәтле халык уеннарын үзгәртеп төрләндерү күнекмәләре бирү. Милли уен-ярышларда («Таяк тартыш», «Аркан тартыш», «Капчык белән сугыш» һ. б.да) катнашасы килү теләге уяту. Кеше тормышында спортның әһәмияте турында күзаллау формалаштыру. Милли спорт төре – көрәш белән таныштыру. Спорт өлкәсендәге билгеле уңыш-казанышлар белән таныштыру. Идел буе халыкларының төрле эчтәлекле уеннарын мөстәкыйль эшчәнлек вакытларында файдалана белү күнекмәләрен ныгыту. Хәрәкәтле уеннарда балаларда көч, җитезлек, кыюлык, тәвәккәллек, түземлек кебек сыйфатлар тәрбияләү. Уен нәтиҗәсен гадел бәяли белүләрен хуплау. Халык уеннары белән кызыксынуларын үстерү.

## Программаны тормышка ашыруда төрле технологияләр, формалар, алымнар, методлар һәм чаралар

**Татар һәм ана телен өйрәтүдә кулланыла торган чаралар:**

1.Эшчәнлек эшкәртмәләре, диагностик материаллар.

2.Тавышлы күрсәтмәлелек (һәр проект өчен аудиоязмалар, анимацион сюжетлар, мультфильмнар).

3.Картиналы һәм картиналы-дидактик күрсәтмәлелек (таратма һәм күрсәтмә рәсемнәр, җырлы-биюле уеннар, театр эшчәнлеге өчен материаллар.

4.Символик, график күрсәтмәлелек (пиктограммалар).

5.Күләмле күрсәтмәлелек (макетлар, муляжлар, уенчыклар)

6.Интерактив уеннар.

7.Эш дәфтәрләре.

**Эш төрләре һәм формалары:** Программа бурычларын үтәүдә эш формаларының, практик гамәли алымнарның, чараларның әһәмияте зур. Төп эш төрләре булып түбәндәгеләр тора:

1.Предметлар белән эш: тасвирлау, уенчык белән диалог төзү, уен һәм әкиятләрдә катнашу.
2.Рәсемнәр белән эш: тасвирлау, үстерешле диалог.
3.Сюжетлы-рольле уеннар;
4.Әйлән-бәйлән, җырлы-биюле уеннар өйрәнү (аудиоязмага таянып).
5.Театральләштерү, сәхнәләштерү (бармак театры, битлекләр, костюмнар, театр күрсәтү (әти-әниләргә, башка төркем балаларына).
6.Хәрәкәтле уеннар: туп белән уеннар, "Командир" уены, әйлән-бәйлән уен, зарядка уеннары.
7.Иҗади һәм ситуатив уеннар: рольле уеннар, интервью, ситуатив күнегүләр.
8.Ситуатив, логик күнегүләрне ишетеп, аңлап эшләү.
9.Үстерелешле диалоглар (зурлар һәм яшьтәшләре белән үзара аралашу).
10.Аудиоязмалар тыңлау, кушылып әйтү, җырлау, кабатлау, ишеткән сүзне рәсемдә табып күрсәтү.
11.Анимацион сюжетлар, мультфильмнар карау.
12.Интерактив уеннар.

**Аудиоязмалар:** Аудиоязмалар яңа сүз өйрәтү, сөйләм үрнәкләре үзләштерү, уеннар, кыска җырлар өйрәтү, өстәл театры күрсәтү вакытларында куллану өчен кулай. Аларны һәр эшчәнлектә куллану мөһим түгел.

**Яңа сүзләр өйрәтү технологиясе:** Балаларны татар телендә сөйләшергә һәм аралашырга өйрәтү билгеле бер күләмдәге сүз байлыгы булдырудан башлана. Яңа сүзләр үзләштерү процессында махсус сайлап алынган күнегүләр төп чара булып тора. Юнәлеше һәм характеры ягыннан лексик күнегүләрне икегә бүлеп карыйлар: әзерлек күнегүләре һәм сөйләм күнегүләре. ***Әзерлек күнегүләре*** балаларны яңа сүзләрне файдаланып сөйләргә әзерли. Бу күнегүләр лексик берәмлекләрне хәтердә калдырырга ярдәм итәләр. ***Сөйләм күнегүләре*** лексик күнегүләрнең бер төре буларак, үзләштерелгән лексик берәмлекләр җирлегендә ситуацияләргә бәйле сөйләм эшчәнлеген барлыкка китерәләр. Яңа сүз өйрәтү төп методик алымнарның берсе булып тора:
-яңа сүз тәрбияче тарафыннан ачык, төгәл итеп күрсәтмә рәсем ярдәмендә әйтелә;-аудиоязмадан тыңлатыла, кабатлатыла;
-ишеткән сүзне бала рәсемннән табып күрсәтә һәм әйтә;
-сүзләр тизрәк истә калсын өчен сүз кат-кат әйттерелә, аңлашылмаган очракта, аның русча тәрҗемәсе бирелә;
-төрле эш формаларында (пышылдап, күмәкләп, төркемнәргә бүленеп, хәрәкәтләнеп әйтеп) өйрәтелә;
-уеннар кулланып ("Ватык телефон", "Кайтаваз"...) ныгытыла;
-яңа сүз, таныш булган сүзләр белән грамматик конструкцияләрдә ныгытыла, мәсәлән: зур туп, чиста туп;
-аралашуда кулланыла (бала өйрәнгән яңа сүзләрне, конструкцияләрне бары аралашуда аңлап куллана);

-бала теге яки бу сүзне анық төгәл мәгънәсен аңлап үзләштереп калсын өчен телдән инкарь итү яисә раслау күнегүләре үткәрергә мөмкин;
-өйрәнелгән сүзләрне хәтердә калдыру максатыннан төрле уеннар оештырырга була: “Исемен әйтсәң бирәм”, “Мин күрсәтәм, син әйт”, “Сорап ал”, “Серле кәрзин” һ.б.

Баланың сөйләмен оештыру өчен исемнең алмашлык (мин, син, бу), сан (1 дән 10 га), сыйфат (тәм, күләм, төс, эчке сыйфатлар) һәм фигыль белән бәйләү грамматик конструкцияләре кулланыла. Фигыль белән таныштыру боерык фигыльләрдән башлана (бар, сикер, аша һ.б.). Уртанчылар төркемендә балаларга боерык фигыльләрне аңлап үтәүләрен тәлап итеlә. Зурлар төркемендә балалар кайбер боерыкларны үзләре бирә (сикер, аша, уйна) һәм аңлап үтиләр. Мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә балалар үзлектән Нишли? Син нишлисең? сорауларын бирәләр һәм аңлап җавап кайтаралар.

**Диалогик сөйләм:** Программаның төп асылы булып аралашуга чыгу тора. Аралашуга чыгу өчен диалогик сөйләмнең әһәмияте бик зур. Диалогик сөйләмгә өйрәткәндә гадидән катлаулыга дигән дидактик принципка таянып эшләү кулай. Диалогик сөйләмдә иң отышлы алым – сорау-җавап рәвешендә (сорау-информация алу берәмлеге) һәм теләк белдерә торган: теләк, үтенү, тәкъдим итү, ризасызлык төсмере булырга мөмкин. Еш кына сораудан соң, әңгәмәдәшнең җавап репликасы килә, раслау яисә инкарь рәвешендә булырга мөмкин.Реплика-җавап сорау рәвешендә дә булырга мөмкин: *Нинди эти?* Бу вакытта әңгәмәдәшнең җавабы тулы да, ким дә булырга мөмкин: *Матур эти;* яисә: *Матур.*

Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга ситуатив - тематик принцип нигезендә, диалогик сөйләмне үстерү буенча түбәндәге типтагы күнегүләр тәкъдим итәргә мөмкин:
- уен ситуацияләрендә катнашу;
- тәкъдим ителгән үрнәк буенча кечкенә диалоглар төзү;
- тематик диалоглар төзү;
- сәхнәләштерүдә катнашу;
- рольләргә бүлеп сөйләү.

Диалоглар белән эшләү коммуникатив юнәлештә алып барылырга тиеш. Тәрбияче аларның балалар сөйләменә кирәкле формаларын эшләргә һәм төрле шартларда куллану мөмкинлеген исәпкә алырга тиеш. Тәрбияче, сөйләмгә эмоциональ бизәлеш өстәү өчен, төрле формаларны кулланырга; эш эчтәлегенә туры килә торган интонация, ишарәләр, мимикалардан файдаланырга һ.б. өйрәтергә тиеш. Шул ук вакытта, диалогны сорау бирү һәм аңа җавап алу дип кенә уйларга ярамый. Балаларны диалогик сөйләмгә хас булган башка (сорау һәм җаваплардан тыш) ситуацияләр, репликалар, көндәлек аралашу формаларына да өйрәтергә кирәк.

Аралашуга чыгу өчен нәтиҗәле чаралар булып аудиоязмалар, эш дәфтәрләре, анимацион сюжетлар тора.

**Эш дәфтәрләре:** Эш дәфтәрләре эшчәнлектә өйрәнелгән материалны ныгытуны күздә тотып төзелгән. Дәфтәрләр белән эшләгәндә балалар кабатлыйлар, бер-берсенә сораулар бирәләр, тәрбияче белән аралашалар. Балалар үзләренең эш дәфтәрләрен өйгә алып кайтып өйрәнелгән материалны кабатлый алалар. Бу дәфтәрләр белән әти-әниләр дә, төркем тәрбиячеләре дә эшли ала, чөнки биремнәр рус телендә язылган. Дәфтәрдәге эшнең нәтиҗәсе уртанчылар төркемендә сүзне ишетеп, аңлап, предметларны табып, парлаштырып, чагыштырып, аларның сыйфатын, санын билгеләүгә китерсә, зурлар төркемендә балаларны үзара аралашуга этәрә һәм бу мәктәпкә әзерлек төркемнәрендә дәвам итә. Иң катлаулы биремнәр мәктәпкә әзерлек төркеме өчен төзелгән. Бу төркемдә хәрәкәтне белдерүче сүзләр, яки фигыльләр күп кулланыла. Балаларны ситуацияләргә куеп, сораулар биреп диалогка этәрәбез. Берүк вакытта, фигыльләр боерык формада (утыр, уйна һ.б.), 2-нче зат алмашлыгына тәңгәл формада (яки утыра, укый, шуа, ашый һ.б.), һәм дә инде үзе турында 1-нче зат алмашлыгын кулланып өйрәтелә (уйныйм, утырам, барам, эчәм һ.б.). Балалар бер-берсенә, өлкәннәргә сораулар бирергә өйрәнәләр: бу нәрсә, нишли, син нишлисең, нәрсә кирәк, нинди һ.б. Җөмләләр төзү баланың уйлавын таләп итә, чөнки алар 3-4 сүздән торалар. Мәсәлән: Аю караватта йоклый. Куян чана шуа. Песи бит юа һ.б.. Мәктәпкә әзерлек төркемендә өченче бирем җыр формасында бирелә.Бу биремнәрне интерактив такта һәм экраннарда эшләп була.

**Анимацион сюжетлар:**

Анимацион сюжетлар балаларның белгән сүз байлыгына, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелгән. Сюжетны караганнан соң, балалар белән әңгәмәләр үткәрелә, алда өйрәнелгән уен ситуацияләрен кабатларга тәкъдим ителә.

**Төрле эшчәнлекләрдә белем бирү формалары**

**1. Хәрәкәт:** -уен; -хәрәкәт элементларын кулланып әңгәмә үткүрү; -физминуткалар.

**2. Уен:** -күзәтү;-уку; -уен;-әңгәмә; -күмәк уен (тәрбияче; балалар белән); -сюжетлы-рольле уен; -кагыйдәле уен; -экскурсия.

**3. Хезмәт:** -күмәк эшчәнлек;-әңгәмә;-карау;-уен;-дежур тору.

**4. Танып- белү:** -күзәтү;-сюжетлы-рольле уен; -хикәя;-үстерүле уен; -әңгәмә; -ситуатив сөйләшү; -уку.

**5. Аралашу:** -уку;-хикәя; -әңгәмә;-өстәл театры;-балалар белән аралашу;-шигырь ятлау; -уен (дидактик, театральләштерелгән, режиссер);-табышмакларга җавап табу; -текстлы хәрәкәтле уен;-тәрбияче белән аралашу.

**6. Матур әдәбият, фольклорны кабул итү:**-уку;-әңгәмә;-хикәя;-уен; -викторина;-инсценирование

**7. Рәсем:** -карау; -уен;-бизәү;-күргәзмәләр;-ясау.

**8. Музыка:** -музыка тыңлау; -җырлы-биюле уен; -җырлау.

**9. Төзү:** -уен; -күзәтү; -карау.

## “Минем өем” проекты буенча тематик план (уртанчылар төркеме)

| Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|
| **1. Гаилә** | Танышу, минем гаиләм. | 1 |
| | Малай,кыз. | 1 |
| | Минем туганнарым. | 1 |
| | Әйдәгез танышыйк. | 2 |
| | Тату гаилә. | 1 |
| | Минем дусларым. | 2 |
| | Әйе-юк. | 1 |
| | Кунак килгән. | 1 |
| | Әйдәгез уйныйбыз. | 1 |
| | Безнең кунаклар. | 1 |
| **2. Ашамлыклар** | Әби күчтәнәче. | 1 |
| | Бабай күчтәнәче. | 1 |
| | Сөт, чәй. | 1 |
| | Дустыңны сыйла. | 1 |
| | Рәхмәт әйт. | 1 |
| | Песине сыйла. | 1 |
| | Кунак сыйлау. | 1 |
| | Кунакны ашат. | 1 |
| | Чәй табынында. | 1 |
| **3. Уенчыклар** | Уенчыклар. | 1 |
| | Зур-кечкенә. | 1 |
| | Күңел ачу кичәсе “Туган көн” | 1 |
| | Курчак кунакка килгән. | 1 |
| | Уенчыклар кибете. | 1 |
| | Яңа уенчыклар. | 1 |
| | Без уйныйбыз. | 1 |
| | Алиянең дуслары кунакка килгән. | 1 |
| | Безнең уенчыклар. | 1 |
| | Бездә бәйрәм. | 1 |
| | Чыршы бәйрәме. | 1 |
| | Уйныйбыз. | 1 |
| | Без уйнарга яратабыз. | 1 |
| | Мияуга бүләк. | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| | Уенчыклар кибете.<br>Бүләкләр.<br>Әйдә уйныйк.<br>Уйна.<br>Күңелле уеннар.<br>Уенчыклар юабыз.<br>Ю.<br>Дуслар кунакка килгән. Уйнарга чакыр.<br>Оляның уенчыклары пычранган. Оляга ярдәм ит. | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| **4. Саннар** | Саннар.<br>Уйныйбыз да, саныйбыз да.<br>Уенчыклар.<br>Ничә уенчык?<br>Уйный-уйный саныйбыз. | 2<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| **5. Кабатлау** | Бергәләп уйныйбыз.<br>Кунак чакырабыз.<br>Күңелле ял итәбез.<br>Без татарча сөйләшәбез.<br>Бу өйдә кем яши?<br>Уенчыклар илендә.<br>Ягымлы сүзләр.<br>Боерыкны аңлау.<br>Без театр уйныйбыз.<br>Кызыклы уеннар.<br>Минем дуслар.<br>Бездә Сабантуй.<br>Хуш киләсең,Сабантуй. | 2<br>1<br>1<br>2<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | | **65 сәгать** |

**“Минем өем” проекты буенча тематик план ( уртанчылар төркеме)**

| № | Тема | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1. | Гаилә | 12 сәгать (1-12) |
| 2. | Ашамлыклар | 9 сәгать (13-21) |
| 3. | Уенчыклар | 23 сәгать (22-44) |
| 4. | Саннар | 6 сәгать (45-50) |
| 5. | Кабатлау | 15 сәгать (51-65) |

## “Минем өем” проекты буенча календарь план
## ( уртанчылар төркеме)  Сентябрь ае.

<table>
<tr><th>Үткәрү вакыты</th><th>Тема Сүзлек</th><th>ЭШ ТӨРЛӘРЕ</th><th>Индивидуаль эш</th><th>Җиһазлау</th></tr>
| **Декабрь**<br>**III атна**<br>**3.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Безнең уенчыклар.**<br>Сүзлек: кабатлау | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | |
| | | **Дидактик уен «Безнең уенчыклар».**<br>**Дидактик уен «Нәрсә юк?»**<br>**Дидактик уен «Мин нинди уенчык турында уйладым?»**<br>**Сүзле уен «Бу уенчык нинди?»**<br>**Сюжетлы-рольле уен «Уенчыклар кибете».**<br>**Өстәл уены «Парын тап».** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Уенчыклар, уеннар. Интерактив такта. |
| | | **«Әкият илендә» тапшыруын язмада карау.**<br>**Дәфтәрдәге биремнәр буенча ИКТ-уен яки предметлы, сюжетлы рәсемнәр белән уен.**<br>**Өстәл уены «Парын тап».**<br>**Уен ситуациясе «Уенчыклар кунакка килгән».** | | |
| **Декабрь**<br>**IV атна**<br>**4.1**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Бездә бәйрәм.**<br>Сүзлек: кабатлау | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | |
| | | **Уен ситуациясе «Уенчык бүләк ит».**<br>**Сүзле уен «Мин башлыйм — син дәвам ит!»** *(Аю — зур, куян...)*<br>**Өстәл уены «Бу кем? Бу нәрсә?»** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Уенчыклар. К.В. Закирова «На поляне детства» (24–25 с.). |
| | | **Уку А.Алиш «Глупый зайчонок».**<br>**Бәйрәмгә әзерлек.** *(Шигырьләр, җырлар өйрәнү.)* | | |
| **Декабрь**<br>**IVатна**<br>**4.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Чыршы бәйрәме.**<br>Сүзлек: кабатлау | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Уенчыклар, уеннар. Интерактив такта. |
| | | **Бәйрәм турында әңгәмә.**<br>**Өстәл уены «Уенчыклар бәйрәмгә килгән».**<br>**Дәфтәрдәге биремнәр буенча ИКТ-уен.**<br>**Лего уены «Парын тап».** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Уенчыклар, уен-нар. Интерактив |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Курчак театры «Чыршы бәйрәме».**<br>**Театральләштерелгән уен ситуациясе «Кыш бабай килгән безгә».**<br>**Р.Валеева «Новый год».***(Русча шигырь уку,эчтәлеге буенча әңгәмә.)* | | такта. К.В. Закирова «На поляне детства»(27 с.). |

## Гыйнвар ае

| Үткәрү вакыты | Тема Сүзлек | ЭШ ТӨРЛӘРЕ | Индивидуаль эш | Җиһазлау |
|---|---|---|---|---|
| **Гыйнвар**<br>**3 атна**<br>**3.1**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Уйныйбыз**<br>Сүзлек:<br>Матур,<br>аю,<br>курчак,<br>туп,<br>зур,<br>кечкенә,<br>бир,<br>куян | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Уенчыклар: эт, песи, курчак, туп, машина,аю, куян. “Кибет” уены өчен атрибутлар. Аудиоязма 47 |
| | | **Дидактик уен** “Нәрсә юк?”<br>**Сүзле уен** “Бу уенчык нинди?”<br>Тәрбияче аюны күрсәтеп сорый: - Аю нинди?<br>- Аю зур (кечкенә, матур, әйбәт).<br>Таныш уенчыкларны кулланып, уен дәвам итә.<br>**Сюжетлы- рольле уен** “Уенчыклар кибете”.<br>**1нче вариант.** Бала: Аю бир.<br>Тәрбияче: Нинди аю?<br>Бала: Зур аю.<br>Тәрбияче: Мә зур аю.<br>Бала: Рәхмәт!<br>**2нче вариант:**Бала: Курчак бир.<br>Тәрбияче: Нинди курчак?<br>- Матур курчак.<br>- Мә матур курчак.<br>- Рәхмәт!<br>**Җырлы- биюле уен “Карусель”.** Аудио (47нче кисәк) “Слушай!”- “Тыңла!” Әллә-лә,әллә-лә, карусель әйләнә,<br>Матур курчак әйләнә,<br>Зур-зур аю әйләнә,<br>Кечкенә куян әйләнә.( ике тапкыр җырланыла)<br>**Темага кагылышлы уенчыклар уртага куела, балалар җырны тыңлап әйләнәләр.** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Р.К.Шаехова “Раз- словечко, два –словечко...” (8 с.) Театр |
| | | **Шәүлә театры** “Мин курчак”. Аудио ( 46нчы кисәк)<br>**Мультфильм карау** А.Алиш “Куян кызы”- “Зайчонок” | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Шигырь уку** “Как девочка учила куклу говорить” *( **курчак** сүзен ныгыту).* **Хәрәкәтле уен** “Уенчыкны ал”. (Бүлмәнең төрле урыннарына бала саны буенча уенчыклар куела. Тәрбияче сигналы буенча балалар таралышып йөгерәләр.Балалар, сигнал буенча йөгереп килеп, үзләренә берәр уенчык алырга һәм аны атарга тиеш. ) | | атрибутлары, предметлы рәсемнәр, уенчыклар. |
| **Гыйнвар**<br>**3 атна**<br>**3.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Без уйнарга яратабыз**<br>Сүзлек:<br>Матур,<br>аю,<br>курчак,<br>туп,<br>зур,<br>кечкенә,<br>бир,<br>куян | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Төрле зурлыктагы уенчыклар; аю, песи, эт, курчак, туп, куян.<br>Аудиоязма 47 |
| | | **Сүзле уен** “Уйлап әйт!”. (Бала борылып баса.Тәрбияче балаларга уенчык күрсәтә. Борылып баскан бала уенчыкның исемениәйтергә тиеш.) Бала: Курчак?<br>Балалар: Юк.<br>Бала: Куян?<br>Балалар: Әйе.<br>**Дидактик уен “Дөрес әйт!”**<br>Тәрбияче , уенчыкны күрсәтеп, балалардан сорый: - Туп?<br>Балалар: Әйе, туп.<br>Тәрбияче: Куян?<br>Балалар: Юк.<br>Тәрбияче: Курчак?<br>Балалар: Әйе, курчак.<br>**Дидактик уен “ Нәрсә зур, нәрсә кечкенә?”** ( Зур, кечкенә уенчыклар кулланыла, зурлыгын билгелиләр)<br>**Җырлы- биюле уен “Карусель”.** Аудио (47нче кисәк) “Слушай!”- “Тыңла!”<br>Әллә-лә,әллә-лә, карусель әйләнә,<br>Матур курчак әйләнә,<br>Зур-зур аю әйләнә,<br>Кечкенә куян әйләнә.( ике тапкыр җырланыла)<br>**Темага кагылышлы уенчыклар уртага куела, балалар җырны тыңлап әйләнәләр.** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | К.В.Закирова “ Балачак- уйнап-көлеп үсәр чак” (106 бит) |
| | | **Бияләй театры “Уенчыклар кибетендә”.**<br>**Әкият сәхнәләштерү А.Алиш “Куян кызы”. (**Балаларны әкиятне сәхнәләштерергә әзерләү)<br>**Шигырь уку “Туп”** ( ***туп** сүзен ныгыту)*<br>**Татар халык уены “Капкалы”.** | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Гыйнвар 4 атна 4.1** (режим вакыты) | **Тема: Мияуга бүләк.**<br><br>Сүзлек: Матур, аю, курчак, туп, зур, кечкенә, бир, куян | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br>**Аудиоязманы тыңлау һәм кабатлау.** ( Һәр балада төрле зурлыктагы уенчык рәсемнәре. Бала аудиоязмадан ишеткәнсүзне аңлап, рәсемен күрсәтә, исемен әйтә.) Аудио (48нче кисәк) “Слушай-покажи-повтори!”, “Тыңла-күрсәт-кабатла!”<br>- Зур курчак (озын пауза).<br>- Кечкенә курчак (озын пауза)...<br>**Уен ситуациясе “Мияуны чакыр”.**<br>Балалар Миуяны чакыралар.<br>Бергә: Мияу, кил монда. Исәнме, Мияу!<br>Мияу: Исәнмесез, балалар!<br>Бергә: Хәлләр ничек?<br>Мияу: Әйбәт, рәхмәт!<br>Бергә: Утыр, Мияу!<br>Мияу: Рәхмәт!<br>**Үстерешле диалог “Мияуга уенчык бүләк ит!”**<br>Һәр бала уенчык рәсемнәрен бүләк итә: курчак, куян, аю, туп, зур аю, кечкенә песи, зур эт. | | Уенчыклар: аю, курчак, туп, машина, куян, зур аю, кечкенә туп, чиста машина. Аудиоязма 48. Уенчык рәсемнәре: Мияу, Акбай. |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br>**Курчак театры “Акбайга уенчык бүләк ит!”**<br>**Аз хәрәкәтле уен “Рәсемдә нәрсә сурәтләнгән?”**<br>**(**Уенчык, ашамлык исемнәрен ныгыту.) **Шигырь- табышмак уку:**<br>Зверь пушистый, очень ловкий,<br>Любит сладкую морковку,<br>Ест капусты он кочан,<br>Кто же это? Бу - … (куян) | | К.В.Закирова “ Балачак- уйнап-көлеп үсәр чак” (88 бит) |
| **Гыйнвар 4 атна 4.2** (режим вакыты) | **Тема: Уенчыклар кибете.**<br><br>Сүзлек: Хәлләр ничек? | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br>**Сюжетлы-рольле уен “Уенчыклар кибете.”** ( Төрле зурлыктагы уенчыклар, Мияу сатучы ролендә. Аудио 49нчы кисәк)<br>Акбай: Исәнме , Мияу!<br>Мияу: Исәнме, Акбай!<br>Акбай: Хәлләр ничек?<br>Мияу: Әйбәт, рәхмәт.<br>Акбай: Аю бир. | | Уенчык Акбай, Мияу. “Кибет” сюжетлы-рольле уены өчен атрибутлар. Төрле зурлык-тагы уенчыклар. Эш дәфтәре. Аудиоязма 49 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Мияу: Нинди Мияу?<br>Акбай: Зур аю.<br>Мияу: Мә, зур аю.<br>Акбай: Рәхмәт.<br>Мияу: Сау бул, Акбай!<br>Акбай: Сау бул, Мияу!<br>*Шул үрнәктә балалар Мияудан уенчыклар “сатып”алалар.*<br>**Дәфтәрдә эш. 12нче бирем. “Подари Алсу игрушку”** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Анимацион сюжит (42 тема) К.В.Закирова “ Балачак- уйнап-көлеп үсәр чак” (88,333 бит) |
| | | **Фланелеграфта театр “Алсуга уенчыклар бүләк итү”.**<br>**Анимацион сюжит карау “Уенчыклар упкәләгән”.**<br>**Аз хәрәкәтле уен “Нәрсә яшерелде?”**(Уенчык, исемнәрен ныгыту.)<br>**Хәрәкәтле уен “Төлке һәм куяннар”.** | | |

## Февраль ае.

| Үткәрү вакыты | Тема Сүзлек | ЭШ ТӨРЛӘРЕ | Индиви-дуаль эш | Җиһазлау |
|---|---|---|---|---|
| **Февраль I атна 1.1** (режим вакыты) | **Тема: Бүләкләр** Сүзлек: уйна | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Уенчыклар: курчак, аю,туп, куян, зур аю машина, кечкенә туп, чиста машина. Аудиоязма 48. Уенчык рәсемнәре. Уенчык Мияу, Акбай. |
| | | **Дидактик уен “Исемен дөрес әйт- уйна”** (Тәрбияче төрле зурлык-тагы уенчыклар салынган машина тартып керә.) Аудио 50нче кисәк.<br>Тәрбияче: Какие красивые игрушки. Поиграем в интересную игру “Назови правильно- играй”, “уйна”. Бу нәрсә?<br>Акбай: Курчак.<br>Тәрбияче: Мә курчак, уйна!<br>Акбай: Рәхмәт!<br>**Уен ситуациясе “Иптәшеңә уенчык бир!”** (Балалар уенчыклары белән алмашалар.)<br>- Оля, мә курчак, уйна!<br>- - Рәхмәт!<br>**Сүзле уен** “Иптәшеңне уйнарга чакыр”.<br>Тәрбияче: Позови друга поиграть.<br>Мияу: Оля, кил монда, уйна.<br>Оля: Коля, кил монда, уйна. | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Анимацион сюжет (42 тема). |

<table>
<tr><td></td><td></td><td>Анимацион сюжет карау “Уенчыклар упкәләгән”. (эчтәлеге буенча әңгәмә)<br>Өстәл театры “Алсуның туган көне”.<br>Хәрәкәтле уен “Кечкенә туплар”.<br>Уку Р.Батулла “Подарок”әкияте.</td><td></td><td>К.В. Закирова “Балачак аланы”(334 б.)<br>К.В. Закирова “На поляне детсва”(34 б)</td></tr>
<tr><td rowspan="4">Февраль<br>I атна<br>1.2<br>(режим вакыты)</td><td rowspan="4">Тема:<br>Әйдә уйныйк<br>Сүзлек:<br>уйна</td><td>Режим вакытында уен эшчәнлеге<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)</td><td rowspan="4"></td><td rowspan="2">Төрле зурлыктагы уенчыклар. К.В. Закирова “Балачак аланы”(334 б.)</td></tr>
<tr><td>Уен ситуациясе “Иптәшеңә уенчык бир!”<br>Сүзле уен “Әйдә бергә уйныйк”. (балалар парлашып уйныйлар)<br>Тәрбияче: Позови друга поиграть.<br>Оля: Алия, кил монда. Мә туп, уйна.<br>Алия: Рәхмәт! Туп матур, зур. Мә курчак, уйна.<br>Оля: Рәхмәт! Курчак матур.<br>Хәрәкәтле уен “Кечкенә туплар”.</td></tr>
<tr><td>Өстәмә материал<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)</td><td rowspan="2">Анимацион сюжет (42 тема) . К.В. Закирова “Балачак аланы” (129,343 б.)</td></tr>
<tr><td>Анимацион сюжет сәхнәләштерү “Уенчыклар упкәләгән”.<br>Уку Б.Рәхмәт “Уенчыклар”.<br>Рәсемле театр “Алсу белән уйныйбыз”.<br>Хәрәкәтләр белән шигырь уку “Матур тубым” (балалар хәрәкәтләрне кабатлыйлар)</td></tr>
<tr><td>Февраль<br>II атна</td><td>Тема:<br>Уйна</td><td>Режим вакытында уен эшчәнлеге<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)</td><td></td><td>Төрле зурлыктагы</td></tr>
</table>

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **2.1**<br>(режим вакыты) | Сүзлек:<br>бир | **Уен ситуациясе “Сорап ал һәм уйна”** (Акбай һәм Мияуда төрле зурлыктагы уенчыклар. Балалар уенчыкларны сорап алалар.)<br>Оля: Акбай, куян бир.<br>Акбай: Нинди куян?<br>Оля: Кечкенә (зур) куян.<br>Акбай: Мә кечкенә (зур) куян, уйна.<br>Оля: Рәхмәт! ( Шул үрнәктә барлык балалар да катнаша).<br>**Дидактик уен “Мин кушканны үтә, әйт”.**<br>Балалар уенчыклары белән тәрбияче кушканны үтиләр, кабатлыйлар.<br>- Аю, кил монда , утыр.<br>- Куян, кил монда, аша.<br>- Курчак, кил монда, эч.<br>- Аю, кил монда, уйна.<br>Шул рәвешле барлык уенчыклар белән дә бирем үтәлә. | | уенчыклар. Уенчык Мияу, Акбай. |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Анимацион сюжет (45 тема)<br>Шәүлә театры атрибутлары<br>К.В.Закирова “Балачак аланы”(346 б.) |
| | | **Анимацион сюжет карау “**Күңелле уеннар”(эчтәлеге буенча әңгәмә)<br>**Шәүлә театры “Әйдә бергә уйныйк”.**<br>**Хәрәкәтләр белән шигырь уку “Аю”** (балалар хәрәкәтләрне кабатлыйлар). **Шигырь- табышмак уку:**<br>Не обижен, а надут,<br>Его по полю ведут,<br>Скачет он и там, и тут.<br>Ну , конечно,- это…(туп). | | |
| **Февраль**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Күңелле уеннар**<br>Сүзлек:<br>Курчак<br>туп | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Төрле зурлыктагы уенчыклар.<br>Аудиоязма 51. |
| | | **Сүзле уен** “Әйдә бергә уйныйк”. (балалар парлашып уйныйлар)<br>Тәрбияче: Позови друга поиграть.<br>Оля: Алия, кил монда. Мә туп, уйна.<br>Алия: Рәхмәт! Туп матур, зур. Мә курчак, уйна.<br>Оля: Рәхмәт! Курчак матур.<br>Аудиоязма тыңлау. (51нче кисәк) “Слушай- пой!”, “Тыңла-җырла!”<br>**Җыр “Уенчыклар”.**<br>Туп матур? Туп матур?<br>Әйе,әйе, туп матур.<br>Әйе, әйе, туп матур. | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Аю зур? Аю зур?<br>Әйе,әйе, аю зур.<br>Әйе,әйе, аю зур.<br>Бу курчак? Бу курчак?<br>Әйе,әйе, бу курчак.<br>Әйе,әйе, бу курчак. | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Анимацион сюжет (45 тема) К.В. Закирова “Балачак аланы”(332 б.) |
| | | **Өстәл театры “Күңелле уеннар”** (анимацион сюжет буенча)<br>**Хәрәкәтле уен “Куышу”.**<br>**Шигырь- табышмак уку:**<br>Круглый, словно колобок,<br>Он, как зайка, прыг да скок.<br>Это мой весёлый друг.<br>Ну, конечно, - это... (туп). | | |
| **Февраль**<br>**III атна**<br>**3.1**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Уенчыклар Юабыз.**<br>Сүзлек:<br>пычрак<br>чиста<br>ю | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Рәсемнәр: чиста һәм пычрак уенчыклар сурәтләнгән. Чиста һәм пычрак уенчыклар. Савыт белән су. Эш дәфтәре. |
| | | **Тәрбияче балаларга бер үк уенчык рәсеменең пычрак һәм чиста вариантларын күрсәтә:**<br>Тәрбияче: Туп чиста, туп пычрак, аю чиста, аю пычрак. (Балалар тәрбияче артыннан кабатлыйлар).<br>**Дидактик уен “Уенчык нинди?”**(Тәрбияче рәсем күрсәтә.)<br>Тәрбияче: Туп (аю) нинди?<br>Балалар: Туп (аю) чиста ( пычрак).<br>**Дидактик уен “Дөрес әйт”.**<br>Тәрбияче пычрак ( чиста) туп рәсеме күрсәтеп сорый:<br>- Туп чиста?<br>Бала: Юк, туп пычрак. ( Әйе, туп чиста.)<br>**Дидактик уен “Уенчыклар юабыз”.**<br>Тәрбияче пычрак уенчык тупны күрсәтә.<br>Тәрбияче: Туп нинди?<br>Балалар: Туп пычрак.<br>Тәрбияче: Туп ю (тупны юалар). Туп нинди?<br>Балалар: Туп чиста.<br>Башка уенчыкларны да шулай юалар.<br>**Дәфтәрдә эш. 13нче бирем “ Отметь правильно” ( ИКТ- уен).** | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Анимацион сюжет (45 тема). К.В.Закирова “На поляне детства” (59 б.) |
| | | **Сәхнәләштерелгән уен** “Уенчыклар юабыз”.<br>**Анимацион сюжетны сәхнәләштерү** “Күңелле уеннар”<br>**Уку Р.Фахрутдин** “Воспитанный ребенок” ( балалар белән чисталык турында әңгәмә). | | |
| **Февраль III атна 3.2** (режим вакыты) | **Тема: Ю** Сүзлек: ю | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Пычрак һәм чиста вариантлары бирелгән рәсемнәр. Уенчыклар. Эш дәфтәрләре. Карандашлар. Аудиоязма 52-53. |
| | | **Дидактик уен “ Әйе, юк”.** ( Балаларга бер үк рәсеменең пычрак һәм пичта вариантлары таратыла).<br>Тәрбияче: Оля, туп чиста?<br>Оля: Юк, туп пычрак. ( Әйе, туп чиста.<br>**Уен ситуациясе “Иптәшеңә уенчык юарга тәкъдим ит”.**<br>Аудиоязма (52нче кисәк).<br>Тәрбияче: После прогулки игрушки испачкались. Надо их помыть. Акбай, помой мячик. Туп ю.<br>**Попросите друг друга помыть игрушку.**<br>Оля: Коля, машина ю.<br>Коля: Оля, туп ю.<br>**Сүзле күнегү “Ю”.** Аудио ( 53нче кисәк)<br>Ю,ю,ю – туп ю. Ю,ю,ю – машина ю. Ю,ю,ю – курчак ю.<br>Ю,ю,ю – куян ю. Ю,ю,ю –алма ю. Ю,ю,ю- аю ю.<br>Ю,ю,ю – песи ю. Ю,ю,ю – эт ю. | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Анимацион сюжет (48 тема). Театр атрибут-лары, предметлы рәсемнәр, уенчыклар. |
| | | **Сәхнәләштерелгән уен “Уенчыклар пычранган, юабыз”.**<br>**Хәрәкәтле уен “Соры куян кунакка җыена”.**<br>**Анимацион сюжет карау “ Акбай, Мияу мажаралары”** (Эчтәлеге буенча әңгәмә)<br>**Шәүлә театры “Дустыңны макта”.** | | |
| **Февраль IV атна** | **Тема: Дуслар** | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Уенчыклар. Аудиоязма 47. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **4.1**<br>(режим вакыты) | **кунакка килгән. Уйнарга чакыр.** | **Сүзле уен "Уенчыкны макта!"**<br>Тәрбияче: Туп (аю) нинди?<br>Балалар: Туп (аю) чиста ( пычрак).<br>**Дидактик уен "Мин кушканны үтә, әйт".**<br>**Җырлы- биюле уен "Карусель".** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | К.В.Закирова "Балачак аланы" (104 б.) |
| | | **Уку А.Валеева** "Домашние животные, звери и птицы**".**<br>Кто живёт в лесном краю? Там живёт медведь- аю.<br>Я кричу Дружку: "Привет!" А собака будет эт.<br>Кто мурлыкает, спроси. Это кошечка – песи.<br>**Р.Валеева** "Кыңгырау чәчәк"(дуслык турында әңгәмә).<br>**Сәхнәләштерелгән уен** "Дуслар кунакка килгән"<br>**Уку** (тәрбияче тәрҗемәсе белән) **"Кыңгырау чәчәк"**(дуслык турында әңгәмә). | | |
| **Февраль IV атна 4.2**<br>(режим вакыты) | **Тема: Олянын уенчыклары пычранган. Оляга ярдәм ит.**<br><br>Сүзлек: песи | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | "Серле тартма". Уенчыклар. К.В.Закирова "Әй уйныйбыз, уйныйбыз..." 44б Р.К.Шаехова "Раз- словечко, два – словечко." (32 с.)Ф.Юсупов Балалар бакчасы (62 б.) |
| | | **Дидактик уен " Серле тартма".**<br>**Дидактик уен " Нәрсә юк?"**<br>**Сүзле уен "Мин нинди уенчык турында әйттем?"** ( Чиста- пычрак). **Хәрәкәтле уен** "Үзеңә иптәш сайла." | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | |
| | | **Уку Б.Рәхмәт "Су"** ( на русском и татарском языках).<br>**Сәхнәләштерелгән театр "Дуслар белән уйныйбыз".**<br>**Уку " Лечу матрёшку"** ( **песи** сүзен ныгыту). | | |

## Март ае.

| Үткәрү вакыты | Тема Сүзлек | ЭШ ТӨРЛӘРЕ | Индиви-дуаль эш | Җиһазлау |
|---|---|---|---|---|
| **Март I атна** | **Тема: Саннар** | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Уенчык Мияу, Акбай. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **1.1**<br>(режим вакыты) | Сүзлек:<br>Бер<br>Ике<br>Өч<br>Дүрт<br>Биш<br>Ничә? | **Дидактик уен “Тылсымлы тартма”**<br>Акбай белән Мияу уенчыклар салган тылсымлы тартма алып килгәннәр. Акбай уенчыкларны алып, күрсәтеп “Бу нәрсә?”, “Нинди?” дип сорый. Уенчыкларны өстәлгә тезеп куялар.<br>**Дидактик уен “Барысы ничә?”**<br>Тәрбияче уенчыкларны саный; балалар белән бергә саныйлар. Санау күнекмәләре ныгытыла.<br>**Хәрәкәтле уен “Мин кушканны үтә!”** ( Исемнәрен әйтеп, тәрбияче боерык бирә, бергәләп саныйлар.)<br>- Коля, прыгай, сикер! ( Бер, ике, өч.)<br>- Оля. хлопай, чәбәклә! ( Бер, ике, өч, дүрт.)<br>Саша, топай, тыпырда! ( Бер, ике, өч, дүрт, биш.) | | Тылсымлы тартма.<br>Уенчыклар. |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Р.К.Шаехова “Раз- сло-вечко,два-словечко..” (64 б.) Анимацион сюжет (54 тема).<br>К.В. Закирова “Иң матур сүз” (100, 224 б.) .<br>Театр атрибутлары, предметлы рәсемнәр уенчыклар. |
| | | **Бармак театры “Әйдә бергә саныйбыз!”**<br>**Уку Ә.Бикчәнтәева “Минем әнием”** (русчага тәрҗемә итеп). “ Иң матур сүз” хрестоматиясе (224 б.)<br>**Анимацион сюжет карау “Уйный-уйный саныйбыз”.** (эчтәлеге буенча әңгәмә).<br>**Уку «Как котёнок считать учился».** | | |
| **Март**<br>**I атна**<br>**1.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Саннар**<br>Сүзлек:<br>Бер<br>Ике<br>Өч<br>Дүрт<br>Биш<br>Ничә? | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Бармак театры атрибутлары.<br>Уенчыклар.<br>Эш дәфтәрләре. |
| | | **Бармак уены “Гаилә”**<br>Бармак театры атрибутларын кулланып, гаилә әгъзәләрен әйтү.<br>- Бу кем?<br>- Бабай.<br>- Бу кем?<br>- Әби. Һ.б.<br>**Дидактик уен “ Гаилә әгъзәләрен санау”.**<br>Шул ук бармак уены үрнәгендә.<br>**Дидактик уен “ Кем юк? Ничә?”** | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Балалар күзләрен йома, тәрбияче бармактагы бер гаилә әгъзәсы атрибутын яшерә.<br>Тәрбияче: Кем юк?<br>Бала: Әти юк.<br>Тәрбияче: Посчитай, сколько осталось? Сана, ничә калды?<br>Бала: Бер, ике, өч, дүрт.<br>**Дидактик уен “ Дөрес итеп сана”.**<br>Бергәләшеп малайларны, кызларны, уенчыкларны санийлар. Биш кыз, биш малай.<br>**Дәфтәрдә эш. 14нче бирем. “Сосчитай, сколько яблок”.** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br>**Хәрәкәтле уен “Ничә малай ( кыз)? Кем юк?”**<br>**Сәхнәләштерелгән әкият “Репка”- “Шалкан”**(для родителей).<br>**Уку Г.Юнысова “Зарядкага бас”** (таныш сүзләрне шигырьдә табу) | | К.В. Закирова “Балачак аланы” (307 б.) |
| **Март**<br>**II атна**<br>**2.1**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Уйныйбыз да, саныйбыз да.**<br>Сүзлек:<br>Бер<br>Ике<br>Өч<br>Дүрт<br>Биш<br>Ничә? | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br>**Дидактик уен “ Дөрес итеп сана”.**<br>Бергәләшеп малайларны, кызларны, уенчыкларны санийлар. Биш кыз, биш малай.<br>**Дидактик уен “ Гаилә әгъзәләрен сана. Кем юк?”**<br>Әти, әни, әби, бабай, кыз рәсемнәре. Балалар рәсемнәрне санийлар. Балалар күзләрен йомалар, тәрбияче бер рәсемне яшерә.<br>Тәрбияче: Кем юк?<br>Бала: Кыз (әти,әни,әби,бабай) юк.<br>Тәрбияче: Сана, ничә калды?<br>Бала: Бер, ике,өч, дүрт.<br>**Хәрәкәтле уен “Туп”.** Аудио (54нче кисәк)<br>Туп,туп, матур туп,<br>Сикер,сикер, матур туп.<br>Бер,ике,өч,дүрт, биш,<br>Сикер,сикер, матур туп.<br>**“Җырлап әйт!”** Аудио (55нче кисәк) “Слушай!”, “Тыңла!”<br>Бер,ике,өч,дүрт, биш аю,<br>Зур аю, матур аю. (ике тапкыр кабатлана)<br>**Җыр.** Аудио (56) “Слушай- пой!”, “Тыңла- җырла!”<br>Бер,ике,өч,дүрт, биш аю, | | Уенчыклар.<br>Рәсемнәр: әти, әни, әби, бабай, кыз, малай.<br>Аудиоязма 54-56 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Зур аю, матур аю. (ике тапкыр кабатлана) | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | К.В.Закирова “Бала-чак – уйнап- көлеп үсәр чак”(100 б.) |
| | | **Рус халык әкиятен сәхнәләштерү “ Курочка ряба”- “ Чуар тавык”. Хәрәкәтле уен “Ике һәм өч”.**<br>**Санамыш ятлау. Бер, ике, өч, сиңа көч, син моннан күч.** | | |
| **Март**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Уенчыклар**<br>Сүзлек:<br>Бер<br>Ике<br>Өч<br>Дүрт<br>Биш<br>Зур<br>Кечкенә<br>Матур<br>Чиста<br>Ничә? | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Уенчык Мияу.<br>Серле тартма.<br>Уенчыклар.<br>Аудиоязма 57. |
| | | **Мияу, тартмага салып, уенчыклар алып керә,балалар белән таныша.**<br>Мияу: Исәнмесез! Мин песи- мин Мияу. Син кем?<br>Бала: Мин Оля ( Коля, Миша).<br>**Дидактик уен “Дөрес әйт”.** (Уенчык күрсәтеп сорый).<br>Мияу: Аю?<br>Балалар: Юк.<br>Мияу: Куян?<br>Балалар: Әйе, куян.<br>Мияу барлык өйрәнгән уенчыкларны, алып күрсәтеп, өстәлгә куя бара.<br>**Дидактик уен “Нәрсә юк?”** (Мияу уенчыкларны берәм-берәм яшерә).<br>Мияу: Нәрсә юк?<br>Бала: Куян юк ( туп юк. һ.б.).<br>**Дидактик уен “Уйлап әйт, ничә уенчык?”**<br>Бала борылып баса. Тәрбияче калган балаларга ике уенчык күрсәтә.Борылып баскан бала уенчыкның ничә икәнен уйлап әйтә.<br>Бала: Өч?<br>Балалар: Юк.<br>Бала: Ике?<br>Балалар: Әйе.<br>**“Җырлап әйт!”**<br>Бирелгән уенчыклар турында “матур”, “зур”, “чиста”, “әйбәт”, “кечкенә” сүзләрен кертеп җырлау. Аудио ( 57нче кисәк)<br>Бер аю, ике аю, өч аю,дүрт аю, биш аю, зур аю.<br>Бер куян, ике куян, өч куян, дүрт куян, биш куян, кечкенә куян.<br>Бер песи, ике песи, өч песи,дүрт песи, биш песи, матур песи. | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Бер эт, ике эт, өч эт,дүрт эт, биш эт, әйбәт эт.<br>Бер туп, ике туп, өч туп,дүрт туп, биш туп, чиста туп. | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Битлекләр, уенчыклар. |
| | | **Аз хәрәкәтле уен “ Мин сан әйтәм, син шул күләмдә предметны тап”.**<br>**Җырлы өстәл театры “Уенчыклар саныйбыз”.**<br>**Хәрәкәтле уен “Үз адымнарыңны сана”.**(Балага өч адым ясарга һәм туктарга тәкъдим итү. Бала атлый һәм саный.) | | |
| **Март**<br>**III атна**<br>**3.1**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Ничә уенчык?**<br><br>Сүзлек:<br>Бер<br>Ике<br>Өч<br>Дүрт<br>Биш<br>Ничә? | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Уенчык Акбай, Мияу.“Кибет” сюжетлы-рольле уен өчен атрибутлар. Бердән бишкә кадәр күләмдә төрле уенчыклар. Аудиоязма 58-60. |
| | | **“Җырлап әйт!”** Аудио (58нче кисәк) “Слушай!”, “Тыңла!”<br>Бер,ике,өч,дүрт, биш аю,<br>Зур аю, матур аю. (ике тапкыр кабатлана)<br>**Җыр.** Аудио (59нчы кисәк) “Слушай- пой!”, “Тыңла- җырла!”<br>Бер,ике,өч,дүрт, биш аю,<br>Зур аю, матур аю. (ике тапкыр кабатлана)<br>**Дидактик уен “Ничә уенчык? Сана”.**<br>Өстәлдә бердән бишкә кадәр күләмдә төрле уенчыклар.<br>- Ничә аю?<br>- Бер, ике, өч, дүрт аю.<br>- Ничә куян?<br>- Бер, ике, өч, дүрт, биш куян.<br>**Сюжетлы-рольле уен “ Уенчыклар кибете”.**<br>Акбай сатучы ролендә. Аудио (60нчы кисәк).<br>Мияу: Исәнме, Акбай!<br>Акбай: Исәнме, Мияу!<br>Мияу: Хәлләр ничек?<br>Акбай: Әйбәт, рәхмәт.<br>Мияу: Куян бир.<br>Акбай: Ничә куян?<br>Мияу: Ике .<br>Акбай: Мә ике куян.<br>Мияу: Рәхмәт.<br>Акбай: Сау бул, Мияу!<br>Мияу: Сау бул, Акбай! | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Шул үрнәктә балалар Акбайдан уенчыклар “сатып” алалар. | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | К.В.Закирова “Әй уй-ныйбыз, уйныйбыз” (35 б.) К.В.Закирова “На поляне детства” (46 с.) Бияләй театры атрибутлары. |
| | | **Хәрәкәтле уен “ Очкычлар”** (балаларны төркемгә бүленеп хәрәкәт итәргә өйрәтү: икешәр, өчәр...).<br>**Уку Ш.Маннур “Гусята”.** ( Рольләргә бүлеп).<br>**Бияләй театры “Уенчык сатып алабыз”.** | | |
| **Март**<br>**III атна**<br>**3.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Уйный- уйный санныйбыз.**<br>Сүзлек:<br>Бер<br>Ике<br>Өч<br>Дүрт<br>Биш<br>Ничә? | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | |
| | | **“Җырлап әйт!”** Аудио (57нче кисәк)<br>**Сүзле-хәрәкәтле уен “Куяннар”.**<br>Үрнәк: Исәнме, куян!<br>Исәнмесез, куяннар!<br>Бер куян, ике куян...<br>Акбай килә һау-һау!<br>**Анимацион сюжет “ Уйный-уйный санныйбыз”.** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Аудиоязма 57. К.В. Закирова “ Әй уйныйбыз-уйыйбыз”(39б.) Анимацион сюжет (54 тема). Контурлы рәсемнәр, |
| | | **Анимацион сюжетны сәхнәләштерү “Уйный-уйный санныйбыз”.**<br>**Рәсем буяу.**<br>**Курчак театры “ Куяннар”.**<br>**Хәрәкәтле уен “Уенчыкларны җый”.**( Балаларга таралган уенчыкларны тәрбияче әйткән сан буенча җыярга) | | |
| **Март**<br>**IV атна**<br>**4.1**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Бергәләп уйныйбыз.**<br><br>Сүзлек:<br>Бабай<br>әби<br>әти<br>әни<br>кыз | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Бармак уенына атрибутлар. Күрсәтмә рәсемнәр: бабай, әби, әти, әни, кыз, малай. Уенчыклар. Эш дәфтәрләре. Карандашлар. Аудиоязма 61. |
| | | **Дидактик уен “Бармак уены”.**<br>Уң кул бармакларын күрсәтеп: Аудио ( 61 нче кисәк)<br>Исәнме, бабай!<br>Исәнме , әби!<br>Исәнме, әти!<br>Исәнме , әни!<br>Исәнме, малай!<br>Сул кул бармакларын күрсәтеп: | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | малай<br>уенчыклар | Исәнме, бабай!<br>Исәнме , әби!<br>Исәнме, әти!<br>Исәнме , әни!<br>Исәнме, кыз!<br>**Дидактик уен “ Исәнме, сау бул”.** ( Рәсемнәр тактада кире яклары белән әйлән- дереп куелган. Тәрбияче рәсемне әйләндереп күрсәтә.)<br>Балалар: Исәнме, бабай!<br>Балалар: Сау бул, бабай!<br>Тәрбияче рәсемне кире ягы белән әйләндереп бара һ.б.<br>**Дәфтәрдә эш. 15 нче бирем “ Найди пару”.** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | К.В.Закирова “Балачак аланы” (94 б.)<br>К.В.Закирова “ На поляне детства” (34 с.) |
| | | **Ата- аналар өчен әкият сәхнәләштнрү “Курочка ряба”- “Чуар тавык”.**<br>**Рәсемле өстәл театры “Исәнме, сау бул”.**<br>**Уку “Ике ялку”- “Два лентяя”** (татар халык әкияте). | | |
| **Март**<br>**IV атна**<br>**4.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Бергәләп уйныйбыз.**<br><br>Сүзлек:<br>Бабай<br>әби<br>әти<br>әни<br>кыз<br>малай<br>уенчыклар | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Уенчык Акбай, Мияу.<br>Ашамлык муляжлары.<br>Аудиоязма 62. |
| | | **Уен ситуациясе “Кунак чакыру”.**<br>Акбай белән Мияу бер-берсен кунакка чакырып сыйлыйлар.<br>Аудио (62нче кисәк)<br>Мияу: Исәнме, Акбай!<br>Акбай: Исәнме, Мияу!<br>Мияу: Акбай, кил монда, утыр.<br>Акбай: Рәхмәт!<br>Мияу: Акбай, мә ипи , аша.<br>Акбай: Рәхмәт! Ипи тәмле.<br>Мияу: Сау бул, Акбай!<br>Акбай: Сау бул, Мияу!<br>Акбай белән Мияу үрнәгендә, балалар бер-берсен кунакка чакыралар, сыйлыйлар.<br>**Хәрәкәтле уен** “Сыерчыклар кайтты”. ( Саннарны кабатлау. Түгәрәкләр- сыерчык оясы, сигнал буенча балалар таралышып йөгерәләр һәм сигнал буенча түгәрәккә “ очып керәлр” | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | К.В.Закирова “Иң матур сүз” |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | **Курчак театры “Кунак чакыру”.**<br>**Әти-әниләргә төрле тематикага бармак уеннары күрсәтү.**<br>**Хәрәкәтле уен “Үз парыңны тап”.**<br>**Татар халык уены “Очты, очты...”- “Улетели, улетели...”.** | | (100 б.) |

## Апрель ае

| Үткәрү вакыты | Тема Сүзлек | ЭШ ТӨРЛӘРЕ | Индиви-дуаль эш | Җиһазлау |
|---|---|---|---|---|
| **Апрель**<br>**I атна**<br>**1.1**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Кунак чакырабыз.**<br>Сүзлек:<br>бабай<br>әби<br>әти<br>әни<br>кыз<br>малай<br>уенчыклар<br>ашамлыклар | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br>**Уен ситуациясе «Кунак чакыру».**<br>**Дәфтәрдә эш. 16 нчы бирем «Угости».**<br>**Хәрәкәтле уен «Кем кайда качкан? Әйт һәм сана».** | | Уенчык Акбай, Мияу.<br>Ашамлык муляжлары.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма 62.<br>К.В. Закирова «На по-<br>ляне детства» (41 с.).<br>Өстәл, бияләй театры атрибутлары. |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br>**Уку Б.Рәхмәт «Петушок» (рольләргә бүлеп уку).**<br>**Өстәл театры «Куян аюда кунакта».**<br>**Бияләй театры «Бүләк бүләк ит».** | | |
| **Апрель**<br>**I атна**<br>**1.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Күңелле ял итәбез.**<br>Бабай, әби<br>әти, әни<br>кыз, малай<br>уенчыклар<br>ашамлыклар | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br>**Дидактик уен «Бармак уены».Уен ситуациясе «Кунак чакыру».**<br>**Анимацион сюжет «Күңелле ял итәбез».**<br>**Хәрәкәтле уен «Полетели, полетели...»** (сүзлек байлыгын активлаштыру). | | Уенчык Акбай, Мияу. Ашамлык муляжлары.<br>Аудиоязма 62.<br>Анимацион сюжет (57 тема) |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br>**Анимацион сюжетны сәхнәләштерү «Күңелле ял итәбез».**<br>**Курчак театры «Мияу белән песидә кунакта».** | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **Апрель**<br>**II атна**<br>**2.1**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Без татарча сөйләшәбез.**<br>Сүзлек:<br>бабай<br>әби<br>әти<br>әни<br>кыз<br>малай<br>аю<br>куян<br>санау | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Курчак театры: песи<br>белән эт.<br>Күрсәтмә рәсемнәр: бабай, әби, әти, әни, кыз, малай.<br>Уенчыклар.<br>Уенчык Акбай, Мияу. |
| | | Уен ситуациясе «Акбай белән Мияу кунакка килә».<br>Акбай белән Мияу уенчык рәсемнәрен алып керәләр. Ишек шакыйлар.<br>Балалар: Кем анда?<br>Мияу: Мин песи.<br>Акбай: Мин эт.<br>Балалар: Кил монда, Акбай. Кил монда, Мияу.<br>Балалар: Исәнме, Акбай! Исәнме, Мияу!<br>Мияу: Исәнмесез!<br>Акбай: Исәнмесез!<br>Дидактик уен «Уенчык сорап ал».<br>Балалар Акбай белән Мияудан уенчык сорап алалар:<br>— Мияу (Акбай), аю бир әле.<br>— Мә аю (туп).<br>— Рәхмәт.<br>Дидактик уен «Бел, әйт, сана».<br>Балаларда уенчыклар.<br>Тәрбияче: Аю (куян), кил монда.<br>Аю (куян) уенчыгы тоткан балалар түгәрәккә басалар. Барлык балалар баскач,<br>тәрбияче сорый:<br>— Ничә аю?<br>Балалар: бер, ике, өч аю.<br>1 дән 5 кә кадәр саннар ныгытыла.<br>Хәрәкәтле уен «Кем кайда качкан? Әйт һәм сана». | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Уенчыклар, театр атрибутлары. |
| | | **Кечкенәләр төркеме балаларына сәхнәләштерелгән әкият күрсәтү «Репка» — «Шалкан». Бияләй театры «Сыйла». Хәрәкәтле уен «Җитез бул».** *(Балалар түгәрәк ясап тезеләләр. Түгәрәк уртасына балалар саны буенча уенчыклар куела. Тәрбияче сигналы буенча, балалар таралышып йөгерәләр. Бу вакытта тәрбияче бер уенчыкны алып куя.*<br>*Тәрбияче сигналы буенча, балалар уенчыкларга таба йөгерәләр. Һәр бала бер уенчык ала һәм югары күтәрә. Уенчык җитмәгән* | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | *бала уеннан чыга. Балалар уенчыкларның исемнәрен атап чыгарга тиеш. Уен шулай дәвам итә.)* | | |
| **Апрель**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Без татарча сөйләшәбез.**<br>Сүзлек:<br>Бабай,әби<br>әти,әни<br>кыз,малай<br>аю,куян<br>санау | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br>**Дидактик уеннар «Парын тап», «Әйт, сана, күрсәт».**<br>**Өстәл уеннары «Уенчык нинди? Ничә?», «Тап, күрсәт», «Дөрес сана». Хәрәкәтле уеннар «Полетели, полетели...»** *(сүзлек байлыгын активлаштыру).*<br>**Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку)<br>**Мультфильм карау. Г.Тукай «Гали белән Кәҗә», «Шаян песи», «Ялкау маэмай», «Бала белән Күбәләк»** *(эчтәлеге буенча әңгәмә).* **Мультфильмнар эчтәлеге буенча рәсемнәр буяу.**<br>**Уку «На рыбалку»** ***(куян*** *сүзен кабатлау).* | | Күрсәтмә рәсем-нәр:бабай,әби, әти, әни,кыз, малай.<br>Уенчыклар.<br>Р.К.Шаехова «Раз-словечко, два-словечко...» (35 с.). |
| **Апрель**<br>**III атна**<br>**3.1**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Бу өйдә кем яши?**<br>Сүзлек:<br>Бабай<br>әби<br>әти<br>әни<br>кыз<br>малай<br>санау | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br>**Уен ситуациясе «Бу өйдә кем яши? Ул нинди?»**<br>*Тәрбияче матур өй, гаилә әгъзалары рәсемнәрен күрсәтә.*<br>Тәрбияче: Какой красивый дом. Давайте вспомним, кто в этом доме живёт?<br>Тәрбияче: Бу кем?<br>Балалар: Әти (әни, бабай, әби, кыз, малай).<br>Тәрбияче: Әти (әни, бабай, әби, кыз, малай) нинди?<br>Балалар: Зур (матур, әйбәт).<br>**Сюжетлы-рольле уен «Акбай белән Мияу кунак чакыра».**<br>Балаларга әти, әни, бабай, әби, кыз, малай рольләре бүленеп бирелә. Син кем? — дигән сорау бирелә.<br>— Син кем?<br>— Мин бабай.<br>*Акбай белән Мияу гаилә әгъзаларын өстәл янына чакырып, утыртып сыйлыйлар.*<br>— Тук-тук!<br>Акбай: Кем анда?<br>Әби: Мин әби.<br>Акбай: Әби, кил монда. Исәнме, әби! | | Өй.<br>Гаилә әгъзалары рәсемнәре (күрсәтмә рәсемнәр).<br>Уенчык Акбай, Мияу.<br>Эш дәфтәре.<br>Аудиоязма 63. |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Әби: Исәнмесез!<br>Акбай: Әби, утыр.<br>Әби: Рәхмәт!<br>Акбай: Әби, мә чәй, эч.<br>Әби: Рәхмәт, чәй тәмле!<br>*Шул үрнәктә барлык гаилә әгъзаларын чакырып сыйлыйлар.*<br>**Аудиоязма тыңлау, кушылып җырлау.**<br>*Аудио (6 нчы кисәк) «Слушай — пой!», «Тыңла — җырла!»*<br>Бу өй матур,<br>Бу өй зур.<br>Монда яши бабай.<br>— Мин бабай *(бабай битлеге кигән бала уртага чыга).*<br>Монда яши әби.<br>— Мин әби *(әби битлеге кигән бала уртага чыга).*<br>Монда яши әти.<br>— Мин әти *(әти битлеге кигән бала уртага чыга).*<br>Монда яши әни.<br>— Мин әни *(әни битлеге кигән бала уртага чыга).*<br>Монда яши малай.<br>— Мин малай *(малайлар чыга).*<br>Монда яши кыз.<br>— Мин кыз *(кызлар чыга).*<br>Әйе шул, әйе шул.<br>Бу өй матур,<br>Бу өй зур.<br>**Дәфтәрдә эш. 17 нче бирем «Найди, назови и обведи».** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | К.В. Закирова «Әй уйныйбыз, уйный-быз...» (108 б.).<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (204 с.). |
| | | **Сәхнәләштерелгән күренеш «Бу өйдә кем яши?»**<br>**Әйлән-бәйлән уены «Кем тавышы, бел».** *(«Гаилә» темасын ныгыту.)*<br>***Хәрәкәтле уен «Кызлар-малайлар».*** *Шигырь-табышмак уку:*<br>Кто на свете всех милее?<br>Кто заботится о вас?<br>Сварит вкусные пельмени,<br>Ну, конечно же, … *(әни).*<br>Кто научит, как быть смелым, | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Сильным, ловким и умелым?<br>Даст машину завести?<br>Ну, конечно же, ... *(əти).*<br>**Уку А.Ерикай «Четыре яблока».** | | |
| **Апрель**<br>**III атна**<br>**3.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Уенчыклар илендə.**<br>Сүзлек: уенчыклар | **Режим вакытында уен эшчəнлеге**<br>(Иртə, саф һавада йөрү, кич) | | |
| | | **Өстəл театры «Яраткан уенчыгыңны сорап ал».**<br>**Сəхнəлəштерелгəн күренеш «Иптəшеңне чакыр, пычрак уенчыгыңны ю».**<br>**Дидактик уен «Өлешлəрдəн уенчыклар рəсемен җый».**<br>**Хəрəкəтле уен «Уенчыкка барып җит».** *(Бала куелган уенчыкка кадəр адымнарын санап бара, уенчыкның исемен атый.)* | | |
| | | **Өстəмə материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур əдəбият əсəрлəре уку) | | Уенчыклар.<br>Шəүлə театры атрибутлары |
| | | **Сəхнəлəштерелгəн күренеш «Уенчыкларда кунакта».** лары.<br>**Шəүлə театры «Уенчыкны ата».**<br>**Хəрəкəтле уен «Нəрсə кирəк?»** *(Балалар арасыннан куучы билгелəнə. Куучы читкəрəк китеп торган вакытта, тəрбияче балаларга уенчык исемнəрен əйтеп чыга. Куучыны чакырып: «Нəрсə кирəк?» — дип сорый. Уйнаучыларга əйтелгəн уенчык исеме аталса, шул бала кача, куучы аны куып җитəргə тиеш. Əгəр тотылмаса, уйнаучы кире уенга кайта.)* | | |
| **Апрель**<br>**IV атна**<br>**4.1**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Ягымлы сүзлəр.**<br><br>Сүзлек:<br>Исəнме-исəнмесез<br>Сау бул- сау булыгыз<br>рəхмəт | **Режим вакытында уен эшчəнлеге**<br>(Иртə, саф һавада йөрү, кич) | | Уенчык Акбай, Мияу. Ашамлык муляжлары.<br>К.В.Закирова «Уй-ный-уйный үсəбез» (57 б.).<br>К.В. Закирова «Ба-лачак -уйнап-көлеп үсəр чак» (91 б.).<br>К.В. Закирова «Иң матур сүз» хресто-матиясе (33 б.). |
| | | **Ситуатив күнегүлəр «Куян аюга кунакка килə».** *(— Исəнме (сау бул), аю.)* **«Акбай Мияуны сыйлый».** *(Рəхмəт.)*<br>**Хəрəкəтле уен «Төсле машиналар».**<br>**ИКТ-уен «Гаилə əгъзаларын каршы алу».** | | |
| | | **Өстəмə материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур əдəбият əсəрлəре уку) | | |
| | | **Сəхнəлəштерелгəн күренеш «Кунакка барабыз».**<br>**Санамыш ятлау. Бер, ике, өч, малайларда көч.**<br>**Аз хəрəкəтле уен: «Кемгə телəсəң, шуңа бир».**<br>**Уку. Ш. Галиев «Яз».** | | |
| **Апрель**<br>**IV атна** | **Тема:**<br>**Боерыкны** | **Режим вакытында уен эшчəнлеге**<br>(Иртə, саф һавада йөрү, кич) | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **4.2**<br>(режим вакыты) | **аңлау.**<br><br>Сүзлек:<br>Кил<br>Утыр<br>Сикер<br>Ю<br>Аша<br>Эч<br>уйна | **Сүзле уеннар «Мин әйтәм, син эшлә», «Исемен әйтсәң бирәм».**<br>**Дидактик уеннар «Серле янчык», «Әйе, юк».**<br>**Аз хәрәкәтле уен «Мин кушканны үтә».** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | |
| | | **Курчак театры «Кызыклы уенчыклар».**<br>**Аз хәрәкәтле уен «Әйе — юк». *(Әйе-әйе — сикерәләр, юк-юк — йөгерәләр).***<br>**Хәрәкәтле уен «Стоп!» (***Балалар арасыннан уенны алып баручы билгеләнә. Ул төрле хәрәкәтләр башкарырга команда бирә. «Стоп!» — дигәч, балалар селкенмичә басып торырга тиешләр. Кем селкенә, уеннан чыга. Уен шулай дәвам итә.)*<br>**Конкурс. Г. Тукай иҗаты буенча *(на русском и татарском языках).*** | | |

## Май ае

| Үткәрү вакыты | Тема Сүзлек | ЭШ ТӨРЛӘРЕ | Индивидуаль эш | Җиһазлау |
|---|---|---|---|---|
| **Май**<br>**II атна**<br>**2.1**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Без театр уйныйбыз.<br>*Сүзлек:*<br>бабай<br>әби<br>әти<br>әни<br>малай<br>кыз<br>өй | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Персонажлар: барлык гаилә әгъзалары, эт, песи, куян, аю.<br>Күренеш: бик матур өй макеты, агачлар, эскәмия, капка.<br>Татар халык көе.<br>Аудиоязма 63–64. |
| | | **Театральләштерелгән уен «Минем өем».**<br>*Балаларга рольләр бүленеп бирелә. Ишек шакып керәләр.*<br>Балалар: Кем анда?<br>Әби: Мин әби.<br>Балалар: Әби, кил монда. Исәнме, әби!<br>Әби: Исәнмесез.<br>Балалар: Хәлләр ничек?<br>Әби: Әйбәт.<br>*Шул үрнәктә барлык персонажлар да керә.*<br>**Аудиоязма тыңлау, кушылып җырлау.**<br>*Аудио (63 нче кисәк) «Слушай, пой!» — «Тыңла, җырла!»*<br>Бу өй матур, бу өй зур.<br>Монда яши бабай. — Мин бабай.<br>Монда яши әби. — Мин әби.<br>Монда яши әти. — Мин әти.<br>Монда яши әни. — Мин әни.<br>Монда яши малай. — Мин малай *(малайлар чыга).* | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Монда яши кыз. — Мин кыз *(кызлар чыга).*<br>Әйе шул, әйе шул.<br>Бу өй матур, бу өй зур.<br>**Татар халык көенә күмәк бию.** *Аудио (64 нче кисәк)* | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | К.В. Закирова «Уйный-уйный үсәбез» (58 б.).<br>Анимацион сюжет (48 тема). |
| | | **Курчак театры «Минем өем».**<br>**Анимацион сюжет карау «Акбай белән Мияу мажаралары».**<br>**Хәрәкәтле уен «Кыңгырау»** ***(санау,боерык бирү, ягымлы сүзләр).*** | | |
| **Май**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>Кызыклы уеннар.<br>*Сүзлек:*<br>яз<br>яңгыр | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Өй макеты, гаилә әгъзалары рәсемнәре, уенчыклар.<br>К.В. Закирова «Балачак — уйнап-көлеп үсәр чак» (42, 112 б.). |
| | | **Түгәрәк уен «Карусель».**<br>**Җыр «Уенчыклар».** *Аудио (5 нче кисәк)*<br>**Татар халык уены «Яз, балалар, яңгыр».**<br>**Татар халык биюе «Әпипә».** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | |
| | | **Мультфильм карау «Төлке белән Каз»** *(эчтәлеге буенча әңгәмә).*<br>**Күргәзмә оештыру «Татар халык әкиятләре геройлары»** *(ата-аналар белән берлектә).* | | |
| **Апрель**<br>**III атна**<br>**3.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Минем дуслар.**<br><br>***Сүзлек:***<br>**бүре**<br>**тавыш** | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | К.В. Закирова «Балачак — уйнап-көлеп үсәр чак» (42 б.). |
| | | **Дидактик уеннар** «Исәнме, сау бул!», «Дөрес әйт», «Уйлап әйт: ничә уен-<br>чык, нинди?» **Әйлән-бәйлән уены «Кем тавышы, бел».**<br>**Сюжетлы-рольле уен «Акбай белән Мияу кунак чакыра».**<br>**Татар халык уены «Соры бүре».** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Анимацион сюжет (45 тема).<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (43 с.). |
| | | **Сәхнәләштерелгән күренеш «Дусларны уйнарга чакырабыз».**<br>**Анимацион сюжет карау «Күңелле уеннар»** ***(эчтәлеге буенча әңгәмә).*** **Уку Р.Валеева «Кукле платье подарила»** | | |
| **Май**<br>**IV атна** | **Тема:**<br>**Бездә Сабантуй.** | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| **4.1**<br>(режим вакыты) | Сүзлек:<br>Сабантуй<br>Яз<br>яңгыр | ***Сүзле уен «Бүләкләр җыябыз».*** *(Нәрсә? Нинди? Ничә?)*<br>***Татар халык уены «Яз, балалар, яңгыр».***<br>***Мультфильм карау «Сабантуй».*** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | Уенчыклар, ашам-лык муляжлары.<br>К.В. Закирова. «Уйный-уйный үсәбез»(66 б.).<br>К.В.Закирова «На поляне детства» (237 с.). |
| | | **Сабантуйга татар милли орнаментлы чакыру билетлары әзерләү.**<br>**Уку Э.Блинова «Сабантуй».**<br>**Сәхнәләштерелгән күренеш «Сабантуй бәйрәменә бүләк җыябыз».**<br>**«Сабантуй» җырын тыңлау.** | | |
| **Май**<br>**IV атна**<br>**4.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Хуш киләсең, Сабантуй!**<br><br>Сүзлек:<br>Ат чабышы<br>Чиләк<br>Чүлмәк | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Уенчыклар, ашамлыклар муляжлары.<br>Сабантуй атрибутлары.<br>К.В. Закирова «На поляне детства» (237, 238 с.). |
| | | **Сюжетлы-рольле уен «Кунакларны каршы алабыз».**<br>**Хәрәкәтле уеннар «Ат чабышы», «Капчык киеп йөгерү», «Чүлмәк вату»,**<br>**«Чиләк белән су ташу»...** | | |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | |
| | | **Уку Ш.Галиев «Батыр Сабантуй», Р. Курбан «Сабантуй».** ***(Рус теленә тәрҗемә ителгән шигырьләр.)***<br>**«Сабантуй» көенә күмәк бию.** | | |

## “Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча тематик план (зурлар төркеме)

| Проект темалары | Эшчәнлек төрләре | Эшчәнлек саны |
|---|---|---|
| **1. Кабатлау** | Минем өем | 1 |
| | “Шалкан” әкияте (катнаш дәрес) | 1 |
| **2. Яшелчәләр** | Кишер үстерәбез | 1 |
| | Баллы кишер (катнаш дәрес) | 1 |
| | Куян күчтәнәче | 1 |
| | Бар матур бакча (катнаш дәрес) | 2 |
| | Серле кәрзин | 2 |
| | Серле янчык | 1 |
| | Яшелчәләр кибете (катнаш дәрес) | 2 |
| | Уйный-уйный эшлибез (катнаш дәрес) | 1 |
| | Без хезмәт яратабыз | 1 |
| | Төсле туплар (катнаш дәрес) | 1 |
| | Төсләр дөньясы | 2 |
| | Юл маҗаралары (катнаш дәрес) | 1 |
| | Уңыш бәйрәме (катнаш дәрес) | 1 |
| | Яшелчә салаты | 1 |
| | Кем эшләми, шул ашамый (катнаш дәрес) | 1 |
| | Яшелчә ю! | 1 |
| | Уйныйбыз да, җырлыйбыз | 1 |
| **3. Ашамлыклар** | Ашханә (катнаш дәрес) | 1 |
| | Ашамлыклар | 1 |
| | Кибеттә (катнаш дәрес) | 1 |
| | Аю кунакка килгән | 1 |
| | Кунак килгән (катнаш дәрес) | 1 |
| | Кем нәрсә ярата? | 1 |
| | Өстәл театры “Кем нәрсә ярата?” (катнаш дәрес) | 1 |
| **4. Савыт-саба** | Туган көн | 1 |
| | Курчак Алиягә булыш (катнаш дәрес) | 1 |
| | Чәй табыны әзерлибез | 1 |
| | Өч аю (катнаш дәрес) | 1 |
| | Төсле чынаяклар | 1 |
| | Чисталыкта – матурлык (катнаш дәрес) | 1 |

| | | |
|---|---|---|
| **5. Киемнәр** | Туган көнгә яңа киемнәр<br>Киемнәр кибете (катнаш дәрес)<br>Курчакны киендер<br>Без киенәбез(катнаш дәрес)<br>Киенергә ярдәм ит<br>Курчакларга булышабыз(катнаш дәрес)<br>Алия йокларга җыена<br>Кибеттә (катнаш дәрес) | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| **6. Шәхси гигиена** | Хәерле көн<br>Ягымлы сүзләр<br>Курчак белән уйныйбыз<br>Шаян уенчыклар | 1<br>1<br>1<br>1 |
| **7. Өй җиһазлары** | Өстәл театры “ Өч аю”<br>Маша һәм өч аю (катнаш дәрес)<br>Кибеттә<br>Ни өчен киемнәр югалган? (катнаш дәрес) | 1<br>1<br>1<br>1 |
| **8. Бәйрәм “ Туган көн”** | Уйнарга яратабыз<br>Уенчыклар иленә сәяхәт (катнаш дәрес)<br>Уйный-уйный үсәбез<br>Курчакның туган көне(катнаш дәрес)<br>Нәрсә бар?<br>Син нәрсә яратасың? (катнаш дәрес)<br>Бар, юк<br>Кем нәрсә ярата? (катнаш дәрес) | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| **9. Бәйрәмнәр “Сабантуй”** | Сабантуйга әзерләнәбез<br>Без театр уйныйбыз (катнаш дәрес)<br>Күңелле сабантуй уеннары<br>Биибез дә, җырлыйбыз (катнаш дәрес)<br>Сабантуй бәйрәме<br>Бездә сабантуй (катнаш дәрес) | 1<br>1<br>1<br>1<br>1<br>1 |
| | | **66 сәгать** |

## Уйный-уйный үсәбез” проекты буенча тематик план ( зурлар төркеме)

| № | Тема | Сәгатьләр саны |
|---|---|---|
| 1. | Кабатлау | 2 сәгать (1-2) |
| 2. | Яшелчәләр | 21 сәгать (3-23) |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | Ашамлыклар | 7 сәгать (24-30) |
| 4. | Савыт-саба | 6 сәгать (31-36) |
| 5. | Киемнәр | 8 сәгать (37-44) |
| 6. | Шәхси гигиена | 4 сәгать (45-48) |
| 7. | Өй җихазлары | 4 сәгать (49-52) |
| 8. | Бәйрәм “Туган көн” | 8 сәгать (53-60) |
| 9. | Бәйрәмнәр “Сабантуй” | 6 сәгать (61-66) |

## “Уйный- уйный үсәбез” проекты буенча календарь план (зурлар төркеме) Сентябрь ае.

| Үткәрү вакыты | Тема Сүзлек | ЭШ ТӨРЛӘРЕ | Индиви-дуаль эш | Җиһазлау |
|---|---|---|---|---|
| **Сентябрь I атна 1.1**<br><br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема: Минем өем**<br><br>Сүзлек:<br>Әти, әни, кыз,малай, Әби, бабай, Кил монда | **Дидактик уен «Өйдә кем яши?»**<br>*(Өй макеты, әни, әти, малай, кыз рәсемнәре күрсәтелә. Һәр гаилә әгъзасын бер-бер артлы чакыралар.)*<br>Тәрбияче: Какой красивый дом. Давайте вспомним: кто живёт в этом доме? Бу кем?<br>Балалар: Әти, әни, малай, кыз.<br>Тәрбияче: Давайте их позовём.<br>Балалар: Әни, кил монда! Исәнме, әни! Хәлләр ничек?<br>Әни: Әйбәт.<br>**Уен ситуациясе «Әби белән бабай бездә кунакта».** *(Балалар әби белән бабай ролендә.)*<br>*(Аудиоязманы тыңлау, кушылып җырлау.)*<br>**Җырлы-биюле уен «Минем өем».** *Аудио (1 нче кисәк)*<br>**Дәфтәрдә эш. 1 нче бирем «Угости».** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була.)* | | Күрсәтмә рәсемнәр: әти, әни, кыз, малай, эт Акбай, песи Мияу,әби, бабай.<br>Битлекләр: әти, әни, кыз, малай, эт Акбай,песи Мияу, әби, бабай.<br>Аудиоязма 1.<br>Эш дәфтәре.<br>Интерактив такта. |
| **Сентябрь I атна 1.2**<br>(режим вакыты) | **Тема: «Шалкан» Әкияте**<br><br>*Сүзлек:*<br>шалкан<br>әти<br>әни | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич)<br><br>**Дидактик уеннар «Өйдә кем яши?», «Кем юк?»**<br>**Уен ситуациясе «Кем анда?»**<br>**Әйлән-бәйлән уены «Бабай шалкан утырткан».**<br>**Җырлы-биюле уен «Минем өем»** *(Аудио 1 нче кисәк)*<br>**Анимацион сюжет карау «Шалкан» әкияте.** *(Анимацион сюжет эчтәлеге буенча әңгәмә үткәрү. Сюжет геройларының рәсемнәрен* | | Күрсәтмә рәсемнәр:әти, әни, кыз, малай,<br>эт Акбай, песи Мияу, әби, бабай.<br>Битлекләр: әти, әни, кыз,малай, эт Акбай, песи Мияу, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кыз<br>малай<br>песи<br>эт<br>әби<br>бабай | *ясарга тәкъдим итү.)* | | әби, бабай.<br>Аудиоязма 1. |
| | | **Өстәмә материал**<br>(Театр уйныйбыз. Матур әдәбият әсәрләре уку) | | К.В. Закирова «Балачак аланы» (390 б.). Г.Тукай «Көз» (120 б.).<br>Театр өчен курчаклар, битлекләр. |
| | | **Сүзле күнегү «Әйдә исәнләшик»** *(битлекләр кулланып).*<br>**«Шалкан» экияте буенча курчак театры.**<br>**Уку М.Мазунов «Безнең бабай». Уку Г.Тукай «Көз»** *(эчтәлеге буенча ике телдә әңгәмә һәм рәсемнәр ясарга тәкъдим итү).*<br>**Сәхнәләштерелгән уен «Син кем?»** *(бармак театры курчакларын кулланып).* | | |
| **Сентябрь**<br>**II атна**<br>**2.1**<br><br>Төп белем бирү эшчәнлеге | **Тема:**<br>**Кишер үстерәбез.**<br><br>*Сүзлек:*<br>кишер<br>нинди? | **Сәхнәләштерелгән уен «Кишер үстерәбез»** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була. Балаларга әби, бабай, әти, әни, малай, кыз, эт, песи битлекләре таратыла. Түтәлдә «кишер» үсә.)*<br>**Сүзле уен «Мә кишер!»** *(Балалар кишер муляжын бер-берсенә бирәләр. «Кишер» сүзе яңа сүз бирү алымнары кулланып өйрәтелә.)*<br>**Дидактик уен «Сорап ал».** *(Тәрбиячедә муляжлар: зур кишер, кечкенә кишер.)*<br>**Дидактик уен «Нинди кишер?»** *(Эшчәнлекне интерактив тактада да оештырырга була. Балаларда таратма рәсемнәр: чиста кишер, пычрак кишер, зур кишер,кечкенә кишер. Аудиодан ишеткән сүзтезмәгә туры килгән рәсемнәрне бала күрсәтә, әйтә.) Аудио (2 нче кисәк)* | | Битлекләр: әби, бабай, әти, әни, кыз,малай,эт, песи<br>Төрле зурлыктагы Кишер муляжлары<br>Таратма рәсемнәр: чиста кишер, пычрак кишер, зур кишер,кечкенә кишер.<br>Аудиоязма 2.<br>Интерактив такта. |
| **Сентябрь**<br>**II атна**<br>**2.2**<br>(режим вакыты) | **Тема:**<br>**Баллы кишер.**<br><br>*Сүзлек:*<br>баллы<br>баллы кишер<br>баллы алма<br>зур кишер | **Режим вакытында уен эшчәнлеге**<br>(Иртә, саф һавада йөрү, кич) | | Кечкенә кишер, алма.<br>Уенчык куян, кәрзин.<br>Кишер, алма муляжлары. |
